ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№08 (379)
АВГУСТ 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

БАРЫСЫ ДА ТИМЕРДӘЙ НЫК БУЛЫР!

№08 (378)
АВГУСТ 2023

16+

Редакция:
420066, Россия, ТР,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Айгөл Әхмәтгалиева, Римма Вилданова, Вероника Домрачева, Илдус Заһидуллин, Әхмәт Шакиров, Луиза Янсуар
Фотографлар: Александр Ефремов, Алсу Шакирова, Рамил Гали
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова, Игорь Глушков
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Лениногорск тимер-бетон эшләнмәләр заводы хезмәткәрләре. Алсу Шакирова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Россия, ТР, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С–2057
Басарга кул куелды: 10.08.2023
Чыгу көне: 16.08.2023

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

ЯҢГЫРДАН СОҢ ҮСЕП ЧЫККАН ГӨМБӘЛӘР КЕБЕК

Августның коеп яуган яңгырлары, моңарчы күрелмәгән эсселек белән бергә, урман нигъмәтләре өчен менә дигән шартлар тудырды. Социаль челтәрләрдә гөмбә җыярга яратучылар бәхетле мизгелләре белән уртаклаша. Алай да гөмбәле урыннарны күрсәтергә ашыкмыйлар – шулай кабул ителгән. Гөреждә, каен һәм усак гөмбәләре, майлы гөмбә һәм һәркемнең хыялы – ак гөмбә – барысы да пешерелә, кыздырыла, маринадлана, тозлана һәм кышка дип алып куела...

Шунысы шатландыра: әлеге күңелле мәшәкатьләр белән татарстанлылар күптән түгел генә алган һәм ала торган яңа фатирларында шөгыльләнә, чөнки статистика буенча, «гыйнвар–июнь айларында Татарстанда 368 мең квадрат метр коммерцияле торак сатылган – барлыгы 42,5 миллиард сумлык. Шул ук вакытта июнь аенда 9,7 миллиард сумлык 76,5 мең квадрат метр торак куллануга тапшырылган – узган елгы саннар белән чагыштырганда үсеш ике тапкырдан артыграк. Һәм мондый тенденция – торак сатуның арта баруы (өстәвенә, шактый күпкә) соңгы өч ай дәвамында күзәтелә», – дип сөйләде безгә ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин.

Татарстанда яңа йортлар яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр кебек арту ягында. Шунысы да бар: әлеге «гөмбәле урыннар» сер итеп сакланмый. Бу турыда сез басмабызның август санында укып белә аласыз.

Барлык «гөмбәле урыннарны» белүче редакциягез.

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзүм Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Россия, ТР, Казан, Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **1026 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» журналына 102 яшь

\# ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

\# бары тик ТАТАРСТАНДА



60 НЧЫ ЕЛЛАР БУЫНЫ КОРИФЕЕ

Аның шигырьләре күп томлы «Бөтендөнья әдәбияты китапханәсе»нә кертелгән, ә китапларының гомуми тиражы миллион данәдән артып киткән. Равил Фәйзуллин, 60 нчы еллар буыны иҗатчылары вәкиле булып, бүген дә иҗатын туктатмаган берничә шагыйрьнең берсе. Кайчандыр ул СССР Язучылар берлегенең иң яшь әгъзасы булган, бүген исә татар әдәбиятының танылган корифее. «Иҗат – эгоизмның иң югары дәрәҗәсе, – дигән иде бервакыт Равил Фәйзуллин. – Мин дә шигърияткә дөньяны шаккатырырга дип килдем. 60 нчы еллардагы рус шагыйрьләреннән безне нигездә авылдан булуыбыз аерып торды. Әгәр, әйтик, мәскәүле Андрей Вознесенский шигъри формалар белән искиткеч экспериментлар үткәрә, сүз һәм мәгънә уйнатa алган булса, без фикергә таянып иҗат иттек. Шуңа күрә безнең шигырьләрдә тирәнлек, сызлану, дөньяның кая тәгәрәгәнен аңлау күбрәк иде. Без шигъриятттә үги бала кебек идек, ә үги бала тормышның эчке ягын яхшырак күрә».

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Хәрабәләр өстендәге өмет яктысы
Татарстанлылар Курган татарларына ничек булыша

12. Тиздән – өй туйлары
Татарстанда күпме фатир, мәктәп һәм поликлиника төзеләчәк

14. Йортны... 3D-принтер күтәрә
Торак төзелешенә нинди яңалыклар керә

22. Дәлилләр? Тимер кебек нык!
Көндәшләрдән курыкмас өчен ничек эшләргә

26. Алдынгылык драйверы
Төзелештә цифрлаштыру ничек кулланыла

32. Иминлек хакына хезмәттәшлек
Ислам финансларының потенциалы нәрсәдә

игелекле эшләр

36. Кремльдән Кремльгә
«Ефәк юлы» кай ягы белән сокландыра

42. Редакция кухнясында
Юнылган балыкны ничек әзерлиләр

48. Гамьле әңгәмә
Милли сәнгать кемнәрдән башка үсә алмый

52. Хезмәт батырлыгы шәһәре
Тыл фронтка ничек булышкан

мәңгелек кыйммәтләр

60. Тарихи сәхифәләр
Гомәр Терегулов тарихта нинди эз калдырган

64. Татар дөньясы
Сембердә татар сәүдәгәрләреннән кемнәр яшәгән

80. Татарстан авыллары
Кайсы авылда мәчет белән чиркәү янәшә

88. Хәрәкәттә – бәрәкәт
Татар биюенә кайда өйрәнергә була

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Фото: Александр Ефремов

Акыллы гамәлләр

06.07

Сергей Лавров, Россия Федерациясе тышкы эшләр министры, – Казан Кремлендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда:

– Сез тышкы элемтәләр алып бару буенча лидерлар арасында. Һәм иң мөһиме – бу эш юнәлеше республика өчен дә, тулаем ил өчен дә яхшы нәтиҗәләр бирә.

Игелекле эшләр

07.07

Дмитрий Патрушев, РФ авыл хуҗалыгы министры, – Татарстанда, «Бөтенроссия кыр көннәре» пленар утырышында:

– Барыбызны да чит ил селекциясе, чит ил орлыклары мәсьәләсе кызыксындыра. Бу бөтен кешегә дә ошап бетмәскә мөмкин, ләкин безнең өчен башка юл юк: без чит илләр белән эшләвебезне дәвам итәчәкбез, әмма аерым бер шартларда. Яңа кагыйдәләр сентябрьдән үз көченә керәчәк. Һәм алар орлык җитештерүне локальләштерүне күздә тота, беренчел, баштагы технологияләрне безгә тапшырудан алып. Безгә бөтен җитештерү циклын үзебездә оештырырга кирәк, бу шул исәптән патентны, хокук иясенең Россия компаниясе булуын да күздә тота. Шул шартларда гына без билгеле бер дәрәҗәдә куркынычсызлыкка ирешәчәкбез.

Мәңгелек кыйммәтләр



26.07

Маки Салл, Сенегал Президенты, – Казанда, Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда:

– Мин халкының 93–95%ы мөселман булган илне җитәклим, бездәге тотрыклылыкның да сере шул ук толерантлыкта һәм башка диннәр белән үзара тыныч яшәүдә. Сездә янәшә торган чиркәү һәм мәчетләрне күрдем, бу соклануга лаек мисал, барлык илләр дә моннан үрнәк алырга тиеш.

Фото: tatar-inform.ru, global.msk.ru, пресс-служба Раиса РТ

игелекле эшләр

акыллы гамәләр /

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстанлылар Курган татарларына **ничек** булыша

Торак төзелешенә **нинди** яңалыклар кертелә

Көндәшләрдән курыкмас өчен **ничек** эшләргә

Ислам финансларының потенциалы **нәрсәдә**

ЙОЛДЫЗ: ӨМЕТ УТЫ СҮНМӘСЕН...

Руфия Фазылова

Юл буендагы нарат, каеннарны күргәч тә аңлашылды: Йолдызга җитәбез икән. Могҗиза диген – агачларның кәүсәләре каралган булса да, ылыс, яфраклары яшел утыра. Ничек тә яшәргә тырышулары...

Курган өлкәсендә Эчкен–Йолдыз исемле зур татар авылы барлыгын киң җәмәгатьчелек 7 май кичендә белде: ике сәгать эчендә авылның өчтән ике өлеше янып көлгә әйләнде. Икенче көнне 228 йортның юкка чыкканы, җиде кешенең гомере өзелгәне билгеле булды...

Шул олы фаҗигадән соң авыл ничек яши? Курган өлкәсендә булып, әле һаман да бу зур тетрәнүдән һушына килеп җитмәгән халык белән аралашып кайттык.

БЕРДӘМЛЕК

Йолдыз – Казан ханлыгы таркалганнан соң оешкан авыл. Җирле халык сүзләренә караганда, аларның бабалары Идел буе татарлары булган. Чукындыру сәясәте башлангач, бу якларга күчеп килгәннәр. Гасырлар дәвамында авыл Эчкен дип аталган. Ә советлар чорында аңа яңа исем кушыла – Йолдыз. Рәсми рәвештә атама үзгәрсә дә, җирле халык туган авылын һаман Эчкен дип атый. Хәер, хәзер исем турында сөйләүче түгел, уйлаучы да юк. Бөтен теләк, ният – кышка кадәр ничек тә йортларын түбә астына кертеп, утын, газын ялгарга.

Без килгәндә авылда көчле янгынның эзе калмаган иде дияргә мөмкин: көлгә әйләнгән йорт нигезләрен чистартып түккәннәр. Ә менә ара-тирә борынга төтен исе килеп китте. Хәер, авыл тирәсендәге каралган агачлар да ике ай элек булган олы фаҗига турында искәртә. Янгыннан соң монда куркыныч кына түгел, коточкыч иде, диделәр. «Сугыш турында фильмнар күрсәтәләр бит, безнең авыл да шул кадрларны искә төшерде», – диде җирле халык.

Хикмәт, урта мәктәпкә терәлеп диярлек торган йортлар янып беткән, ә белем учагы калган. Мәдәният йорты, мәчет тә исән. Социаль объектлардан бары авылның фельдшер-акушерлык пункты гына көлгә әйләнгән. Йолдызлылар бәхетенә, Курган өлкәсе хакимияте аны ике ай эчендә сафка бастырган. Яңа ФАП 500 кешегә хезмәт күрсәтә алачак. Аны ачу тантанасына Курган өлкәсе губернаторының урынбасарлары Наталья Кириллова белән Константин Ермаков килгән иде. Зур фаҗига кичергән авыл 12 июль көнне гөрләп торды, чөнки Казанда һәм Россиянең башка төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребез бердәм булып Йолдызга җыелды. Биредә ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев Милли Шураның күч-

Фото: Александр Ефремов

Рәзилә Әминовага йортын Курган өлкәсенең дәүләт төзелеш оешмасы салачак, нигезе бар инде.



Гаилә бүген вагонда яши.

Рәзилә Әминова

мә утырышын үткәрде. Төп тема – ике ай эчендә Йолдызда ниләр эшләнгән, тагын кемнәргә кичекмәстән ярдәм кирәк. Максат – кышка кадәр халыкны торaклы итү.

КЫЗЫКТЫРУ

Без барган көнне Йолдызда кырык биш градус эссе иде. Шулай булса да, урам тулы халык: берәү дә тыныч кына өендә утыра алмый. Хәер, утырырга өйләре дә юк. Күбесе вакытлыча вагоннарда яши. Халык мәдәният йорты, мәктәп тирәсендә йөреп тора, барысының да нindидер гозере бар. (Янгыннан соң урта мәктәп бинасы күпләр өчен вакытлы торак булган: биредә ашаганнар да, йоклаганнар да). Курган администрациясе, Казаннан килгән түрәләрне күреп калырга ашыгалар...

Рәзилә Әминова белән дә мәктәп ишегалдында таныштык. Ул биредә җыештыручы булып эшли икән. 7 май төнендә чыккан янгын аны да йортсыз, каралтысыз калдырган. Рәзилә апа бүген сиксән өч яшьлек әнисе, унөч яшьлек оныгы белән вагонда яши. Хәләл җефете исә күптән мәрхүм булган.

– Янган йортымда оныгым һәм улым да пропискада иде, тик торак сала торган сертификат биргәндә, аларны кертмәделәр, – дип борчуы белән уртаклашты ханым. – Янәсе, оныгым безнең гаилә әгъзасы түгел, ә бит аның торагы юк. Хәзер менә суд аша унөч яшьлек оныгымның безнең гаилә әгъзасы икәнен расларга кушалар. Ә ул ким дигәндә өч ай бара торган эш. Әле суд безнең яклы буламы-юкмы - белмим.

Рәзилә Әминованың бүгенге көндә кулында дәүләт биргән 2 миллион 400 мең сумлык сертификаты бар. Бу урында шуны искәртергә кирәктер: әлеге сертификатларның суммасы төрлечә. Курган өлкәсенең Төзелеш министрлыгы стандартлары буенча, янган өйнең квадрат метрына, ничә кеше яшәвенә карап, 1 миллионнан 4 миллион сумга кадәр сертификат бирелә. Аңа Курган өлкәсенең теләсә кайсы шәһәреннән торак сатып алырга яки янган нигезенә йорт салырга мөмкин. Соңгысын сайлаганда, дәүләт яки шәхси подряд төзелеш оешмасы белән килешү төзелә, монысын кеше үзе хәл итә. Бүгенге көндә җирле халыкка барлыгы 178 шундый сертификат бирелгән. Шулар арасында алтмышлап гаилә авылда йорт салудан баш тарткан, алар шәһәрдә йорт эзләү белән мәшгуль икән.

– Кешеләрне көчләп авылда йорт салдырып булмый, – диде Милли Шураның күчмә утырышында Васил Шәйхразыев. – Бу законга каршы килү. Шулай да туган авылында йорт салырга уйлаган кешеләргә Курган өлкәсе администрациясе кызыксындыру чарасы уйлап тапты – сертификаттан тыш 700 мең сум акча бирәләр. Бу инде капка, коймa, зур булмаган каралтыга да җитәргә мөмкин. Ә менә шәһәргә китәргә теләүчеләргә ул акча юк.

Чынлап та, 700 мең сум акча бирелә башлагач, шәһәргә китү уеннан кайтучылар шактый булган. Рәзилә Әминова да башта Йолдыздан кырык чакрым ераклыктагы Шадринск шәһәреннән өч бүлмәле фатир алырга уйлаган. Аннан исә ниятеннән кире кайткан.

– Беренчедән, көчле янгыннардан соң шәһәрләрдә фатир бәяләре нык артты, – диде Рәзилә апа. (Йолдызда гына түгел, Курган өлкәсенең тагын берничә авылында шундый фаҗига булган –

– Бәбкәләрне күңел юанычы булсын дип алдык, – диде хуҗабикә.

авт.) – Бездә бит кеше хәсрәтендә баеп калырга теләүчеләр гел табыла. Икенчедән, җирсез яши алмам, дип уйладым. Янгынга кадәр алты үгезем бар иде. Мунча, каралты – барысы да күз ачып йомганчы юкка чыкты...

Рәзилә Әминовага йортын Курган өлкәсенең дәүләт төзелеш оешмасы салачак, нигезе бар инде. Июль азагына кадәр төзүчеләр йортны блоктан күтәреп, түбә астына кертергә тиешләр. Теге 700 мең сум акчага каралты да эшләтергә нияте бар, мал асрыйсы килә аның.

«МАЛ БЕЛӘН БЕРГӘ, БӨТЕН ИСТӘЛЕКЛӘР ДӘ КӨЛГӘ ӘЙЛӘНДЕ...»

Рәзилә апа безне яшәгән нигезенә алып барды. Сиксән өч яшьлек әнисе Разыя апа каз бәбкәләре саклап утыра иде.

– Бәбкәләрне күңел юанычы булсын дип алдык, – диде хуҗабикә.

– Авылда мондый көчле янгыннар элек булмадымы? – дидем Разыя апага.

– Минем чорга туры килмәде. Ә менә әнкәй берьюлы берничә йорт янды дип сөйли иде. Тик моның кадәр афәт беркайчан булмагандыр: ахырзаман галәмәте кебек иде бит. Санаулы минутлар эчендә янгын бөтен авылны чолгап алды. Әнә, минем ике яшьтәшем, өйләреннән чыга алмыйча, янып үлде. Мине дә балалар гына алып чыкты. Андый чакта өлкәннәр түгел, яшьләр дә югалып кала икән.

– Янгын авыл башыннан, мәдәният йорты ягыннан килде, – диде Рәзилә апа. – Башта безгә кадәр җитәр дип уйламадык та. Әле мин иртә белән малларны ашаттым. Аннары соң күршеләр кычкырды: кешеләргә өйләреннән чыгарга, күл буена барырга кушканнар. Тиз генә җыендык та чыктык. Ул да түгел урамда төтен исенә тончыга башладык. Янгын турында ишетеп, улым Газиз шалтыратты. «Хәзер кайтып җитәм, әйберләрне булса да чыгарырмын», – диде. «Зинһар, йөрмә, улым», – дип телефоннан кат-кат әйттем үзенә. Барыбер кайтты, ул вакытта өйне ут камап алган булган инде. Аннары безнең янга килде ул. Улымның йөзенә карауга ук, йортсыз калганыбызны аңладым. Ул бер сүз әйтми кочаклады гына... Көчле янгын басылганнан соң һәркем өенә таба ашыкты. Без дә улым белән кайттык,

Ике теплицадан кала, бөтен нәрсә янып беткән иде...

Урта мәктәпкә терәлеп диярлек торган йортлар янып беткән, ә белем учагы калган. Мәдәният йорты, мәчет тә исән.

монда әле бөтен җирдә утлы кисәүләр пыскый иде. Авыз-борыннарны юеш чүпрәк белән каплап йөрдек. Ике теплицадан кала, бөтен нәрсә янып беткән иде. Үгезләрне чыгарып җибәргән идем, алар исән калды. Берничә көн болында йөргәннән соң, аларны сатып җибәрдек. Ә менә этебез янып үлде. Этне дә бәйдән ычкындырган идем, күрәсең, төтеннән куркып, кире оясына кергән. Иң аянычы – гаилә альбомнарын бәрәңге базына аткан идем, ирем белән төшкән сурәтләр, балаларның фотолары – алар да янган. Ут базга да төшкән. Әнә шулай, мал белән бергә, бөтен истәлекләр дә көлгә әйләнде...

Шаккаткыч: Рәзилә апалар урамында исән калган йортлар да бар, берсе янган, берсе калган. Әйтерсең, шахмат уены. Секундына 40 метр тизлектәге җил авыл кешеләре белән әнә шулай рәхимсез «шаярган».

– Янгын сүндерүчеләр килдеме соң? – дим Рәзилә апага.

Мөхәммәтнәбиевләрнең ихаталары авыл башында, шуның өчен дә ялкын беренчеләрдән булып аларның мал-мөлкәтен юк иткән.

– Килделәр. Ләкин алар нәрсә эшли ала: авыл бер җирдән генә түгел, әллә ничә яклап янды бит. Ничек бөтен йортлар да көлгә әйләнмәде, могҗиза! Аллаһ кызгангандыр инде...

«АЛТЫ КЕШЕ УРАМДА КАЛДЫК!»

Йорт-җирсез калган тагын бер гаилә – Мөхәммәтнәбиевләр белән таныштык. Ихаталары авыл башында, шуның өчен дә ялкын беренчеләрдән булып аларның мал-мөлкәтен юк иткән.

– Янган йортыбыз 1991 елда салынган иде, ә мин аны яңарттым, – диде гаилә башлыгы Эдуард. – Алты кеше – әнием, җәмәгатем һәм өч бала белән бер йортта яшәдек. Әти күптән вафат. Әлегә гаиләбез белән күрше авылда, туганнарда яшәп торабыз. Балаларның үз өйләренә кайтасылары килә. Янган нигезне чистартканнан соң гына балаларны монда алып килдек, күңелләрендә авыр тойгы калмасын дидек. Әле кечкенәләр бит: иң олысына – ун, уртанчысына – җиде, кечесенә яшь ярым...

Мөхәммәтнәбиевләргә Россия мөселманнары Диния нәзарәте ярдәм итәргә алынган. Ни өчен дигәндә, дәүләттән аларга нибары 666 мең сум акча күчкән, чөнки закон шулай куша.

– Ник алай? – дидем, гаҗәпләнеп.

– Әтидән калган мирас буларак, йортыбыз өч өлешкә: әниемә, сеңлемә һәм миңа бүленгән иде, – диде Эдуард. – Гомер буе шунда яшәсәк тә, йортны үз исемемә күчермәдем. Кирәксенмәдем, димме. Йорт янгач, сеңлемә акча бирмәделәр, чөнки аның яшәү урыны бар. Әнигә 333 мең һәм миңа 333 мең сум тәтеде. Хатыныма да акча юк, чөнки аның туган нигезендә дүрттән бер өлеше бар булып чыкты.

Мөхәммәтнәбиевләр бүген суд юлын таптый. Балигъ булмаган балаларына бер сум компенсация дә бирелмәгән. «Ә алар кайда яшәргә тиеш?» – дип аптырый гаилә башлыгы.

Мөхәммәтнәбиевләрнең йорт төзелеше эшләрен башлап җибәрү өчен Йолдызга Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары Рафыйк Фәттахетдинов килгән иде. Ни өчен нәкъ менә бу гаиләгә ярдәм итүләрен ул болай аңлатты:

– Йолдыз авылында зур фаҗига булганнан соң, Россия мөселманнары Диния нәзарәте

рәисе Равил Гайнетдин белән Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев гел элемтәдә тора. Васил Габделгаяз улы авыр хәлдәге, дәүләттән ярдәм алмаган берничә гаиләне тәкъдим итте. Равил хәзрәтнең күп балалы гаиләгә йорт салып бирәсе килде. Төзелешне баштанаяк контрольдә тотып, Аллаһ боерса, Яңа елга кадәр Мөхәммәтнәбиевләрне тораклы итәчәкбез.

Күп балалы гаиләгә дигән йортның планы бар инде, тугызга җиде квадрат метрлы уртача зурлыктагы, бер катлы торак булачак ул. Июль азагына таба эш башланып китәчәк, –диде Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары.

Мөхәммәтнәбиевләр мәктәпкә терәлеп үк тора. Хикмәт, мәктәп тә, күршеләренең йорты да исән калган.

– Мәктәпнең түбәсе яна башлаган иде, янгын сүндерүчеләр өлгерде, – диде Эдуард. – Таш бина булгач, аңа ут тиз капмады. Күрше дә йортын калай белән тышлаган иде, аларныкы да исән калды. Ә безнең йорт агач булганлыктан, күз ачып йомганчы ут кабып, көлгә әйләнде. Шуның өчен дә хәзер йортларны блоктан эшләргә тырыша халык. Аллаһ сакласын, соңгы елларда безнең якта янгыннар гел булып тора бит.

Авыл буйлап йөргәндә, шуңа игътибар иттек: бирედә бүрәнәдән салынган өйләр күп икән. Түбәләре шифер белән ябылган. Шуңа күрә ике сәгать эчендә 228 йортның көлгә әйләнүе гаҗәп тә түгел.

ТАШЛАМЫЙЛАР...

Кызганыч, Мөхәммәтнәбиевләр кебек дәүләттән аз күләмдә яки бөтенләй компенсация алмаган гаиләләр кырыклап. Барысының да сәбәбе төрле: йорты теркәлмәгән, авылда пропискада булмаган, кемдер мәрхүм әтиәнисеннән калган йортта яшәп яткан. Ә бездә, документның булмаса, син беркем түгел. Шуның өчен дә бүген Йолдызның дистәләгән гаиләсе суд юлын таптарга мәҗбүр. Алар үзләренең шушы авыл кешеләре, янган йорт хуҗалары булуларын расларга тырыша.

Ләкин хәл бөтенләй аяныч түгел. Әнә шундый документлары тәртиптә булмаган 18 гаиләгә Татарстан хөкүмәте йорт салып бирәчәк. Тагын «Татнефть» оешмасы үзенең хәйрия фондыннан 13 гаиләгә торак төзүне планлаштыра. Моннан тыш, Россия мөселманнары Диния нәзарәте кебек, аерым гаиләләргә булышучы дини оешмалар бар. Мәсәлән, беренчеләрдән булып Чувашия мөселманнары Диния нәзарәте Йолдыз

Быелгы уку елында мәктәптә 68 укучы булган.

Халык үзенә ризыкны менә шундый шартларда пешерә.

авылындагы Гариповлар гаиләсенә йорт сала башлаган. Шулай ук Удмуртия мөселманнары да авылның имамына өй салып ята.

Йолдызда янгын булганнан соң, Россиянең һәр төбәгендә яшәүче татар иҗтимагый оешмалары ярдәм кулы сузган. Кемдер акчалата, төзелеш материаллары, икенчеләр азык-төлек җибәреп торган. Әле бу ярдәм бүген дә дәвам итә икән.

Иҗтимагый оешмалар арасында авыл кешеләренә йорт салучылар да бар. Мисал өчен, «Бөтенроссия татар авыллары» иҗтимагый оешмасы гомере буе колхозда эшләгән 74 яшьлек пенсионерга йорт җиткерәчәк. Нижневартовскидагы «Мирас» иҗтимагый оешмасы исә авылдагы укытучы гаиләсенә йорт салачак. Ә Самараның бер төркем эшмәкәре, иҗтимагый оешма вәкилләре Фәтхуллиннар гаиләсен үз канаты астына алган: йортның нигезе инде салынган.

БЕРЕНЧЕ СЫЙНЫФКА БАРУЧЫ ЮК...

Йолдыз авылына иң зур ярдәм күрсәтүче, әлбәттә, Татарстан. Сүз матди як кына түгел, ә мораль ярдәм турында да бара. Һәр эштә башлап йөрүче кирәк бит. Фаҗигадән соң бөтен татар дөньясын күтәрүче буларак Бөтендөнья татар конгрессын әйтми калсак, дөрес булмас...

Йолдызда Милли Шураның күчмә утырышы узган көнне урта мәктәптә укучы балалар велосипедлы булды. Бу Татарстан хөкүмәте тарафыннан алынган матур бүләкләр. Яңа уку елына балаларга мәктәп формалары, уку әсбаплары тутырылган букчалар да тапшырылды. Шулай ук июнь аенда Йолдыз авылының 30 баласы Актаныштагы «Бүләк» лагерында ял иткән.

– Курган өлкәсе хакимияте бер канатыбыз булса, икенчесе – Татарстан, – диде Йолдыз урта мәктәбенең укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гөлсимә Байтирәкова.

Татарстан хөкүмәте яңа уку елына Йолдыз балаларына велосипед, мәктәп формалары, уку әсбаплары тутырылган букчалар әзерләгән.

Мәктәп белән танышып чыктык. Төзек, заманча ул. Стенада татарча язылган плакатлар да күрдек. Заманында биредә йөзләп бала укыган. Быелгы уку елын исә 68 укучы тәмамлаган.

– Курган өлкәсе хакимияте бер канатыбыз булса, икенчесе – Татарстан, – дип башлады сүзен Йолдыз урта мәктәбенең укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гөлсимә Байтирәкова. – Биредә егерме алты ел директор булып эшләдем. Лаеклы ялга чыккач, математика укытучысы, директор ярдәмчесе булып калдым. Йолдыз урта мәктәбе тирә-якта атаклы санала. Балалар бакчасы да биредә урнашкан, анда егермегә якын бала йөри. Ни кызганыч, быелгы уку елында укучылар саны кими: янгыннан соң биш бала гаиләләре белән шәһәргә күченеп китәчәк. Унынчыга да бер-ике генә бала калыр кебек. Беренче сыйныфка керүче балалар да юк...

Йолдызга берничә авылдан килеп укыйлар. (Алар зур булмаган рус, татар салалары). Төп фәннәр рус телендә алып барыла. Татар теле дәресләре ана теле буларак атнасына ике тапкыр керә икән. Ә менә унынчы, унберенче сыйныфларда татарча укымыйлар, чөнки программада каралмаган.

ФЕРМЕРЛАРГА ЯРДӘМ

Мәктәп балаларына гына түгел, Татарстан Йолдызның фермерларына да бүләк әзерләгән иде. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән килештереп, авылның ике фермерына трактор бирделәр. Икесе дә йорт-җирсез калган гаиләләр исемлегендә.

– Йөз гектар җирем бар, – диде Кәлимулла Миңнегәрәев. – Йөз тонна бодаем амбарда янды. Бәясе арзан дип көзен сатмаган идем, язын бодайны урнаштырып, шул акчага берәр техника алырмын, дигән идем. Менә нәрсә килеп чыкты...

Миңнегәрәевләрнең капка белән гаражлары янмаган. Ә менә йорт, мунча, каралтылар көлгә әйләнгән. Аларның бөтен өметләре – Татарстан хөкүмәтендә. Ни өчен дигәндә, йорт салыр өчен аларга 500 мең сумлык гына сертификат бирелгән.

– Төмән шәһәрендә унөч квадрат метрлы бүлмәбез бар, шуның өчен дә без мохтаҗлар исемлегенә кермәдек, – диде Кәлимулла абый. – Янган йортыбызда җәмәгатем белән яшәдек. Ике кызыбыз читтә яши, оныкларыбыз да бар инде, Аллаһка шөкер. Татарстан Республикасына олы рәхмәтебезне җиткерәм, безгә йорт салырга алындылар. Нишләгән булыр идек: 500 мең сумга йорт түгел, мунча да эшләп булмый бит. Ә шәһәргә китәсе килми. Гомер буе җирдә эшләп, авылда яшәп, картлык көнендә ничек таш стена арасына барып утырырга кирәк?!

Кәлимулла абыйның хыял-максатлары зурдан – фермерлык эшен дәвам итү. Бүләккә килгән «МТЗ-80» тракторына нык сөенгән ул. Кышка кадәр яңа йортлы булырбыз, дип тә өметләнә.

Икенче фермер Ринат Сәфәров исә «МТЗ-82» тракторына ия булды. Гаиләсе белән 600 гектар җирне эшкәртәләр икән. Буй җиткән улы, кызы бар, алар төп ярдәмчеләре. Өченче балалары – җиде яшьлек уллары үсеп килә.

– Фермерлык эше белән 2000 нче елдан бирле шөгыльләнәм, – диде Ринат абый. – Янгында бер тракторым янды. Йортсыз да калдык. Гаилә ишле булганга, безгә йорт салу өчен әйбәт акча чыкты – биш миллион сумга сертификат алдык, тагын әле ихаталар төзер өчен дип, 700 мең сум бирелә. Барыбыз да йортта теркәлгән идек. Аллаһ боерса, шул акчага зур йорт салып чыгарбыз, дип уйлыйм. Янган йортыбыз да зур, заманча иде. Башта бу хәлләрне уйлап, ничә төн күзгә йокы кермәде. Хәзер инде тынычланабыз. Төзелеш эшләрен башладык. Ничек тә, салкыннар җиткәнче, яңа йортыбызга керәсе иде.

ТУГАННАРГА СӘЛАМ!

Көне буе йөрелде Йолдызда. Янгыннан соң авылда беренче тапкыр никах укылу шаһиты да булырга туры килде. (Никах табынын яшьләргә Татарстан оештырган иде.)

Беренче карашка, биредә туры сүзле халык яши, дигән фикер туды. Мәдәният йортында узган җыелышта да тарсынып, кыенсынып утырмадылар. «Ни өчен фәлән кешегә ярдәм бар, безгә юк», – дигән сүзләрне дә ишетергә туры килде. Аңлашыла: андый чакта ыгы-зыгы, бәхәсләр күп була ул. Ләкин берәүне дә урамда калдырмаячакбыз, дип ышандырды җитәкчеләр.

Шуның белән бергә халыкның гадилеге, кунакчыллыгы сокландырды. Кем белән генә сөйләшсәң дә, өй түенә килегез, дип чакыралар. Якын итеп кочып алалар. Ике теплицасы гына утырып калган Рәзилә Әминова саубуллашканда бакчасыннан лилия чәчәкләре кисә башлады. Каршы килдем... Соңгысы белән бүлешмәсен. «Үсеннәр, нигезегезнең яме бит», – дидем.

Кайтыр юлга җыенганда, автобуска өлкән яшьтәге бер апа килеп керде. Үзен Мәүлетова Алевтина Әхмәт кызы дип таныштырды. Елмаеп, яныма ук килеп басты:

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән килештереп, авылның ике фермерына трактор бирделәр.

– Татарстан халкына сәлам әйтегез, яме, – диде ул. – Мин ялгыз карчык. Бернәрсәсез урамда калдым. Өстемә кигән яшел күлмәк, аягымдагы башмак, сумкам да Татарстаннан килде, волонтерлар җибәргән. Йортым рәсми рәвештә теркәлмәгән иде. Шуның өчен дә сертификат бирелмәде. Ләкин миңа Татарстан йорт салып бирәчәк, Аллаһ боерса. Төзүчеләр нигезне килеп карады инде. Минем Татарстанда булганым юк, ләкин телевизордан гел карап барам. Мәрхүм бабам тамырларыбыз Татарстаннан булуы белән бик горурлана иде. Казан турында сүз чыкса: «Безнекеләр!» – дип сөенде. Минем өчен хәзер Татарстанда яшәүче һәркем туганнарым кебек якын. Рәхмәт сезгә, яме. Мондый хәсрәтне берегезгә дә күрергә язмасын. Тагын килегез. Яңа йортымда кунак итәрмен, килегез, зинһар...

– Минем өчен хәзер Татарстанда яшәүче һәркем туганнарым кебек якын. Рәхмәт сезгә, яме, – диде Алевтина Мәүлетова.

ТАТАРСТАН

БЫЕЛ БАРЛЫГЫ

3 100 000 м² торак

КУЛЛАНЫШКА КЕРТЕЛӘЧӘК

197 йорт
(1 428 418 м²)
күпфатирлы торак

70 йорт
(160 630 м²)
ТР ДТФ программасы буенча төзеләчәк

10 420 йорт
(1 510 952 м²)
индивидуаль торак төзелеше

БЫЕЛ **42** МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКТӘ ТӨЗЕЛӘ:

53
фельдшер-акушерлык пункты

47 ФАП инде куллануга тапшырылган

4
поликлиниканың

әзерлек дәрәҗәсе – 61%

11
гомуми белем бирү учреждениесе (мәктәпләр һәм мәктәп-бакчалар)

ТӨЗЕЛӘ

«Мәгариф» милли программасы буенча
Р. Гәрәев урамында 1501 урынлык мәктәп төзелде

ТОРАК ҺӘМ СОЦИАЛЬ-МӘДӘНИ ОБЪЕКТЛАР ТӨЗЕЛЕШЕ

«Экология» милли проекты буенча

Казанда биологик чистарту корылмалары реконструкцияләү һәм ләмле кырларны рекультивацияләү, Түбән Кама сусаклагычындагы торбаүткәргечләрне сүтү, Самосырово полигонын рекультивацияләү эшләре башкарыла

68

җәмәгать киңлеген төзекләндерү

«Торак һәм шәһәр мохите» милли проекты буенча гамәлгә ашырыла

«Демография» милли проекты буенча

һәрберсе 220 урынлык

2 балалар бакчасы

төзелә





Быел Татарстанда

751 күпфатирлы йорт

капиталь ремонт программасы буенча төзекләндереләчәк

2 479 000 м² торак*

ТӨЗЕЛЕШЕ ТӘМАМЛАНГАН БУ -

125 йорт

(1 000 010 м²)

күпфатирлы торак

28 йорт

(114 000 м²)

социаль ипотека программасы буенча

1 355 000 м²

индивидуаль торак

** быелның 22 июленнән*

Марат Айзатуллин: «БЕЗНЕҢ БУРЫЧ – ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕ КОМПЛЕКСЛЫ ИТЕП ТӨЗҮ»

Фотолар ТР Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгыннан, tatar-inform.ru, uno-kzn.ru сайтларыннан алынды.

Әхмәт Шакиров

Татарстанда кайда өйләрне 3D-принтерда бастыралар? Казанның яңа архитектурасы башка шәһәрләрнекеннән кай ягы белән аерылып тора? Коттедж бистәләре ничек төзекләндереләчәк? Татарстан картасында нинди яңа микрорайоннар пәйда булачак? «Татарстан» журналының әлеге һәм башка сорауларына ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин җавап бирә.

КОТТЕДЖ БИСТӘЛӘРЕНЕҢ ЙӨЗЕ ҺӘМ ҮЗ ЙОРТЫҢ ХАКЫНДАГЫ ХЫЯЛЛАР ТУРЫНДА

– Марат Мансурович, июль башына Татарстанда 2,3 миллион квадрат метр торак төзелде – бу планлаштырылган еллык күләмнең 75 проценты. План саннарын яңа торакка ихтыяҗ белән чагыштырганда, нинди картина барлыкка килә?

– Әйдәгез карыйк. Гыйнвар–июнь айларында Татарстанда 368 мең квадрат метр коммерцияле торак сатылды – барлыгы 42,5 миллиард сумлык. Шул ук вакытта июнь аенда 9,7 миллиард сумлык 76,5 мең квадрат метр торак сатылган – узган елгы саннар белән чагыштырганда, үсеш ике тапкырдан артык. Һәм мондый тенденция – торак сатуның арта баруы (өстәвенә, шактый күпкә) соңгы өч ай дәвамында күзәтелә. Бу чагыштыру, әлбәттә, беренчел базарда узган елның әлеге чорына карата.

– Үз йорты белән яшәргә теләүчеләр санының артуы торак төзелеше статистикасына нинди йогынты ясый?

– Республикада ел саен тапшырыла торган торак күләменең яртысыннан артыгы гадәттә шәхси торак төзелешенә туры килә. Шул ук вакытта узган ике ел рәттән шәхси торак төзелеше күләме ике миллион квадрат метрдан артып китте. 2021 елда 15329 шәхси йорт төзелде, 2022 елда – 16317. Дөрес, быелгы саннар бераз кимрәк – 1 млн 510,9 мең квадрат метр мәйданга ия 10420 аз катлы торак йорт төзү планлаштырыла. Аларның 9500 гә якыны бүген инде куллануга тапшырылган, ел ахырына кадәр фаразланган саннар ябылыр, дип көтелә.

– Кайбер коттедж бистәләренең планлаштырылуы, архитектурасы, дөресен генә әйткәндә, идеаль булудан ерак. Монда үзгәрешләр көтеләме?

– Сез хаклы, соңгы 10–15 елда шәхси торак төзелеше өчен бүленгән территорияләрдә сыйфат ягыннан канәгатьләнерлек булмаган, тәртипсез рәвештә алып барылган төзелеш өстенлек итә. Без моны бигрәк тә Казан агломерациясе чикләрендә күзәтәбез. Бүген безнең бурыч – элеккеге ялымнардан котылу, территорияләрне комплекслы төзүне тәэмин итү. Сүз, аңлавыгызча, архитектура компоненты турында гына бармый. Беренче чиратта яңа терри-

торияләрнең социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин ителүенә ирешү мөһим. Торак төзелеше буенча карарлар бары тик расланган планлаштыру проектлары нигезендә генә кабул ителергә тиеш. Бигрәк тә тапшырыла торган торакның күләме социаль объектларны, әйтик, мәктәп, балалар бакчаларын сафка бастыру белән туры килүе мөһим. Территорияләрне үстерүне регламентлаштыручы карарларны һәм норматив-хокукый актларны әзерләү өчен, без, Татарстан Республикасы Киңлекләрне планлаштыру институты белән берлектә, кирәкле документларны әзерләдек, хәзер алар килештерү процедурасын уза.

ТОРАКНЫҢ СЫЙФАТЫ ҺӘМ АРХИТЕКТУРА ЯҢАЛЫКЛАРЫ ТУРЫНДА

– Татарстанда сафка баса торган торакның сыйфаты вакыт таләпләренә ни дәрәҗәдә туры килә? Әйтик, 10 ел элек тапшырылганнан ничек аерылып тора?

– Бүген төзүчеләр үз проектларын өч төп сегментта тормышка ашыра: комфорт, бизнес һәм премиум-класс. Күпфатирлы йортлар проект документациясенә төгәл туры китереп төзелә, төзелеш тәмамлангач, Дәүләт төзелеш күзәтчелеге тикшерүен уза. Торакның сыйфаты заманча таләпләргә туры килә, бу шулай ук энергия нәтиҗәлелегенә дә карый. Ун ел элек төзелгәннәреннән төп аерма – бүген төзүчеләр проектларны комплекслы итеп башкара. Мондый алымны тормыш үзе таләп итә: кечкенә архитектура формалары урнаштырылган, парковка, ял итү зоналары булган яңа уңайлы комплекслардагы фатирларга ихтыяҗ зуррак.

– Татарстандагы яңа корылмаларның, микрорайоннарның архитектура йөзен башка төбәкләрдәге шәһәрләр белән белән чагыштырсак, «өстенлек» кайсы якта булачак?

– Казан – Россиянең өченче башкаласы, шуңа күрә аның барлык параметрлар буенча әлеге исемгә туры килүе мөһим. Заманча уңайлы шәһәр мохите, тарихи үзәк, төзекләндерелгән парклар һәм яр буйлары, бина һәм корылмаларның матур, зәвыклы архитектурасы – болар барысы да югары дәрәҗәдә булырга тиеш. Әлбәттә, Россиянең башка төбәкләрендә дә торак комплексларга һәм тулы бер кварталларга яхшы мисаллар күп. Архитекторлар, төзүчеләр квадрат метрларны гына түгел, ә сокланырлык архитектурасы һәм уйланылган инфраструктурасы булган уңайлы мохит тудырырга омтыла. Шулай да бүген Казанның яңа комплексларын, минемчә, зәвыклы, стилистик яктан дөрес иҗат ителгән архитектура проектлары, тарихи үзәк турында сөйләсәк, мохиткә гармонияле рәвештә туры килә торган фасадлар аерып тора. Төзелештә сыйфатлы заманча материаллар һәм технологияләр кулланылуын да әйтергә кирәк.

– Күптән түгел РФ Хисап палатасы аудиторы Наталья Трунова белән очрашу вакытында сез капиталь төзелеш объектларына куелган норма һәм таләпләрнең еш үзгәрүе тапшыру срогына, бәяләргә йогынты ясый дигән фикергә килдегез. Бу мәсьәләдә хәлләр яхшы якка үзгәрергә мөмкин, дип ышанырга буламы?

– Әйе, без социаль объектлар мисалында анализ үткәрдек. Мондый күренеш ачыкланды: биш ел элек яңа проектлау нормалары һәм кагыйдәләре гамәлгә кергәннән соң, мәктәп һәм балалар бакчалары биналарының мәйданы һәм күләме бер ярым-ике тапкырга арткан. Гади мисал: 1985 елда Чаллыда төзелгән 1500 урынлык бассейнлы мәктәпнең мәйданы – 16 мең квадрат метр. Ә быел Казанда Раис Гәрәев урамында тапшырылачак мәктәпнеке 29 мең квадрат метр, ул шулай ук 1500 урынга исәпләнгән, бассейнлы. Нәтиҗәдә, объектны төзү бәясе һәм аны киләчәктә карап тоту чыгымнары шактыйга арта. Бу никадәр акланган гамәл соң? Нәтиҗәдә, без норматив документларга үзгәрешләр кертергә тәкъдим иттек һәм Россия Төзелеш министрлыгына һәм Хисап палатасына конкрет тәкъдимнәр юлладык. Безне ишетерләр һәм кайбер үзгәрешләр кабул итәрләр, дип ышанам.

ТӨЗЕЛЕШТӘ ЯҢА ҺӘМ ЦИФРЛЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ТУРЫНДА

– Соңгы вакытта торак төзелешендә нинди яңа технологияләр, материаллар пәйда булды?

– Цифрлы технологияләр әкренләп торак төзелешенә дә кертелә. Төзелеш проектларын гамәлгә ашырганда, BIM-технологияләр куллану гадәти практикага әверелде, дәүләт заказын үтәгәндә, мәгълүмати модельләштерүне куллану мәҗбүри санала. Ул проектны эшли башланганнан алып бинаны утилләштергәнчегә кадәр булган барлык үзгәрешләрне контрольдә тотарга мөмкинлек бирә, проектлаучылар, консультантлар, төзүчеләргә үзара нәтиҗәле хезмәттәшлек итәргә булыша. BIM куллану документларны эшләгәндә проектлау, төзелеш, координацияләү һәм килештерүләр вакытын кыскартырга мөмкинлек бирә. Йортларны төзү тизлеген һәм сыйфатын саклау максатыннан төзелешне контрольдә тотуның автоматлаштырылган системалары кертелә.

Республикада су агудан саклау, электр белән идарә итү, исәпләгеч күрсәткечләрен автомат рәвештә тапшыру һәм янгын сүндерү системасын кертү кебек «акыллы йорт» элементлары кулланылган заманча торак комплекслары төзелә инде (мисал өчен, Татарстанда беренче күпфункцияле UNO комплексы; девелоперы – «Унистрой»). Face ID (подъездга кешене йөзеннән танып кертү функциясе) һәм Smart-замоклар (электрон биометрик йозаклар) һ.б. кулланыла. Әлегә мондый технологияләрне куллану массакүләм характерда түгел, әмма киләчәктә бу булачак. Өстәвенә, әгәр «акыллы йорт» системасы халыкка смартфоннан яки планшеттан идарә итәргә мөмкинлек бирә икән, «акыллы шәһәр» системасы квартал, микрорайон, район яки хәтта шәһәр масштабында оптималь экосистема булдыруны күздә тота.

– Ә тармак үсеше драйверы – индивидуаль торак төзелешендә инновацияле технологияләр кулланыламы?

– Әлбәттә. Мәсәлән, Яшел Үзән районының Әйшә авылында 3D-басма инновацияле технологияләре ярдәмендә тулы бер бистә төзелә. Ул әлегә Россиядә беренче һәм бердәнбер шундый комплекс. Төзелеш вакытында 3D-принтер, өч үлчәмле модельгә нигезләнеп, роботлаштырылган «кран-кул» ярдәмендә бетон катнашмасын катлам-катлам салып бара, шул рәвешле конструкцияне төзелеш мәйданчыгында ук ясый. Эчке эшләре эшләнмәгән бер йортны салу өчен 21 көн китә, ә норма буенча файдалану срогы 80 нән 120 елга кадәрне тәшкил итә.

Индивидуаль торак төзелешендә иң перспективалы технологияләрнең берсе – модульле төзелеш. Татарстан Республикасында префаб технологиясе буенча эшләнгән әзер йорт комплектлары җитештерүче предприятиеләр бар. Анда сыйфатны контрольдә тотуның заводта җайга салынган системасы эшләгәнгә, мондый йортларны җыю вакытында нindidер җитешсезлекләр калу куркынычы кими. Мәсәлән, Лаеш районының Сараево

бистәсе әлеге технология буенча төзелде. Республикада соңгы 10 ел эчендә төзелеш материаллары чыгара торган 150 дән артык сәнәгать предприятиесе ачылды һәм яңартылды, шул исәптән дөнья дәрәҗәсендәге предприятиеләр дә. Бүген Татарстан Россия Федерациясендә иң алга киткән төзелеш сәнәгате материаллары базасына ия.

ЯҢА МИКРОРАЙОННАР ҺӘМ ТАРИХИ ҮЗӘК ТУРЫНДА

– Дус булмаган чит ил фирмаларының базардан китүе торак төзелешенә һәм гомумән тармакка нинди йогынты ясады?

– Бернинди дә йогынты ясамады, торакны файдалануга тапшыру буенча план күрсәткечләре тулы күләмдә үтәлә. YIT киттеме? Аның бөтен бизнесын – илнең биш төбәгендә проект һәм төзелеш стадияләрендәге 19 проектын – Россиядә девелопмент һәм төзелеш өлкәсендә иң эре корпорацияләрнең берсе булган «Эталон» төркеме сатып алды. Компания яңа проектлар белән Омск, Новосибирск өлкәсе, Екатеринбург, Төмән һәм Казан базарларына чыкты. «Эталон» бездә YIT игълан иткән проектларны да тормышка ашыра: бу – Гаврилов урамындагы «Счастье в Казани» һәм Павлюхин урамындагы «Квартал Сюита» торак комплекслары.

– Якын киләчәктә ТР башкаласында һәм республиканың башка шәһәрләрендә нинди яңа микрорайон һәм торак массивлар пәйда булачак? Казан елга порты янындагы территориядә төзелеш планнары никадәр кызыклы?

– Казан елга порты тирәсендәге территориядә тормышка ашырылачак проектка килгәндә, шуны әйтә алам: ул бик җитди һәм озак вакытка исәпләнгән, аны эшләп чыгу өчен, ким дигәндә, 10 ел кирәк. 287 гектар мәйданда 1,5 миллион квадрат метр торак һәм 1,3 миллион квадрат метр коммерция биналары, шулай ук 20 балалар бакчасы һәм 3–4 мәктәп төзү планлаштырыла. Территориянең, кимендә, 25 процентын, ягъни 72 гектарын төзекләндерү өчен бүлеп бирү күздә тотыла, шул исәптән 30 гектарында парк һәм скверлар булачак. Реновациянең беренче этабы кысаларында 1,3 километрлы Идел ярын төзү планлаштырыла. Киләчәктә яр буе озынлыгы 12 километр тәшкил итәргә тиеш. Торак төзелеше нигездә 4–15 катлы булачак, әмма биегрәк йортлар да салыначак. Әлеге колачлы проектның архитектура концепциясен «Цимайло, Ляшенко һәм партнерлар» бюросы эшләде. Татарстан башкаласы өчен әлеге территорияне үзләштерү бик перспективалы һәм бу комплекслы үсеш күзлегеннән караганда гына түгел: Казанга

чыннан да Идел буе ягын үстерү җитми иде. Бу проект бик уңышлы булачак, дип саныйм.

– Тарихи үзәктә төзелеш алып бару, аны яңарту – бик җитди, четерекле тема. Күптән түгел оештырылган «РЕБУС: тарихи үзәктә төзелеш икътисады» Халыкара форумы да әлеге темага багышланган иде. Монда эш стратегиясе нинди?

– Минемчә, шәһәрләрнең тарихи үзәкләре үсешенең төп юнәлеше бу территорияләрдә бизнес, хакимият, девелоперлар, саклау органнары мәнфәгатьләренең ярашуыннан тора. Тарихи үзәк проблемаларын планлы рәвештә хәл итәргә кирәк, алар шунда ук юкка чыга алмый. Бу республикада 2011 елдан бирле алып барыла торган, инде үзенең сизелерлек уңай нәтиҗәләрен биргән көндәлек эш.

– Уңайлы торак – ул һәрвакыт уңайлы мохит тә. Быел Татарстан башкаласында, шәһәрләрдә һәм республика районнарында нинди яңа иҗтимагый киңлекләр барлыкка киләчәк?

– Республикада 60 иҗтимагый киңлек төзекләндерелә, бу максатларга 2 миллиард сумнан артык акча бүлеп бирелгән. Шуларның 26 сы – яңа территорияләр. Тагын 8 объект – Мамадыш, Лаеш, Болгар, Зәй, Алабуга, Яшел Үзән, Лениногорск һәм Әлмәт – Бөтенроссия кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр конкурсы нәтиҗәләре буенча төзекләндереләчәк.

2023 елның мөһим объектлары исемлегендә – Горький паркының керү төркеме (беренче чират) һәм Казандагы Иске Татар бистәсенең үзәгендәге Юныс мәйданы, Яр Чаллыдагы «Яр буе» паркы һәм Табиев яр буе, Биләрдәге «Алтын Дага» мәдәни-рекреация кластерының икенче чираты, Алабугадагы Шишкин буалары, Зәйдәге Яшьләр паркының беренче чираты, Яшел Үзәндәге «Юный корабел» һәм Алтынов скверлары, Кама Тамагында «Диңгез – море Татарстана» (Лобач тавы) туристлык-рекреация кластерының өченче чираты, Лаешта «Ак таулар» мәдәни-рекреация кластерының беренче чираты, Болгарда «Спас Болгары» социаль-мәдәни үзәген төзекләндерү һәм башкалар.

Соңгы 7 елда Татарстанда 367 яңа иҗтимагый киңлек төзелгәнен дә билгеләп үтәсе килә.

«Неолит Дизайн» студиясе Татарстанда ландшафт дизайны һәм комплекслы төзекләндерү проектларын гамәлгә ашыру белән инде 15 елдан артык уңышлы шөгыльләнә.

РӘХӘТ УРЫН ГАРМОНИЯСЕ

Татарстанда зур шәһәрләрдән читтә йортлар салу һәм алар урнашкан кишәрлекләрне күзне сөендерерлек итеп матурайту артканнан-арта. Кешеләр, мегаполис шау-шуы һәм ыгы-зыгысыннан туеп, ял итү өчен үзләренә тыныч һәм рәхәт урын эзли.

– Бүген безнең клиентларыбыз үз биләмәләрен бизәүнең табигый юнәлешләренә өстенлек бирә – алар җирле табигать гүзәллегенә яисә борынгы бакчаның аутентик детальләренә хозурланып ял итәргә тели. Оригиналь стильләр, мәсәлән, хайтекка нигезләнгән заманча өслүб яки шәрык юнәлешләре дә популяр, – дип сөйли **«Неолит Дизайн» компаниясе җитәкчесе Ләйсән Шлайфер.** – Заказчылар үзләренең шәхси стилен булдырырга омтыла, башкалардан аерылып торырга тели. Ландшафт дизайнында клиентның характерын, фәлсәфәсен чагылдыру мөһим булганда, эшләве бик кызык.

Шәһәр читендәге кишәрлекнең бизәлешен сайлаганда, дизайнер йортның тышкы кыяфәтен дә, биләмәнең үзенчәлекләрен дә исәпкә ала, – ди Ләйсән. – Әмма иң мөһиме – заказчыны сөендерү, илһамландыру. Нинди вариантлар бар соң?

УРТА ДИҢГЕЗ СТИЛЕ

Ул Италия һәм Испаниянең кояшлы, тормышчан кәефе белән сугарылган. Анда җылы кызгылт-сары, көрән төсмерләр белән баетылган җете төсләр (сары, күксел, зәңгәрсу) патшалык итә. Болар барысы да рәхәтлек, ләззәт мохитен тудыра. Үсемлекләрне җентекләп сайлау мөһим: алар көньяк табигатен хәтерләтергә, әмма урта полоса климатына яхшы яраклашырга тиеш. Бу крокус, примула, йөзем, зелпе, роза булырга мөмкин.

СКАНДИНАВИЯ СТИЛЕ

Төньяк табигатен чагылдыру, минималистик эстетика тудыру мөһим: гади, табигый композицияләр, ташлар, ылыслы агачлар, кыяклылар. Ясалма калкулыклар, ташлар арасында агып яткан чишмә, чуерташ һәм яссы ташлар түшәлгән сукмаклар урынлы.

МАВРИТАНИЯ (ШӘРЫК) СТИЛЕ

Кишәрлек агачлар күләгәсендәге чишмә янында ял итәсе килерлек оазисны хәтерләтә. Беседкаларны бизәгәндә мәрмәр, мозаика кулланыла, яшел газоннар төсле плиткалардан катлаулы бизәк төшерелгән мәйданчыклар белән аралаша. Клематис, хуш исле рәйхан, шалфей, бөтнек, чия, груша утырталар.

КАНТРИ

Чәчәк түтәлләренә көнбагыш, дельфиниум, кыңгырау, кашкарый, гортензия, люпин кебек җете чәчәкле үсемлекләр утыртыла. Декор – авыл көнкүреше элементлары: агач арбадагы чәчәк түтәле, балчык чүлмәкләр эленгән казыклар, сусипкечләр. Агач җимешләре һәм хәтта яшелчәләр дә декоратив акцентка әйләнергә мөмкин.

ПРОВАНС

Нәзакәтле француз эстетикалы гадилек һәм уңайлылык. Ландшафт ак, шәмәхә, лаванда төсендәге үсемлекләргә бай. Яран, роза, лаванданы түтәлләргә генә түгел, чүлмәкләргә дә утыртырга була. Күп кеше хуш исле үләннәр түтәле дә үстерә. Дизайнның башка детальләре – чүкеп ясалган яки агач эскәмияләр, махсус искертелгән арка һәм беседкалар, таш түшәлгән сукмаклар.

ЭКОСТИЛЬ

Кишәрлекнең табигый халәтен саклый, шунлыктан биредә җирле үсемлекләргә (ромашка, тукранбаш, абага) өстенлек бирелә. Чәчәкләрне түтәлгә утыртмыйлар, алар төрле җирдә үсә. Коймалар урынына – үсемлекләрдән тере киртәләр, бормалы сукмакларга таш һәм чуерташ түшәлә.

Фото «Неолит Дизайн» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

Төзелеш объектларын саклауның үзенчәлекләре бар. Үзара килешүне планлаштырганда, сак предприятиесенең объектта иминлекне тулысынча тәэмин итүне күздә тоткан индивидуаль программасы булуы идеаль вариант санала.

ТӨЗЕЛЕШ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫКТАН БАШЛАНА

«БаяZet» компанияләр төркеме идарәчесе Владлен Рәшит улы Абделмәнов төзелеш мәйданчыгында тынычлыкны тәэмин итү төшенчәсенә нәрсәләр керүе турында сөйләде. Әлеге ширкәт Россия базарында 2018 елдан эшләп килә, ул нефть чыгару һәм төзелеш тармагының әйдәп баручы предприятиеләре, төрле җитештерү компанияләре, дәүләт хакимияте органнарына куркынычсызлык хезмәте күрсәтә.

– Владлен әфәнде, сак компанияләренең төзелеш объектларындагы эшендә нинди үзенчәлекләр бар? Ни өчен бу мәсьәләдә нәкъ менә тәҗрибәсе булганнарга мөрәҗәгать итәргә кирәк?

– Теләсә кайсы объектта төзелеш эшләрен планлаштырганда, тикшереп чыгару-кертү постын, төзелеш складларын, видеокамераларны кайда урнаштырырга икәнен, төзелешнең тирә-ягыни дәрәҗәдә әйләндереп алыначагын уйларга кирәк. Әгәр территория иркен булса, сакчыларның күчеп-йөреп тору мәсьәләсе дә карала. Махсус чаралар һәм җиһазлар нәтиҗәле кулланылсын өчен, барлык нечкәлекләр сак оешмасы белән тикшерелә, килештерелә. Төзелеш объектларын саклау шулай ук товарларның, материалларның хәрәкәтен контрольдә тотуны һәм чыгару-кертү режимын да күздә тота. Әлеге процесслар яклар тарафыннан бергәләп координацияләнә. Күперләр төзелешендә сак эшен тәэмин итүнең өстәмә үзенчәлекләре бар, чөнки күперләр аеруча игътибарлылык таләп ителгән стратегик объектлар булып тора. Югарыда санап үткәннәрдән тыш, мондый объектларның террорчылыкка каршы иминлеге дә гамәлгә ашырыла.

– Объектларыгызның иминлеген тәэмин итү өчен, нинди алымнар һәм технологияләр кулланасыз?

– Безнең өчен тотрыклылык мөһим, бу исә ышаныч яулаган эшчеләр белән тәэмин ителә. Аларның күбесе – хокук саклау органнары һәм хәрби структураларның элеккеге хезмәткәрләре; Росгвардиядә махсус белем эстәп, шәхси сакчы таныклыгы алган кешеләр дә бар. Һәр ел саен барысы да әзерлек курсларын кабат уза. Хезмәт хакы тотрыклылыгы һәм эш нәтиҗәләре нигезендә премияләр түләү системасы да мөһим роль уйный. Махсус компьютер программасын кулланып, хезмәт күрсәтелә торган объектларда тикшерүләр үткәрәбез. Әгәр хезмәткәрләр тырышлык күрсәтсә, ниндидер уңышка ирешсәләр, хокук бозу очрагын булдырмый калсалар, сак хезмәте начальниклары премия билгеләү турында отчет яза.

Эштә яңа технологияләр кулланыла. Мәсәлән, өченче затларның кушылып тыңлау мөмкинлеге булмаган бердәнбер ешлыклы яңа төр рацияләр, периметр тирәли сак өчен акыллы комплекслар, махсус техника хәрәкәтен һәм маршрутларын контрольдә тоту өчен заказчы транспортына урнаштырылып, сак мониторы аша күзәтелә торган GPS-трекерлар, читтән торып эшләүче хезмәткәрләрне контрольдә тоту өчен үз IT-программабыз һәм аның мобиль кушымтасы гамәлдә. Җитәкче Россия Федерациясенең теләсә кайсы төбәгеннән шул кушымта аша тиешле мәсьәләләрне билгели һәм аларның үтәлешен күрә ала.

– Сак предприятиегезнең нинди төр хезмәтләренә аеруча ихтыяҗ зур?

– Төрле мәсьәләләрдә клиентларыбызның күбесе даими клиентка әйләнә һәм алар безгә төрле хезмәт сорап мөрәҗәгать итәләр. Болар арасында – стационар объектларны физик каравыллау, төрле бәйрәм-кичәләрне, очрашуларны саклау, йөкләрнең иминлеген тәэмин итү, куркынычсызлык системаларын проектлау һәм урнаштыру, техник сак чараларын урнаштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү, клиентларыбызның хак-хокукларын канун нигезендә яклау мәсьәләләрендә консультация, шулай ук заказчының үзен һәм аның гаилә әгъзаларын шәхси саклау.

– Клиентларыгыз исемлегендә нинди компанияләр бар?

– «Туры инвестицияләр фонды» ҖЧҖ, «Капитал-Строй» ҖЧҖ, «БКС» ҖЧҖ, «А.Элит групп» ҖЧҖ, «3Д Лэнд» ҖЧҖ, «Инженерлык төзелеш идарәсе» компанияләр төркеме» ҖЧҖ, «Татинвестгражданпроект» ДУП, «СтройБытСервис» ҖЧҖ һәм башка ширкәтләр партнерларыбыз булды һәм кайберләре белән хезмәттәшлегебез бүген дә дәвам итә. Бөтен коллектив исеменнән барысын да якынлашып килгән Төзүчеләр көне белән котлыйм, һәр көнегез яңа уңышлар һәм казанышлар белән тулып торсын. Үзегезне саклагыз, иминлеккә, сәламәтлеккә һәм үсешкә акча кызганмагыз.

Фото «БаяZet» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА



ТИМЕР-БЕТОН КЕБЕК НЫК

Лениногорск тимер-бетон эшләнмәләр заводы директоры Александр Тришкин Татарстанның бөтен көньяк-көнчыгышын тимер-бетон белән нибары 100 кешенең ничек тәэмин итә алуы турында сөйли. Җитештерү эшендә кимчелекләр дә, көндәшләр дә борчымасын, һәрнәрсә һәрвакыт тимер-бетон кебек нык булсын өчен нишләргә кирәклеген дә аңлата ул.

– Безнең заводка 68 яшь һәм ул рекламага мохтаҗ түгел. Лениногорск тимер-бетон эшләнмәләр заводы исеме һәрвакыт телдә булды. Завод тарихы зур һәм кызыклы вакыйгаларга бай, мәсәлән, совет чорында, завод бригадасы ВДНХ күргәзмәсендә «Москвич» автомобиле хакы кадәр премия белән бүләкләнә! Бу вакыйганы барлык завод хезмәткәрләре бүген дә горурланып искә ала.

ТИМЕР-БЕТОН ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Хәзерге вакытта төзелә торган барлык сәнәгать комплекслары, бигрәк тә Татарстанның көньяк-көнчыгышындагылары, тимер-бетон мәсьәләсендә беренче чиратта безгә мөрәҗәгать итәләр. Монда төп үзенчәлек: нефть һәм газ өлкәсе өчен сәнәгый төрдәге эшләнмәләр булырга тиеш. Былтыр да, хәзер дә без – «Татнефть»нең төп тәэминатчылары: Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы нефть суыра торган сиртмә насосларның һәр икенчесе безнең фундаментта тора.

Узган ел без тимер-бетон эшләнмәләрне Дзержинскига атом электростанциясе төзелешенә җибәрдек. Быел Пермьгә һәм Казанга торак комплекслар төзелешенә ташыдылар. Республиканың көньяк-көнчыгышындагы һәр шәһәрдә – Бөгелмәдә, Баулыда, Азнакайда, Алабугада, Лениногорскида, шулай ук Чистайда, Казанда безнең өлеш кергән боз объектлары бар.

ӘГӘР БЕЗНЕ УЗСАЛАР...

Хәзер завод күбрәк сәнәгый заказларга йөз тота. Һәм безнең көндәшләребез юк. Бу без шундый бөек булганга түгел, ә көндәшләргә карата мөнәсәбәтебез игътибарлы булганга күрә – әгәр кемдер безнең эшләнмәләрне сыйфат, заказ саны ягыннан узып китә икән, бу безнең кимчелекләребезгә ишарә. Димәк, аларны күреп алырга һәм төзәтергә кирәк. Шуңа күрә бездә кимчелекләр дә юк. Камилләштерергә кирәк кайбер нәрсәләр бар. Мәсәлән, сезонлылык. Кыш көне барлык складларыбызны продукция белән йөз процент тутырып куйдык. Быел ике ай эчендә булган запасларыбызны кырып-себереп алып бетерделәр. Нәтиҗә ачык күренә: күбрәк эшләргә кирәк.

ЗАВОДНЫҢ ТӨП РЕСУРСЫ ҺӘМ НИГЕЗЕ

Әйтсәм ышанмассыз да, әмма менә шундый зур күләмнәрдә товар җитештерә торган заводта нибары йөз кеше хезмәт куя. Барлык эш оптимальләштерелгән, автоматлаштырылган һәм модернизацияләнгән. Яңа системалар һәр этапта хезмәткәрләр санын киметергә мөмкинлек бирде: белгеч программага эш куша да чираттагы этапка күчә.

Ләкин без кешеләрне таратмыйбыз, белгечләрне саклыйбыз, яңадан укытабыз һәм өйрәтәбез. Чөнки кешеләр – төп байлыгыбыз. Алар заводның нигезен тәшкил итә. Монда 36 шар ел, 43 әр ел эшләгән лениногорскилылар бар... Бездәге кайбер династияләрнең гомуми эш стажы завод яшеннән дә күбрәк! Бу Курскийлар, Мөхәммәтовлар династияләре...

Мондый авыр эшкә аларны нәрсә җәлеп итә, дип сорарсыз. Иң беренче чиратта – тотрыклылык. Бездә заказлар даими, хезмәт хакы яхшы. Алдынгыларны сәяхәт итәргә юлламалар белән бүләклибез. Безнең коллектив инде кайда гына булмады: Питерда да, Әрмәнстанда да, Италиядә дә...

ДӘҮЛӘТ БЕЛӘН ГОРУРЛАНУ

– Хәзер зур заводлар өчен авыррак вакыт, – дип дәвам итә сүзен Александр Тришкин. – Шартлар үзгәрде. Элек төп критерий «бәя - сыйфат» нисбәте иде. Хәзер бәя генә мөһим. Техник аудит юк. Мин бу күренешкә каршы көрәшәм, техник тикшерүнең кирәклеген исбатлыйм. Дәүләт катнашы булган объектлар һичшиксез техник аудит узарга тиеш, дип саныйм. Конкурс нигезендә сатуларга рөхсәт бирер алдыннан техаудит үткәрергә кирәк: предприятиегә барып карагыз, ничек эшлиләр, продукцияне нәрсәдән ясыйлар, заказны тәэмин итү өчен запаслары җитәрлекме һ.б. Шул очракта гына сыйфатка бәйле проблемалар килеп чыкмаячак, тендерда колак ишетмәгән, күз күрмәгән компанияләр җиңмәячәк.

Безгә кеше күп килә: кайсы укырга-өйрәнергә, кайсы – экскурсиягә. Безнең яшерер нәрсәбез юк.

Фото: Алсу Шакирова. РЕКЛАМА

– Ничек кенә купшы яңгырамасын, без барыбыз да бер чылбырның буыннары.

– Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы нефть суыра торган сиртмә насосларның һәр икенчесе безнең фундаментта тора.

– Әзер тимер-бетон плитәдән нинди ис килгәнен беләсезме? Балачактагы дымлы идән исе. Хәтерлисезме?

Минемчә, үз йортын төзү белән мәшгуль кешенең идәнендә-түшәмендәге плитәнең башына килеп төшмәячәгенә ышану телләге табигый.

Күрше заводлардан килүчеләр дә күп – бик рәхәтләнеп каршы алабыз. Әйе, продукция күбрәк җитештерелә торган яки ассортименты баерак булган заводлар бар, бу исә безгә кайсы юнәлешкә омтылырга кирәклеген генә күрсәтә. «Менә монда ялгышасыз», «Җиңелрәк юл белән, яхшырак эшли алыр идегез», – дип әйткән һәр искәрмәгә, рәхмәт әйтеп, камилләшергә тырышабыз. Бездән күчереп ясыйлар икән, рәхим итсеннәр. Безнеке кебек итеп ясый алсалар.

ЭШЛӘП БУЛМЫЙ, ДИП ӘЙТҮ ДӨРЕС ТҮГЕЛ

Мин монда сигез ел эшлим. Заводка башка өлкәдән килдем, шуңа күрә иң беренче пролетлар буйлап йөреп, нәрсәнең ничек эшләнгәнен карадым, өйрәндем. Башка тармактан килгән кеше буларак, минем бар нәрсәгә дә карашым яңа иде. Мөгаен, ахмак сораулар биреп, кешеләрнең ачуын да чыгарганмындыр. Тимер-бетон эшләнмәләр җитештерү процессын аңлау өчен, барысын да тәфсилләп сораштым, вак-төягә белән кызыксындым. Ни өчен нәкъ менә шушы рәшәткә куела? Ни өчен нәкъ менә шушы состав кулланыла? ПТО башлыгы бөтен нәрсәне күрсәтте, аңлатты, норматив-хокукый актлар белән чагыштырды, теге яки бу нәрсәнең ни өчен менә болай булуына төшендерде. Башымда һәрвакыт бер уй йөрде: без эшләгән һәрнәрсә әле югары чик түгел, аны камилләштерергә, яхшыртырга мөмкин. Мин әле дә шулай эшлим. Эшләп булмый, килеп чыкмаячак, дип әйтү дөрес түгел. Нигә эшләп булмый? Әйдәгез сынап карыйк, ә, бәлки, килеп чыгар! Эшләп карамау хата булачак. Без өйрәнүне, сынап карауларны туктатмаска тиеш.

МИН РӘССАМ, МИН ӘНӘ ШУЛАЙ КҮРӘМ

Бу завод, бу эш – тормышымның бер өлеше. Һәм эшем өчен миңа оят түгел. Төрле нечкәлекләрне күрергә яратам. Җитештерү тармагында гына түгел, хезмәт күрсәтү өлкәсендә дә. Әгәр каядыр баргач, әйтик, берәр яхшы брендлы кофе белән сыйлансам, үземә теркәп куям: бик яхшы күренеш бит, нигә әле үзебездә

дә сынап карамаска. Белемнәремне җитештерүдә сынап карыйм һәм кулланам. Әйтмим, минем белән эшләү авырдыр да, чөнки һәрвакыт яңалык кертергә тырышам. Холкым шундый. Хәтта кайбер карарлар, яңа ысуллар төшемә дә керә – иртәнге биштә үземнекеләргә шалтыратып: «Сәгать җидедә җыелабыз да фәлән-фәлән мәсьәләне тикшерәбез», – дим. «Тагын төш күрдеңме?» – дип көлә дусларым. «Әйе, төшемдә күрдем!» Ниндидер алдынгы идея, иҗади алымны төштә күргәнем бар... Мин рәссам, мин шулай күрәм. Барысы да иҗади рухтагы фикерләр. Чөнки җитәкче үз предприятиесенә илһам биреп торучы, әлеге зур механизмны эшләтеп җибәрүче ул. Кешеләр мине аңлый, чөнки без бер эшне башкарабыз.

ТЫЛСЫМЛЫ КАМЧЫ

Монда беркемне дә камчы белән «кыздырырга» кирәкми. Ә нигә? Ник әле мин өреп-җикеренеп, мәҗбүриләп йөрергә тиеш, ди? Мин эт түгел ләбаса. Кеше йә безнең белән, йә юк. Безнең кеше үз гамәлләре белән мине түгел, ә үз бригадасын, бөтен заводны уңайсыз хәлдә калдыруын аңлый. Тапталган сүз булса да, шунысы хак: без барыбыз да бер чылбырның буыннары. Әгәр дә берәрсе аннан-моннан гына эшли икән, бөтен нәрсә җимерeләчәк.

Беләсезме, бездә элек иң зур җәза нинди иде? «Син арыгансың, ял ит, яңа көч белән кайт, һәрнәрсәгә башка күзлектән кара!» – дип, кешене отпускка җибәрә идек.

БЕЗ ХЫЯЛНЫ ЧЫНГА АШЫРАБЫЗ

Беренче карашка, эшчеләр цехта көрәкләр белән эшләп тир түккәндә, без монда, офиста, ручкадан авыррак бернәрсә дә күтәрмибез кебек тоела. Ләкин шундый мисал китерим. Без үз кадрларыбызны үстерәбез: цехтан кешеләрне сайлап, укырга җибәрәбез, уку өчен үзебез түлибез... Менә шулай ике хатын-кыз укып кайтып, офиска эшкә күчте. Һәм береаздан кире цехка кайтаруыбызны сорап керделәр: «Анда кулларыбыз арый, – диләр, – ә монда – баш. Куллар арыса арысын...» Бусы «Җитәкче булу җиңелме?» дигән сорауга җавап та. Кешеләр өчен җаваплылык беркайчан да җиңел түгел. Менә, мәсәлән, бер эшченең кәефе киткән, ди. Аңа ни булган? Бәлки өйдә берәр нәрсә килеп чыккандыр? Аңа ничек ярдәм итәргә? Минем бүлмә ишегендә сез кабул итү сәгатьләре графигын күрмәссез. Һәркем теләсә кайсы вакытта теге яки бу проблема белән килә ала, һәм без ул проблеманы хәл итәчәкбез. Һәр эшченең гаиләсе бар һәм, аңа хезмәт хакын түли алмасам, бу минем өчен иң зур фаҗига булачак. Әлеге мәсьәлә беркайчан да тынычлыкта калдырмый. Мин коллективны эш күләме, чимал белән тәэмин итәргә, сатуны җайга салырга тиеш...

Минем өчен коллективның рухи халәте, кәефенең нинди булуы мөһим – продукциябезнең сыйфаты да шуңа бәйле бит. Эшебез бетон белән тимер-томырны бер өемгә кушу гына түгел. Без үз йорты турында уйлаган һәркемгә хыялын тормышка ашырырга ярдәм итәбез. Ә бу һич тә вактөяк түгел. Начар кәеф белән яхшы нәрсә ясап булмый. Тимер-бетон теләсә нинди таш кына түгел, чөнки ул – гаилә бәхетен корачак, аның нигезен тәшкил итәчәк нәрсә.

ҺӘР ҖИРГӘ БОРЫНЫМНЫ ТЫГАМ

Минем хакта, бөтен җиргә борынын тыга, дип әйтәләр. Чыннан да шулай. Миңа алай җиңелрәк. Мин моны эштәге хәл-әхвәлләрне аңлар өчен эшлим. Әгәр дә берәр нәрсә дөрес булмаса, актив белән җыелабыз да эшне ничек яхшыртырга икәнен уйлыйбыз.

Элекке эшемдә – Эчке эшләр министрлыгы системасында туплаган тәҗрибәм заводта төрле тайпылышларны булдырмаска ярдәм итте. Кешеләргә бу дөньяда икенче мөмкинлек бирелми торган нәрсәләр барлыгын турыдан аңлаттым, сүз эчкечелек һәм урлашу турында бара. Нинди генә бөек һәм алыштыргысыз булсаң да, икенче мөмкинлек булмаячак. Пенсиягә чыгарга ярты ел калган бер кеше урлашкан өчен эштән куылды. Ташламалар, искәрмәләр була алмый.

Минекен түгел, үзләренекен урлыйлар бит. «Әйдәгез, ул акчаны үзегезгә үк сарыф итик!» – дим. Бу төшенчәләрне аңламаган кешеләр табыла. Ләкин коллективның нигезен тәшкил иткән, әхлакый кагыйдәләрне үти торган команда бар. Начар нәрсәдән түгел, яхшыдан үрнәк алырга кирәк.

ЮГАРЫ ХЕЗМӘТ ХАКЛЫ СОҢГЫ САНТЕХНИК ТУРЫНДА

Безнең заводта яшьләр күп. Студентлар өстәмә эшкә киләләр, үзенчәлекле балаларны укытабыз, аларны шефлыкка алабыз. Мин яшьләрнең үз куллары белән башкарылган беренче эшләреннән ләззәт алуын күрергә яратам. Бу киләчәккә өмет уята. Югыйсә блогер һәм тиктокерлардан гыйбарәт бозык буын кешелекне бер 50 елдан соң шундый хәлгә китереп җиткерергә мөмкин ки, ихтыяҗ тугач, аларга соңгы сантехник киләчәк һәм аның кечкенә генә хезмәте дә 100 мең сумга төшәчәк. Бәлки, шул чакта эшче һөнәрләрне кадерли башларлар.

Миңа егетләрнең безгә беренче машинасын сатып алу өчен акча эшләргә килүе ошый. Икенче елны килгәч, тегеләрдән сорыйм: «Машина алдыңмы?» «Алдым!» – дип горурланып җавап бирәләр. Шәп бит!

Безнең максат – яшьләр кулына балык түгел, ә кармак тоттыру.

Бу сүзем студентларга да, махсус интернатларда үскән балаларга да кагыла. Ул балалар баштагы мәлдә үзләрен аларга барысы да нәрсәдер тиеш кебек тота. Ашаталар, керләрен юалар, кайгырталар – алар шуңа күнеккән. Тормышның алай бармавын, аларның инде зур үсүләрен, берәүнең дә бернәрсәне дә кулларына китереп тоттырмаячагын, акрынлап һөнәргә, дөнья көтәргә өйрәнергә кирәклеген аңлатырга туры килә. Ә без ярдәм итәргә әзер.

БУ ӨЛКӘДӘН ЕРАК КЕШЕЛӘР ӨЧЕН

Әзер тимер-бетон плитәдән нинди ис килгәнен беләсезме? Балачактагы дымлы идән исе. Хәтерлисезме? Әнинең балачакта миңа йөземле кекслар пешерүен дә искә төшерә әле ул. Яңа гына пешкән, кайнар, тәмле исле – бер читен сындырып кабасы килә. Менә монда да шундый ук халәт.

Күңелгә хуш булганда, эш җиңел бирелә. Мин бу эшнең фанаты. Бөтен командам шундый. Мин бу командамның булганына бик рәхмәтле, без бер-беребезне таптык, һәм без барыбыз бергә шул кайнар бетон исеннән, шушы эштән ләззәт тоя алабыз. Без барысын да булдырачакбыз. Һәм барысы да тимердәй нык булачак! Т

ПАВЕЛ КОЧНЕВ: «ЦИФРЛАШТЫРУНЫ МАКУЛАТУРА ТАПШЫРУДАН БАШЛАДЫК»

«Союзхимпромпроект» проектлар институты директоры оешманың 70 еллык эш тәҗрибәсен уңышлы файдалану хакындагы фикерләре белән уртаклаша.

– Павел Владимирович, «Союзхимпромпроект» Россия сәнәгать холдинглары проектларын гамәлгә ашыручылар рейтингында иң алда баручылардан берсе. Институт мондый дәрәҗәгә ничек ирешә алды?

– Әлбәттә, иң әүвәл – эшнең сыйфатлы башкарылуы һәм, икенчедән, эшне оештыру ысулы – без ресурслар җитмәгән проектларга бөтенләй алынмыйбыз. Чөнки бу очракта вакытында өлгертеп булмаячак, ялгышлар килеп чыгачак һ.б. Кагыйдә буларак, заказчылар безне аңлый. Без эш күләмен тигезләп бүләбез һәм вакытында өлгертү өчен бөтен көчебезне куябыз. Шуның белән бергә, үзебезнең бу өлкәдә эксперт булуыбызны даими дәлилләп торабыз – үз профилебез буенча барлык форум, конференция, семинарларында спикер сыйфатында катнашабыз һәм тормышка ашырган проектларыбыз турында сөйлибез, мөмкинлекләребезне күрсәтәбез.

– Институтта яшь белгечләр белән зур тәҗрибәле хезмәткәрләрнең нисбәте якынча бертигез. Әлеге баланс ничек саклана?

– Безнең уңышларыбыз – институтның бөтен коллективы тырышлыгы нәтиҗәсе ул. Шул ук вакытта без һәркем өчен эш шартларының уңайлы булуын да кайгыртабыз, чөнки интеллектуаль хезмәт зур көч сарыф итүне сорый. Миңа исә һәр хезмәткәремнең эшкә күтәренке кәефтә килүе һәм шундый ук кәеф белән өенә кайтып китүе мөһим. Моннан тыш, без эш өчен бик яхшы шартлар тудырабыз, безнең институтта хезмәт хакы Казандагы проект оешмалары арасында иң югарылардан берсе.

– Институт үзенең заказчыларына да шулай игътибарлымы?

– Әйе, без клиентларга да нәтиҗәле эш өчен кирәкле бөтен шартларны тудырабыз. Мәсәлән, Кингисеппта «ЕвроХим» өчен объектны проектлаштырганда EPC-подрядчы – Кореянең Daelim инжиниринг компаниясе – объектны җыйнаграк итеп ясауны үтенде. Сәнәгать куркынычсызлыгының стандарт кагыйдәләре буенча әлеге үзгәрешләр рөхсәт ителми иде. Әмма тагын бер инструмент – «Куркынычсызлыкны нигезләү» дә бар бит әле, ул, авария хәлләре хәвефен исәпкә алып, махсуслашкан компанияләр тарафыннан эшләнә һәм сәнәгать куркынычсызлыгы экспертизасын үтә. Заказчы өчен өстәмә чыгым булса да, бу конкрет объект буенча норматив таләпләрен канәгатьләндерә торган проект ясау мөмкинлеге булып тора. «ЕвроХим» белән Daelim безнең тәкъдимгә ризалаштылар, Куркынычсызлыкны нигезләү эшләнде, бу әлеге заводны бүленгән кишәрлеккә сыйдыру мөмкинлеген бирде. Әлбәттә инде, мондый киңәшләрне зур эш тәҗрибәсенә ия компетентлы белгеч кенә бирергә сәләтле.

– Шундый осталыкка ничек ирешелә соң?

– Без даими өйрәнәбез, башкалардан үрнәк алабыз. Хезмәтне оештыру системасын үзгәртәбез, идарәгә яңа инструментлар кертәбез. Мәсәлән, моннан 2 еллап элек нормоконтроль системасын керттек. Моңа кадәр проектлаштыручылар «төрле яклап» нормоконтроль башкара һәм, кызганычка, еш кына бу формаль төстә була иде. Әлеге күчешкә каршы килүчеләр дә табылды, шактый вакыт кирәк булды. Хәзер исә система эшли, сыйфат сизелерлек яхшырды, хезмәт чыгымнары шактый кимеде.

– Быел институт оешуга 70 ел булды. Предприятиенең цифрлы төзелешкә һәм гомумән цифрлаштыруга карашы ничегрәк?

Фотолар «Союзхимпромпроект» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

– Бик әйбәт. Безгә чыннан да 70 яшь, әмма бай тәҗрибәбез шуңа өйрәтте: заманча технологияләрдән файдаланучылар гына алдынгы була ала. Без үзебездә цифрлы инструментларны актив кертәбез. Электрон документлар әйләнешенә күчтек, һәр проектчы өчен 2 монитор куйдык – сызым һәм документациянең икесен бергә кәгазьдә түгел, экранда күреп булсын өчен. Электрон документлар әйләнешенә күчү процессында макулатура тапшыру бәйгесе үткәрдек. Предприятие буенча барлыгы 12 тоннадан артыграк кәгазь җыйдык. Киләчәктә кимендә шулкадәр үк кәгазьне янга калдырачакбыз. Моннан тыш, цифрлаштыру клиент белән мәгълүмат алмашын яхшырта. Кемнең кайчан һәм нинди документ бирүе, әлеге документның килешенгән-килешенмәгән булуы хакында мәгълүмат системада саклана.

> Кадерле хезмәттәшләребез, безнең коллектив – зур тату гаилә ул, анда һәркем бер-берсен аңлый, хөрмәт итә, кадерен белә һәм ярата. Сезгә моның өчен зур рәхмәт! Безнең команда гел шундый яшь һәм шундый тәҗрибәле булып калсын. Сөенеч һәм канәгатьләнү хисе бирә торган кызыклы һәм дәртле хезмәт телим. Юбилеебыз котлы булсын!
>
> **Павел Кочнев,«Союзхимпромпроект» проектлар институты директоры**

– Төзелешне цифрлаштыруны тизләтү өчен нәрсә эшләргә кирәк?

– Безнең эш тәҗрибәсеннән чыгып, шуны әйтер идем: инжиниринг оешмалары (аларга без дә керәбез) әлеге процессның драйверлары булып тора. Биредә яңа инструментлар шактый тиз үзләштерелә, документлар ясауны һәмраслауны тизләтүгә ихтыяҗ бар. Ә менә подрядчылар белән алай тиз генә булмый әле. Хәзер безнең 2D һәм 3D форматларындагы барлык цифрлы мәгълүматларыбызны подрядчылар күбесенчә тикшерү өчен генә файдалана. Ә инде нәтиҗәгә ирешү, ягъни Госстройнадзор яки Ростехнадзор органнарыннан уңай бәяләмә алу өчен, подрядчыга элеккечә үк йөзләрчә папка кәгазь документ тапшырырга кирәк. Чылбырда катнашучыларның барысының да цифрлы коммуникацияләргә күчүе һичшиксез тармакның тулаем цифрлашуын тизләтер иде.

– Цифрлаштыру импортны алыштыру бурычларын хәл итүгә булышамы?

– Безнең очракта, булыша. Моннан берничә ел элек без нефть химиясендәге җитештерү процессларын мәгълүмати модельләштерүне үзләшерә башлаган идек. Бүгенге санкцияләр шартларында җитештерүчеләр чималны эшкәртү процессында компонентларны алыштырырга, традицион импорт җиһазлары булмаганга, аларны кайтарта алмаганга, яңа предприятиеләр ачарга мәҗбүр. Шунлыктан безнең цифрлы модельләштерү юнәлешенә ихтыяҗ зур. Шуның нәтиҗәсендә без СИБУР, «ЕвроХим», «Русхимгаз», «Лукойл» кебек компанияләрнең колачлы инновацияле проектларында катнашабыз.

– Тармактагы трендларны, институтның казанышларын һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып, «Союзхимпромпроект» якындагы бер-ике елда нәрсәләр планлаштыра?

– Без һичшиксез мәгълүмати модельләштерү юнәлешен үстерүне дәвам итәчәкбез. Шуның белән бергә, безгә хәзер көньяк-көнчыгыш илләрдән, Иранан килгән партнерлар катнашында гамәлгә ашырыла торган зур проектлар да кызыклы. Шуңа күрә без хезмәткәрләр өчен чит тел өйрәнү курслары ачтык, беренче 3 төркемне укытабыз инде. Моннан тыш, компетенция һәм эшләребезнең дәрәҗәсе бердәй югары булсын өчен, без субподрядчылар белән үзара хезмәттәшлекне яхшыртуны планлаштырабыз. Бу планнарның бер өлеше генә, әмма иманым камил, безнең институт ниятләгән һәр нәрсәне тормышка ашырыр.

ХАТЫН-КЫЗЛАР БИЗНЕСЫ: АВЫР ХЕЗМӘТ КЕНӘ ТҮГЕЛ, ГҮЗӘЛЛЕК ТӘ

Моннан 15 ел элек Наталья Кукушкина «Төзүчеләр урамы» дигән компания оештырган, бүген ул Татарстанда һәм аннан читтә дә төзү материаллары – кирпеч, блоклар, түбә материаллары, клинкер, декоратив таш, брусчатка сату буенча әйдәп бара һәм 50 зур завод белән хезмәттәшлек итә. Компания продукциясен файдаланып, инде 5 миллион квадрат метрдан артыграк шәхси торак төзелгән.

Натальяны күргәч, аның бизнеста шулкадәр катлаулы чорлар кичергән кеше икәненә ышанып та булмый. Тик ул иң кыен чакларда да үзенә ышанычын җуймаган, эшен туктату турында фикер беркайчан да башына килмәгән. Әлеге юлда ул хатын-кыз буларак шәхси трансформация кичергән һәм, эшкуар ханымнарның нинди хисләр кичерүен, нинди сынауларга дучар булуын яхшы аңлаганга, әле күптән түгел генә остазлык эшен дә башлаган.

Бүген Наталья үзен искиткеч гармонияле кеше итеп тоя, аның бөтен нәрсәгә вакыты җитә: гаилә, балалар, бизнес, үзен камилләштерү эше,

Фотолар Наталья Кукушкина архивыннан. РЕКЛАМА

иҗтимагый башлангычлар. Милләте буенча мари булганга, ул Казандагы марилар җәмгыяте эшчәнлегендә дә катнаша. Һәр иртәсен саф һавада физик күнегүләр ясаудан башлый.

Төзүчеләр көне алдыннан ул «Татарстан» журналына тормышны яратуы, бизнестагы перспективалары һәм рухи кыйммәтләре хакында сөйләде.

– Наталья, сез оештырган компаниягә икътисадтагы төрле чорларга карамастан 15 ел буе тотрыклы эшләүгә нәрсә ярдәм итә? Аның киләчәктәге үсеш юнәлешләре нинди?

– Үз компаниямне оештыручы һәм аның директоры буларак минем позициям – бурычларны хәл иткәндә үз сүземдә нык тору, даими өйрәнү. Нәкъ менә даими яңа белем алганга күрә, без команда белән икътисадтагы тотрыксыз чорларны үтә алдык, компаниядәге кыенлыкларны җиңдек. Эзләсәң, теләсә нинди авыр хәлдән дә чыгу юлын табып була. Бу үсеш, киңәю, шәхси клиентлар арасында да, зур компанияләр арасында да клиентлар базасын арттыру өчен үзенә бер төрле двигатель булып тора. Колачлы проектларны республика күләмендә гамәлгә ашыру да хәлебездән килә. Хәзерге вакытта бездә заказчы таләбе белән теләсә кайсы объектны тулысынча материаллар белән тәэмин итү өчен кирәкле бөтен нәрсә дә бар.

– Быел компания 15 еллыгын билгеләп үтә. Оештыручы буларак, сез аның бүгенге халәтеннән канәгатьме? Нәрсә күбрәк булды – җиңүләрме, уңышсызлыкармы? Аларны ничек җиңеп чыктыгыз?

– Беренче чиратта, мин үзебезнең эшебезне дәвам итүебездән канәгать. Компанияләрнең тиз арада таркалганнары да күп бит. Статистика буенча, беренче 10 елда бизнесларның нибары 10 проценты сакланып кала, 15-20 еллык эшчәнлеккә ирешү өчен исә зур тырышлык һәм үҗәтлек таләп ителә, бигрәк тә тотрыксыз Россия икътисады шартларында.

Безнең компания тарихында төрле чорлар булды: үзебезгә хезмәт күрсәткән банк банкротлыкка чыгу аркасында 35 миллион сумның әйләнештән алынуы да, бер хезмәткәребезнең намуссызлыгы да, ябылу перспективасы да. Әмма компания үсеше дәвамында мин һәрвакыт якыннарымның һәм иремнең (бу безнең уртак бизнесыбыз) куәтле ярдәмен тойдым. Компанияне коткару өчен күп санлы судлар аша да үттек, иремә барысына да җентекләп төшенергә, суд утырышларында чыгыш ясарга туры килде – мин аның үз сүзендә нык торуына, үҗәтлегенә, кыюлыгына соклана идем. Безнең өчен теләсә нинди хәлдә дә бер-беребезгә терәк булу сулыш алу кебек үк табигый. Гәрчә кайбер мәсьәләләрне хәл итүгә еллар һәм күп көч сарыф ителсә дә, сынмадык, сыгылмадык.

Бүген инде без тотрыклы компания, кешеләргә булышабыз, үз эшебезне яратабыз һәм рәхмәтле клиентларыбыздан җылы сүзләр ишетүгә бик сөенәбез. Уңышсызлык теләсә кайсы бизнеста да булырга мөмкин, тиз арада шуны гына аңлый алмыйсың: мондый мизгелләрдә көч чыганагы – синең эчке рухи терәгең, илаһи көчләр белән бәйләнешең ул. Әгәр моңа белем, технологияләр, идарә инструментларын да кушсаң, яхшы нәтиҗәгә ирешергә мөмкин. Моны аңлаганга, даими укыйм, өйрәнәм, бизнесымны камилләштерүне кайгыртам.

– Сез үзегездәге ихтыяр көче, көчле холыкны һәм хатын-кыз нәзакәтлелеген ничек яраштыра аласыз?

– Ихтыяр көче, холкым гел нык иде, ә менә нәзакәтлелеккә ирешү юлларын эзләргә туры килде. Бу моннан 9 ел элек, беренче балам – улым дөньяга килгәч уйландырды. Шул чакта мин гаилә һәм бизнесны яраштыру, тормыштан да, үзеңнән дә ничек канәгать булу хакында фикерли башладым. Шуны аңладым: гаиләдә бер-береңә һәм үзеңә мәхәббәт, хөрмәт мохите тудырудан башларга кирәк. Эзләндем,

өйрәндем. Хәзер төгәл беләм: хатын-кыз һәм төзелеш тармагы үзара яраша ала. Алай гына да түгел, хатын-кыз төзелеш эшенә гүзәллек, эстетика, әдәплелек алып килә, социаль асылга игътибарны арттыра.

Еш кына клиентлар, тышкы кыяфәтемне күргәч, техник сораулар биреп, мине тикшерә башлый. Тик мин инде моңа күптәннән игътибар итмим, саннар һәм исәпләүләр – минем көндәлек хезмәтем. Гомумән, күпләр бизнестагы хатын-кыз нәзакәтлелегенә шикләнеп карый. Әмма нәкъ менә шунда республикага һәм бөтен дөньяга файда китерерлек куәт тупланган да инде.

– Сез күптән түгел остазлык эшенә керешкәнсез. Кемнәр өчен ул, асылы, максаты нәрсәдә?

– Ул эшкуарлар өчен. Компания хуҗасы буларак мин үзем катлаулы юл үттем – бик кыен әхлакый халәттән, хәл ителми торган диярлек бурычлардан тулы гармония, тынычлануга кадәр. Бизнестагы кыенлыклар аркасында, елаган чакларым күп булды, төшенкелек халәтендә дә эшләдем, ике декрет ялым вакытында да өйдә утырмадым – нәкъ шул мизгелләрдә эшемне коткару юлларын табарга кирәк булды. Шул чакта минем кемнеңдер ярдәмен тоясым, җылы сүзен ишетәсем килде. Шуларның барысын да кичергәннән соң, ниһаять, башкача да мөмкин икәнен аңладым. Үзгәреш юлына бастым. Бизнес һәм тормышның ничек шатлык, бәхет китерүен үземдә тойдым.

Аннары инде башкаларга да булышасым килде. Әгәр хатын-кыз йөк атына әйләнә икән, бу начар тәмамланачак. Аның эше дә гөрләп барсын, үзе дә гүзәлләнә генә барсын өчен нишләргә? Еш кына сайларга туры килә: йә җәмгать эшчәнлеге, йә эш, йә гаилә. Мин боларның барысын да бергә бик җиңел яраштырам, чөнки шуны аңладым: син үзең бәхетле икәнсең, әйләнә-тирәдәгеләр дә бәхетле. Башкача була алмый.

– Сезнең тагын бер иҗади мавыгуыгыз – Казандагы марилар җәмгыяте белән хезмәттәшлек итү, аның чараларында катнашу. Сезне, бизнес кешесен, милли киемнәр киеп, шәһәрдән әллә ничә чакрымнардагы чараларга барырга нәрсә мәҗбүр итә?

– Чыннан да, Казан шәһәре марилар җәмгыяте җитәкчесенең урынбасары мин. Милләтем буенча мари, җәмгыятькә 6 яшемнән бирле йөрим – әти-әнием беренче тапкыр алып килгәннән бирле. Мин үз халкымны бик яратам, марилар мәдәнияте һәм гореф-гадәтләрен саклауга булышуны үземнең миссиям дип саныйм.



Грантлар булдыруга, өлкәннәр һәм балалар өчен чаралар оештыруга хәлкадәри ярдәм итәм. Милли мәдәниятне саклаганда, без яшь буында әхлаклылык тәрбиялибез. Әлеге юнәлештән иситкеч рәхәтлек алам, мари кызы булу, мари киемнәреннән йөрү минем өчен зур горурлык ул.

– Бүген гаилә кыйммәтләрен ныгыту турында күп сөйлиләр. Бу тема сезгә якынмы? Әлеге төшенчәгә сез үзегез нинди мәгънә саласыз?

– Әлбәттә, бу бит – терәк. Гаиләм, ирем, әти-әнием миңа иң кыен чакта ярдәм итте, көч бирде. Гаилә – син үзең дә бәхетле булган, башкаларны да бәхетле иткән учак ул. Анда мәхәббәт хөкем сөрергә тиеш. Нык гаиләдән башка уңышлы бизнес төзеп булмый. Гаиләдә тынычлык булмау рәхәтләнеп эшләргә дә комачаулый. Бер-береңне ярату, ихтирам итү, күп вакытны бергәләп үткәрү балаларны уңышлы шәхес итеп тәрбияләүдә дә бик мөһим.

– Ничек үз эшеңне башларга һәм гармониядә яшәргә? Бу мөмкинме? Үз фикерегезне әйтегез әле.

– Әлбәттә, мөмкин. Мин инде күп еллар буе планлаштыру белән шөгыльләнәм, вакытымны бизнеска да, гаиләгә дә, иҗтимагый эшчәнлеккә дә бүләм. Вакыт үзең телгән бөтен нәрсәгә җитәргә тиеш. Шунлыктан остазлык проектымда төп принцип мондый булачак: башта үзеңне бәхетле шәхес итеп тәрбиялә, аннары гына белгәннәреңне башкалар белән уртаклаш.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU

ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫ:
ИМИНЛЕК ХАКЫНА ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

Рамил Батыршин, «Торак традицияләре» Торак-туплау кооперативы проекты координаторы, – партнерлык (ислам) финансларының потенциалы турында

Мөселман дөньясы илләре белән сәүдә-икътисадый мөнәсәбәтләр үсеше, гел үзгәреп торган вазгыять, ниһаять, күптән түгел Башкортостан, Татарстан, Дагыстан һәм Чечня территорияләрендә партнерлык (ислам) финанслары буенча эксперимент үткәрү турында Дәүләт Думасы тарафыннан кабул ителгән закон – вакыйгалар логикасы шуны раслый: илебез хокукый кырына һәм икътисадына финанс югалтулары ягыннан минималь куркынычка ия яңа инструментлар системалы рәвештә интеграцияләнә башлады. Тәкъдим, гадәттәгечә, ихтыяҗ белән бәйле.

Партнерлык финанслары белән кызыксынуның көчәюенә китерүче факторларның берсе – бизнеста финанс куркынычларын һәм табышны инвесторы белән бүлешү юлын аңлы рәвештә сайлаган эшкуарларда партнерлык принципларына нигезләнгән финансларга ихтыяҗның артуы. Торак, автомобиль, көнкүреш техникасын партнерлык принципларына нигезләнгән бүлеп түләү ысулы белән сатып алырга теләүче халык тарафыннан да ихтыяҗ бар. Әлеге факторлар шуңа күрә финанс базарының эре уенчыларында ислам финанс инструментларына кызыксынуны арттырырга ярдәм итә.

Аларның кайберләре партнерлык продуктларын сатуда күпмедер күләмдә тәҗрибә туплады инде, икенчеләре исә әлегә теләк кенә белдерә, бу эшкә сак карый.

Барлык санап үтелгән аспектлар, бердәм концепциягә әйләнеп, Россиянең үсеш стратегиясенә кереп китә һәм, гамәлдәге икътисад моделен диверсификацияләү хисабына, илнең икътисадый иминлеген арттыра ала. Партнерлык финанслары һәм икътисадый куркынычсызлык арасында нинди бәйләнеш бар соң? Күпләр тарафыннан ислам финанслары халыкның билгеле бер катламы өчен көнүзәк мәсьәләләрне хәл итү (мәсәлән, торак, автомобиль һ.б. сатып алу) коралы буларак кабул ителә. Шулай ук еш кына ислам финансларын мөселман илләреннән инвестицияләр җәлеп итү өчен кирәк дип саныйлар. Икесе дә дөрес һәм мөһим. Ләкин партнерлык финансларының тагын бер әһәмиятле ягы бар, бу – гамәлдәге икъ-

Фото: Әхмәт Шакиров, pxhere.com

тисад моделен диверсификацияләү мөмкинлеге.

Сер түгел, инфляция – процентлар алына торган традицион кредитлау нәтиҗәләренең берсе. Кредитлар зур күләмдә бирелгәндә, «куык» үскәннән-үсә бара, акча арзаная, халыкның икътисадый байлыкларны куллануы арта, ә чынлыкта җитештерелгән байлык күләме кулланучының кредит акчаларын үстерергә өлгерми. Шуңа күрә товар һәм хезмәт күрсәтүләргә бәя арта, инфляция туа. Югары инфляция, үз чиратында, сатып алу сәләте кимү белән бергә бара...

Җитештерүне процентка кредитлауның да йомшак яклары бар, монда баланс бозыла, чөнки финансист һәм бизнес арасында эшкуарлык куркынычлары бүленмәгән. Әйтик, финансист, проектның нәтиҗәсе нинди булуга карамастан, барыбер табыш ала. Алынган табыш займ суммасын да кайтара, кагыйдә буларак бәясе буенча кредит суммасыннан артыграк булган залог табышын кайтаруны да тәэмин итә. Бу факт финанс институтларын икътисадның реаль секторыннан читләштерә, аларны бизнес нәтиҗәләре белән кызыксындырмый, чөнки аның үзенең керем алуы гарантияләнә.

Партнерлык финансларында исә, мәсәлән, «мушарак» һәм «мудараба» контрактларында күз алдында тотылганча, якларның табышы һәм ихтимал булган югалтулары реаль сектор эшенең нәтиҗәләренә бәйле. Бу проектларны, бизнес партнерларны сайлаганда саграк, җитдирәк булырга мәҗбүр итә һәм барлык кызыксынган якларның иҗади, килешеп эшләвенә ярдәм итә. Ә куллану ихтыяҗларын финанслаганда үзара ярдәм кассасы (мөлкәттә партнерлык) принцибын куллану икътисадка илебез инвесторының акчаларын җәлеп итәргә мөмкинлек бирә, реаль сектор һәм финанс активлары арасында баланс та саклана, чөнки өстәмә акча эмиссиясе таләп ителми. Димәк, инфляция тумый.

Нәтиҗәдә товарлар җитештерү, хезмәтләр күрсәтү һәм җәмгыять мөмкинлекләрен арттыру пропорциональ рәвештә үсә, кискен ясалма сикерешләр һәм икътисадый кризислар рәвешендәге артка тәгәрәүләр булмый. Барлык субъектларның сатып алу сәләтенә уңай йогынты ясый торган икътисадый тотрыклылык, базардагы тынычлык – инвесторларны җәлеп итү өчен менә дигән шартлар. Акча үзеннән-үзе товар булудан туктагач, өч мөһим параметр – бурычлар, керемнәр һәм җитештерү үсешенең тизлеге тигезләнә башлый. Моның файдасы җәмгыятьнең барлык әгъзалары өчен дә күренеп тора, чөнки ул һәр аерым кешенең һәм тулаем җәмгыять мәнфәгатьләре арасында баланс булдырырга мөмкинлек бирә.

ТАТМЕДИА

shop.tatmedia.ru

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АҖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Кремльдән Кремльгә **нинди** юл алып бара

Юнган балыкны **кайда** тәмләп карарга була

Милли сәнгать **кемнәрдән** башка үсә алмый

Хезмәт батырлыгы шәһәре фронтка **ничек** булышкан

Фото: Александр Ефремов, ТР Раисе матбугат хезмәте

«ЕФӘК ЮЛЫ»: СТАРТТАН – ФИНИШКА, КРЕМЛЬДӘН КРЕМЛЬГӘ КАДӘР

«Ефәк юлы» Халыкара раллиен катнашучылар да, тамашачылар да, бик кызык һәм дулкынландыргыч булды, дип искә ала. «Татарстан» фотохәбәрчесе Александр Ефремов фотосурәтләрендә дә әлеге «ефәк» көннәрнең иң кызыклы кадрларын тәкъдим итәбез.

SILK WAY RALLY 2023

МАРШРУТ

ДАТЫ / КИЛОМЕТРАЖ

ДАТА	Nº	ЭТАП	СПОРТИВНЫЙ МАРШРУТ						СЕРВИСНЫЙ МАРШРУТ
			LL A	SS A	LL B	SS B	LL C	ВСЕГО	ВСЕГО
5.07.2023 среда		КАЗАНЬ. АДМИНИСТРАТИВНЫЕ И ТЕХНИЧЕСКИЕ ПРОВЕРКИ							0
6.07.2023 четверг	0	КАЗАНЬ. АДМИНИСТРАТИВНЫЕ И ТЕХНИЧЕСКИЕ ПРОВЕРКИ. ТОРЖЕСТВЕННЫЙ СТАРТ.	0,00	0	0,00			0,00	0
7.07.2023 пятница	1	КАЗАНЬ - УФА	48,66	142,00	415,36			606,02	523
8.07.2023 суббота	2	УФА - МАГНИТОГОРСК	287,79	245,83	37,45			571,07	346
9.07.2023 воскресенье	3	МАГНИТОГОРСК - МАГНИТОГОРСК	37,76	345,77	67,89			451,42	0
10.07.2023 понедельник	4	МАГНИТОГОРСК - ОРЕНБУРГ	131,32	118,14	41,46	75,69	172,38	538,99	437
11.07.2023 вторник	5	ОРЕНБУРГ - САМАРА	67,06	226,41	263,81			557,28	431
12.07.2023 среда	6	САМАРА - САРАТОВ	137,66	136,24	78,66	125,98	143,66	622,20	473
13.07.2023 четверг	7	САРАТОВ - ВОЛГОГРАД	80,59	162,50	51,58	267,26	33,47	595,40	393
14.07.2023 пятница	8	ВОЛГОГРАД - ЛИПЕЦК	91,68	314,12	367,06			772,86	655
15.07.2023 суббота	9	ЛИПЕЦК - МОСКВА	101,72	117,60	293,92			513,24	500
ИТОГО			984,24	1808,61	1 617,19	468,93	349,51	5228,48	3758

ДОРОЖНАЯ СЕКЦИЯ	2950,94	3758
СКОРОСТНОЙ УЧАСТОК	2277,54	
ОБЩАЯ ДИСТАНЦИЯ	5228,48	

БОЛЬШЕ ЧЕМ ГОНКА, **ЯРЧЕ** ЧЕМ ПРИКЛЮЧЕНИЕ

6 июль көнне Казан Кремле янында

внедорожник, мотовездеход, грузовик, квадроцикл һәм мотоциклларда

23 илдән

98 экипажга

старт бирелде.

«КАМАЗ-мастер» командасыннан Дмитрий Сотников, Андрей Каргинов, Эдуард Николаев, Сергей Куприянов һәм Хоу Хоннин идарәсендә

5 экипаж

катнашты.

Маршрут Россиянең

13 төбәге аша узды.

КАДЕРЛЕ ДУСЛАР, БУ ФАНТАСТИК ЧАРАДА, ОЗАТУ ФОРМАСЫНДАГЫ ӘЛЕГЕ ОЧРАШУДА КАТНАШУ МӨМКИНЛЕГЕ ӨЧЕН БИК ЗУР РӘХМӘТ. КЫЮ КЕШЕЛӘРНЕ, ИРЛӘРНЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, БУ ЯРЫШТА КАТНАШАЧАК ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫ ДА ОЗАТУ ЧАРАСЫНДА КАТНАШУ МӨМКИНЛЕГЕ ӨЧЕН! КАЙБЕР СПОРТ ӘҺЕЛЛӘРЕ, ӘЛЕГЕ ДАИРӘДӘГЕ КАЙБЕР ЭШЛЕКЛЕЛӘР СПОРТНЫ СӘЯСӘТЛӘШТЕРЕРГӘ ТЫРЫШСА ДА, УЛ СӘЯСӘТТӘН АЕРЫМ БУЛЫРГА ТИЕШ.

Сергей Лавров, Россия тышкы эшләр министры

Командалар

3 сәгать поясын,
5 247 чакрым ара
узды, шул исәптән аның
2 277 чакрымы –
тизлекле участоклар.

«Ефәк юлы» Халыкара раллие Мәскәүдә тәмамланды.

«БЕЗНЕҢ РЕСПУБЛИКА – АВТОМОБИЛЬ ТӨБӘГЕ, БЕЗДӘ ТЕХНИК СПОРТ ТӨРЕНӘ ҺӘРВАКЫТ ЗУР ИХТЫЯҖ БУЛАЧАК. БӘЙРӘМ КУНАКЛАРЫНА, РАЛЛИДА ЯРЫШУЧЫЛАРГА – КАТНАШКАННАРЫ, КАЗАНЛЫЛАРГА КУНАКЧЫЛЛЫКЛАРЫ ӨЧЕН РӘХМӘТЕМНЕ ҖИТКЕРӘСЕМ КИЛӘ!

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Рәисе

редакция кухнясы

ЯКУТ ЖУРНАЛИСТЛАРЫ СТРОГАНИНА БЕЛӘН СЫЙЛЫЙ

Татьяна Вафина

«Татарстан» редакциясе кухнясы тарихындагы иң тиз әзерләнә торган ризыктан без Якутиядә, «Сахамедиа» республика мәгълүмат-нәшрият холдингында авыз иттек. Генераль директор урынбасары Чокуур Гаврильев белән финанс директоры Татьяна Мордовская, татарстанлыларны Төньяк халыкларының иң танылган ризыгы белән сыйлаганда, безнең үзебезне дә аны әзерләргә өйрәтте.

Фото: Александр Ефремов

КАТЫ СУЫК ҺӘМ ҮТКЕН ПЫЧАК

– Бу ризык өчен бары тик балык һәм бик үткен якут пычагы гына кирәк, – дип аңлата безгә Чокуур, кыныннан эш коралын чыгара-чыгара. – Балык туңдырылган булырга тиеш. Менә аны шулай ашыкмый гына юнабыз, ул матур бөҗра булып киселеп төшә. Кирәк кадәр юганнан соң, тәлинкәгә ике кат чиста кәгазь бите җәябез (кәгазь җылыны начар үткәргәнгә, балык кисәкләре озаграк эреми торачак), шуңа балыкны салабыз да, табынга куябыз.

– Алданрак исә «манырлык» әзерләп куярга кирәк, – дип өсти Татьяна. – Бусы тагын да ансатрак. Тоз белән төелгән кара борычны тигез микъдарда кушу гына

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- Чир балыгы – 1 данә;
- Тәменчә тоз, борыч.

– Юнып ашау өчен бөтен балык та яраклы түгел. Ә бары тик чир, нельма, муксун һәм омуль гына ярый. Кыскасы, төньяк балыклары.

– Аның тышкы кыяфәте дә бик матур, – дип, Чокуур безгә телефоннан үзе тоткан балыкның бөтен ракурслардан да төшерелгән фотоларын күрсәтә... Карда, боз өстендә ята: зур балык, тәңкәләре кояшта җемелди, борыны галәмәт... – Мондый чирның авырлыгы 15 килограммга җитәргә мөмкин.

сорала. Яки кушмыйча, икесен янәшә салып кына кую тагын да яхшырак. Балык кисәкләрен башта тозга, аннары борычка манасың да кабасың... Яисә киресенчә, кемгә ничек ошый инде.

– Бары шул гынамы?

– Әйе, бик гади, – дип ризалаша сыйлаучыларыбыз. – Әмма!

– Берничә шарт бар, – дип кисәтә Чокуур. – Юнып ашау өчен бөтен балык та яраклы түгел. Ә бары тик чир, нельма, муксун һәм омуль гына ярый. Кыскасы, төньяк балыклары. Бүген безнең табында – чир. Аның тышкы кыяфәте дә бик матур, – дип, Чокуур безгә телефоннан үзе тоткан балыкның бөтен ракурслардан да төшерелгән фотоларын күрсәтә... Карда, боз өстендә ята: зур балык, тәңкәләре кояшта җемелди, борыны галәмәт... – Мондый

чирның авырлыгы 15 килограммга җитәргә мөмкин.

– Чыннан да бик матур!

ИСКИТКЕЧ ТӘМЛЕ

– Әле ул искиткеч тәмле һәм вак сөяге бөтенләй юк, – ди Татьяна. – Карап торышка чир майлы күренсә дә, аның ите диетик, чөнки 100 граммында нибары 86 ккал гына. Төньяк балыкларында гомумән файдалы матдәләр бик күп: аксым, майлар, аминокислоталар, витаминнар, минераль элементлар, туендырылмаган май кислоталары. Мондый балыкны чи килеш ашаганда, кеше аларның барысын да тулысынча үзләштерә.

ТЫНГАН ТҮГЕЛ, ТЕРЕ

– Ягъни безнең Идел, Чулман, Мишә, Нократта чир, нельма, муксун һәм омуль яшәми икән, без үзебездә юнылган балык ашый алмыйбыз дигән сүзме?

– Билгеле, юнылган сыйны ялангач балык (җиз мыек), пелядь, хәтта чуар балыктан да ясап була. Сезнең балыклардан авыз иткәнем юк, елгаларыгызда нинди балык булуын белмим, бәлки, алардан да буладыр, – ди Чокуур, Урта Идел буенда яшәүчеләрдә бераз өмет уятып. – Монда иң мөһиме – кагыйдәләрне төгәл үтәү. Строганина әзерләү өчен «йоклаган» (ягъни ятьмәдә үлгән) балык ярамый, бары тик «тере»се генә яраклы. Кунакны җансыз балыктан әзерләнгән тәгам белән сыйлау мыскыл итү санала.

Аннары безне «тере туңдырылган балык» әзерләргә өйрәттеләр. Әгәр сез мондый вәхшилекләргә күнеккән балыкчы түгел икән, бу ысул шактый аяусыз тоелыр: тоткан балыкны башы белән каты итеп бозга бәрергә кирәк. Аннары егерме минутлап суыкта «ял иттерәләр». Аннан соң бераз йомшартып, турайталар һәм 30 градустан да суыгракта туңдыралар. 10-12 сәгатьтән соң балыкны юнып сыйланырга була. Балыкны берничә тапкыр эретеп туңдырырга

һич ярамый – мондыйдан юнылган тәгам әзерләү катгый тыела, ул тәмсез булачак.

ИҢ ШӘП «ТУҢДЫРМА»

Безнең табындагы матур божралар итеп юнылган чир туңдыруның алдарак санап кителгән барлык баскычларын да үткәнгә охшаган: ул «тынмаган», «бозга шәпләп бәрелгән», «суыкта ял иткән», «йомшартып, турайтылган», бер тапкыр да кире эретеп туңдырылмаган... Гомумән, бик дөрес әзерләнгән якут деликатесы.

Безнең кебек үк кайчандыр төньякның әлеге могҗизалы ризыгын татып караган һәм үз тәэсирләрен кәгазьгә язып калдырган элгәрләребезнең фикере белән танышыр өчен, моннан да шәбрәк вакытның булуы мөмкин түгелдер.

Мәсәлән, төньякны өйрәнүче галим, булачак адмирал Фёдор Матюшкин, шагыйрь Пушкинның лицейдагы дусты, 1820 елның октябрендә Среднеколымскидан Царское Село лицее директоры Егор Антонович Энгельгардтка болай дип язган: «Туңган балык (бигрәк тә чөгә) пешкәненә яки кыздырылганына караганда күпкә тәмлерәк икән. Берәр вакыт сез дә юнылган балык ашап карагыз. Ул бик тәмле, ә менә тоз, борыч һәм серкә белән ашаганда, тагын да сыйфатлырак була. Строганина – иң шәп туңдырма!»

Матюшкинның һәр сүзен хуплыйбыз!

НИЧЕК ЮНЫРГА

Строганина әзерләүдә иң кыены – аны юну. Чокуур моны бик оста эшли, божралар бик җиңел бөдрәләнеп коела тора.

– Кулда эремәсен өчен, балыкны койрыгыннан тастымал белән тоталар, – дип өйрәтә Чокуур. – Һәм, шумасын өчен кытыршы киндер җәелгән өстәлгә башын терәп, йөзгечләрен кисеп алалар. Аннары бик үткен пычак белән, май катламын зарарламаска тырышып, тиресен чистарталар. Башта аркасын һәм корсагын юналар, аларны аркылыга кисәләр. Яки корсагы һәм аркасында 1,5–2 сантиметрлы кисемнәр ясыйлар һәм бер кискәндә үк койрыгыннан башына кадәр юнып төшерәләр. Бу иң тәмле җире, шуңа аны иң аска куеп калдыралар һәм иң соңыннан ашыйлар.

Арка ягыннан башта койрыгыннан башына кадәр берничә эре кисәк юнып төшерелә, аннары сөякнең ике кырыеннан, һәркайсында кызгылт май катламы калырлык итеп, телемнәр теленә. Юнылган ярымбожралар, пөхтәләп, тәлинкәгә өеләбара.

– Балыкны алдан ук, кунаклар килгәнче юнырга һәм салкынга куеп торырга

– Кулда эремәсен өчен, балыкны койрыгыннан тастымал белән тоталар, – дип өйрәтә Чокуур. – Һәм, шумасын өчен кытыршы киндер җәелгән өстәлгә башын терәп, юна башлыйлар...

Юнылган балык җылыта да, туендыра да, көч тә бирә.

«Индигирка» салатыннан да авыз иттек – туңдырылган балык шакмаклары суган, тоз-борыч, серкә һәм көнбагыш мае белән телне йотарлык тәмле иде.



Якутиядә өчпочмак балык һәм дөгедән пешерелә.

ярамый – тәме бозыла, – дип өсти тагын бер язылмаган кагыйдәне Татьяна.

НИЧЕК АШАРГА

Юнылган балыкны кул белән ашыйлар, шуңа башта кулны яхшылап юарга кирәк. Иң алдан өстәге «йомычкалар» алына. Аларны ашап бетергәнче, астагы майлы кисәкләргә сузыла күрмә! Әгәр әлеге «җинаятьтә» бала тотылган икән – кулына сугачаклар. Бу – горефләрне белмәүче кунакларга гына кичерелә торган нәрсә.

Юнган балыкны дөрес ашауның тагын берничә кагыйдәсе бар:

– аңа кадәр бернинди салат һәм кабымлык ашамыйлар;

– аның белән сыйланганнан соң кайнар чәй эчмиләр. 15–20 минуттан соң гына кайнар чәй эчәргә рөхсәт ителә, алайса температуралар сикерешеннән тешләр бозылырга мөмкин;

– бик кечкенә кисәкләрне тешләп алып ашарга кирәк.

ТУҢУДАН ИҢ ШӘП ЧАРА

«Татарстан»га юнылган балыкны тәүге тапкыр 36 градуслы эсседә ашарга насыйп булды. Әйе-әйе, Мәңгелек туңлык патшалыгында да мондый эссе көннәр булгалый кайчак! Чир эчке әгъзаларны бик рәхәт суытты һәм кышкы чана шуу, кар бәрешү, тимераякчаңгыларны искә төшерде... Суык, бәке, саф һавалы чыршы урманы һәм яңа яуган кар исе килеп китте...

Юнылган балыкны суыкта ашаучылар исә әлеге майлы ризыкның өшегән юлчыларны никадәр тиз җылытуын яхшы белә. Сыйланганнан соң берничә минут үтүгә, бик җылы булып китә. Рус әдәбияты классигы Валентин Распутин, Русское Устьеда (Аллаих олысындагы авыл) булганнан соң, болай язган: «Юнылган балык җылыта да, туендыра да, көч тә бирә. Сүздә генә түгел, чынлап җылыта – моның өчен аны суыкта ашап карау җитә! Балык майлы, калорияле – сүнгән учакка ыргытылган утын кебек организмны шундук җылыта».

«ИНДИГИРКА»

Без шулай ук юнылган балыктан ясалган «Индигирка» салатыннан да авыз иттек – туңдырылган балык шакмаклары суган, тоз-борыч, серкә һәм көнбагыш мае белән телне йотарлык тәмле иде!

Исерткеч эчемлекләр табынына мондый кабымлыкны һәм «Балыкны этләр генә аракысыз ашый» дигән әйтемне XIX гасыр уртасында рус сәяхәтчеләре уйлап тапкан, диләр.

Әмма әлеге әйтем Якутиягә бер дә туры килми. Бирелә алкоголь белән шаярмыйлар. 50 градус суыкта исерсәң, өеңнән ике адым ераклыкта да туңып үләргә мөмкин бит. Спиртлы эчемлекләр бары тик махсус кибетләрдә

14.00 дән 20.00 гә кадәр генә сатыла, ашамлык кибетләренә бөтенләй кертелми. Безнең күз ияләнгән «Пятерочка» һәм «Магнит» кибетләре дә Якутиядә бер дә очрамады.

Биредә үз кибетләре, үз бәяләре. Мәсәлән, 1 килограмм яшел суган... 1200 сум тора!

КЫРГЫЙ СУГАН ҺӘМ «БЕНЗОЙ» ҖИЛӘГЕ

– Кыйммәтме? Бездә яшелчә-җиләк-җимеш өлгерми бит, җәй кыска, – дип аңлата сыйлаучыларыбыз. – Без кыргый суган җыябыз. Бушка. Капчыклап. Аны турыйбыз да туңдырабыз. Йә банкада тозлыйбыз. Кыш ашка кушарга менә дигән – бик хуш исле ул! Тиз арада җыеп калырга гына кирәк. Ул нибары бер генә атна үсә. Соцчелтәрләрдә кемнең дә булса суган җыйганын күрсәк, шундук чыгып йөгерәбез. Бездә бөтен нәрсәне бик тиз арада эшләргә кирәк бит. Нарат җиләге өлгергәч – шундук аны җыярга, мүк җиләге күренгәч – тизрәк шунда йөгерергә, саз җиләге пешсә – анысын җыеп калырга. Һәр җиләк сезоны бер атна-атна ярым гына. Безнең җиләкләрдә лимон кислотасы күбрәк – җәй кыска булганга, ул тизрәк өлгерә, шунлыктан составында бензой кислотасы башка җиләкләрдән күбрәк була. Шуңа ул озаграк саклана да.

ҖИЛӘКЛЕ ЧӘЙ

Юнылган балык ашаганнан соң тиешле вакыт үткәч, кыска якут җәенең бензой кислотасына бай нарат җиләге, саз җиләге, тагын әллә нинди бик тәмле җиләкләре кайнатмасы белән хуш исле якут чәен эчәбез дә, хуҗаларга рәхмәт әйтеп, өйгә җыенабыз. Юнылган балык һәм «Индигирка» рецептлары диктофонда – аларны үзебезнең Идел-Чулман балыгыннан ясап карарга ниятлибез. Юнылган сыладан авыз итәсегез киләме соң?

Үзебезнең аш-су өлкәсендәге уңышларыбыз белән киләсе санда һичшиксез сезне дә таныштырачакбыз.

Юнылган балык белән сыйланганнан соң Мәңгелек туңлык патшалыгында да туңмыйсың!

«ПРОФЕССИОНАЛЛАРДАН БАШКА МИЛЛИ СӘНГАТЬНЕ ҮСТЕРҮ МӨМКИН ТҮГЕЛ!»

Руфия Фазылова

Һәр чорның үзенең популяр җырчысы, композиторы, язучысы була. Буыннар алмашынгач та, аларның иҗаты онытылмый. «Гармун алыйк әле, дуслар», «Бергә чакларда», «Кал моңнарым булып», «Ялгыз көймә», «Безгә дөнья дәшә»... Бу җырларны ишетмәгән кеше бармы икән?! Композитор Риф Гатауллин аларны иҗатының иң популяр чагында язган. «1970–1980 нче елларда ким дигәндә айга бер-ике җыр туа иде», – ди композитор үзе. Риф әфәнде бүген нинләр белән шөгыльләнә? Хәзерге татар эстрадасына карашы ничек?

Кыскасы, редакциябез кунакханәсендә бүген композитор, Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Риф Хоббулла улы Гатауллин.

– Риф абый, сөйләшүне балачагыгыздан башлыйсы килә: туган авылыгыз – Югары Осланның Яңа Болгар авылы Идел елгасы буена урнашкан. Шул матурлыкны күреп үскәнгә, җыр сәнгатенә килмәдегезме икән?

– Әйе, безнең авыл искиткеч җирдә урнашкан: тәрәзәдән Идел елгасы күренеп тора. Кояш чыкканда, кояш батканда елгага шәүлә төшә, аның матурлыгы... Кечкенәдән әнә шул гүзәллекне күзәтергә яраттым. Иделдә боз кузгалу аеруча зур бер вакыйга була иде! Без, бала-чагалар, биш чакрым араны атлап түгел, йөгереп барабыз: боз киткәч, Казан белән ара якынайган сыман тоела. Пароходлар йөри башлый, Идел җанлана. Иксез-чиксез булып күренгән елга ярына утырасың да уй-хыялларың белән әллә кайларга китәсең... Әнә шулай үскән бала мин. Шуның өчен дә иҗатка тартылганмындыр да. Биш яшемдә инде гармун тотып төшкән сурәтләрем бар.

Фото: Александр Ефремов

Икенче сыйныфта укыганда тальянда уйный идем. Безнең авылда җыр-моңга һәвәс кешеләр яшәде. Көн саен гармуннар белән кич утырыш иде. Мин дә алардан күреп кулга тальян алдым.

– Әти-әниегез сез бала чакта аерылышкан. Сезнең өчен бу фаҗига булдымы?

– Юк, булмады. Күрәсең, әти белән әнинең бергә яшәгәнен күрмәгәч, мин аны шулай тиеш дип кабул иткәнмендер. Ләкин мин әтисез үсмәдем, без бик еш очраша идек. Кайбер елларда әти белән бергә яшәргә дә туры килде.

Әтинең икенче гаиләсе бар иде. Анда миннән ике яшькә кечерәк улы үсте. Беренче класска әти мине үзләренә, Казанга алып килде. Русча укысын, яхшы белем алсын, дип теләгән, күрәсең. Әни башта каршы да килгән булган, аннан инде ризалашкан. Әнинең әнисе әти белән аралашуыбызны бик теләгән: «Әтисез үскән бала бәхетсез була», – дигән.

Ләкин мин Казанда беренче сыйныфны гына тәмамладым, аннары яңадан авылга әни янына кайтып киттем. Ни дисәң дә, чит хатын-кыз кеше баласын үзенекедәй кабул итә алмый...

Тик Казаннан кайтып китксәч тә, әти белән юллар аерылмады. Тугызынчы, унынчы сыйныфны мин барыбер алар янында, Казанда тәмамладым. Әтинең ничек тә миңа яхшы белем бирәсе килде. Алай гына да түгел, үзе кебек инженер булуымны теләде. Ләкин мин бүтән юлны – җыр сәнгатен сайладым. Башта ул моңа үпкәләп тә йөрде, ләкин инде уңышларымны күрә башлагач, киресенчә, горурланды. Бергәләп җырлап утырган чаклар булды. Әти дә, әни дә бик матур җырлый иде минем.

– Сездә бер әчке зыялылык бар. Бу кемнән килә дип уйлыйсыз?

– Әтием белән әнием укыган кешеләр. Нәселдә дә зыялылар шактый, барысы да кушылгандыр. Әни Югары Осланның Мәмәтхуҗа авылы мәктәбендә эшләде, биология, химия фәннәрен укытты. Хәер, башка фәннәрне дә алып барды, ул чагында шулай ярый иде бит. Әни белемле, төрле яктан әзерлекле мөгаллимә иде.

Әтием Әтнә районының Ябынчы авылыннан. Заманында ул авылга Мәрҗанинең әтисе мәчет салдырган. Әти әнә шундый динле, белемле авылда үскән.

Әни Кайбыч районы Чүти авылыннан. Нәсел җепләребез Шәкүр карак нәселенә барып тоташа. Туганнар бик күп, аралашып яшибез. Табында сөйләшүләр нигездә әдәбият, сәнгать, тарих турында була.

– Авылда музыка мәктәпләре юк бит. Шулай булса да, Казан музыка училищесына укырга керә алгансыз. Әллә инде музыкаль башлангыч белемегез бар идеме?

– Мин бит җыр сәнгатенә шактый урау юллар аша килдем. Унынчыны тәмамлагач та, әти теләге буенча, КХТИга укырга кердем. Анда ике ел матур гына укыганнан соң... Казан музыка училищесына киттем. И, әти шул чагында ачуланды. Әйткәнемчә, аннан соң аңлады ул мине.

Ә музыка училищесына язмыш кушуы буенча барганмын, дип саныйм. КХТИда укыганда, хорга йөри башладым. Механика факультетының үзенең ансамбле бар иде, мине шунда берсүзсез алдылар. Ләкин анда рус телендә җырлыйлар иде, ә минем күңел татар җырларына тартылды. Шунда миңа бер танышым Сара Садыйкова хорына барырга тәкъдим итте. Сара апа мине бер җырлатып карауга ук үзенә алды. Бер ел шулай атаклы композитор оештырган хорда җырладым. Аннан соң Сара апа җитди генә итеп: «Вакытыңны бушка уздырма, музыка училищесына бар», – диде. Хорга йөргән өч егетне училищега үзе алып барды. Мине алдылар, ә КХТИны ташларга туры килде.

– Казан дәүләт консерваториясе сезгә нәрсә бирде?

– Консерваториягә югары белем алам дип бардым. Мин бит училищеда укыганда ук көйләр яза башладым. Ә шул юлдан китү өчен яхшы белем кирәк иде.

Профессиональ композитор булам дисәң, консерватория белеменнән башка булмый. Сара апа да киңәш бирде: «Әгәр укымасаң, минем кебек гомерең буе үзешчәннәр рәтендә йөрисең», – диде. Сара апаны үләренә ике ел калганда гына ТР Композиторлар берлегенә алдылар. (Ул Россия Композиторлар берлеге бүлекчәсе санала.)

Иҗатташ дуслар белән.

Әнисе Мәрзия, сеңлесе Лилия белән.

Җәмәгате Мөршидә ханым белән.

Россия Композиторлар берлегенә мин дә бик иртә кермәдем – 2007 елда гына кабул иттеләр. Анда керү өчен, композитор дипломы булырга тиеш. Дөресен генә әйткәндә, андый максатым да юк иде. 1991 елда үзем Үзешчән композиторлар берлеген төзедем. Һәвәскәр композиторларның иҗатлары күренсен дип, төрле конкурслар, фестивальләр оештырдык.

– Ул ике Берлек бер-берсеннән ничек аерыла?

– Бөтенләй нота белмәүчеләр бар. Бар нота белүчеләр, мисал өчен, музыка училищесының вокал яки берәр инструмент бүлеген тәмамлаучы. Ләкин ул композиция бүлегендә укымаган. Баянчы Рамил Курамшинны алыйк. Аның нинди шәп җырлары, әсәрләре бар. Ләкин аны ТР Композиторлар берлегенә алмаганнар, чөнки махсус белеме юк. Мәсгуть Имашев та консерваторияне җырчы буларак тәмамлаган. Ягъни Үзешчән композиторлар берлегенә керүчеләр дә бик талантлы, алар җыр сәнгатенә урамнан килеп кергән кешеләр түгел. Алар иҗат иткән җырлар югалмасын, туплансын өчен, әнә шулай берләшергә кирәк, дигән максат белән эшләдек.

– Риф абый, татар җыр сәнгате турында да сөйләшик. Бүген бөтен кеше җырлый һәм җыр яза. Моңа мөнәсәбәтегез?

– Ул элек тә булган. 1945 елда Казан дәүләт консерваториясе оеша. Менә шуннан соң худсоветлар барлыкка килә. Һәм профессионаллар белән үзешчәннәр аерыла. Ягъни зур сәхнәгә беренчеләре генә чыга башлый. Үзешчәннәр дә читтә калмый: һәр заводның хоры, клубы бар иде. Җыр сәнгатенә гашыйк кешеләр шуларда шөгыльләнде. Ә менә худсоветларның максаты профессиональ җыр сәнгатен үстерү булды. Радиода бер көн үзешчәннәр җырласа, алты көн профессионаллар җырлады. Шул рәвешле халыкның зәвыгын тәрбияләделәр. Мин дә шуның өчен профессионализмга омтылдым. Ике симфония яздым. Ә бүген бу тәртип югалды. Урамнан килеп кергән һәркем үзен җырчы яки композитор дип уйлый. Ләкин алай БУЛМЫЙ! Профессионаллардан башка милли сәнгатьне үстерү мөмкин түгел!

– Бүген татар эстрадасында меңнән артык җырчы бар, диләр. Советлар чорында бармак белән санарлык булган. Ул җырчыларның барысы да зур сәхнәгә чыгарлыкмы? Халыкның музыкаль зәвыгын кем тәрбияләргә тиеш?

– Әлбәттә, моны дәүләт үз кулына алырга тиеш. Совет чорында дәүләт һәр милләтнең мәдәниятен үстерергә тырыша иде. Ә бүген бу өлкәдә контроль дә, кыйбла да юк кебек. Тик моны үз көенә җибәрергә ярамый.

Бүгенге җырчыларга килгәндә, аларның киләчәге аяныч бит. Ярар, иллегә кадәр сәхнәдә йөрде, ди. Аннары нәрсә эшли? Тавыш гомерлек түгел, аның вакыты чикле. Кыяфәт тә үзгәрә. Җырчы дигән һөнәргә ия булсаң, әле музыка юнәлешендә балалар укытырга, дәресләр бирергә мөмкин. Ә акча эшләр өчен генә сәхнәгә чыккан белемсез җырчыларның иҗатлары кыска гомерле була...

– «Үзгәреш җиле» кебек фестивальләргә ничек карыйсыз: татар моңнарын үзгәртеп җырлау дөресме?

– Мин аны башта ук кабул итмәдем, русча әйткәндә «лажа» ул. Гәрчә ике җырымны анда җырлаттылар. Татар көйләрен бозарга ярамый! Алар безгә әби-бабайлардан калган мирас булып бара. Ритмик рәсемнәр үзгәрергә мөмкин әле, ләкин сүзләрдәге басым үзгәрергә тиеш түгел. Ә «Үзгәреш җиле»ндә сүзләрдәге басымны да үзгәртеп җырлыйлар. Нәтиҗәдә, җыр бөтенләй икенче яңгыраш ала, ул татар көе булудан туктый.

Хәзер күп җырчылар нота белми. Нота белән җыр язып бирсәң: «Риф абый, җырлап бирегез», – дип язалар. Хәтта музыкаль белеме булганнар да шулай яза. Җыр бит ул сүзләр җыелмасы гына түгел, ә иң беренче чиратта көй, моң. Бүген менә шуны аңлау бетте.

– Сез берсендә: «Татарча уйламаган кеше татар көйләре иҗат итә алмый», – дигәнсез. Хәзер дә шулай фикер йөртәсезме?

– Әйткәнемчә, басым дөрес ясалмаса, татар көе булмый, чөнки ритм үзгәрә. Хәзер дә шулай уйлыйм. Ритмны үзгәрткәч, бер матурлык барлыкка килә кебек, тик ул татарча түгел. Шуның өчен бүген макса-

тым – элек язган һәвәскәрләрнең иҗатын тарихта калдыру, чөнки алар гел үзебезчә – татарча көйләр иҗат иткән.

– Риф абый, сез өч тапкыр гаилә корган кеше. Никах озын гомерле булсын өчен нәрсә кирәк? Шуның турында уйланганыгыз бармы?

– Берсендә дә аерылам дип өйләнмәдем, шулай килеп чыкты. Беренче никахымда балабыз тумады, аерылмаган да булыр идек, дип уйлыйм. Алты ел яшәгәннән соң очраклы гына икенче хатын-кыздан улым туды. Әмма мин Алмаз улымны беркайчан ташламадым, әнисе белән дә мөнәсәбәтләр начар булмады, ләкин бергә яшәмәдек. Флүзә дә иҗат кешесе, җырчы. Аннары җырчы Гөлзада Сафиуллина белән рәсми рәвештә язылышып алты ел яшәдек. Гөлзада белән иҗади гаилә кордык: гел гастрольләр, уртак җырлар күп язылды. Тик ул никахыбыз да кыска гомерле булды.

Хәзерге хатыным Мөршидә белән утыз бер ел бергә яшибез, Аллаһка шөкер. Туран исемле егет үстердек. Улыбызга утыз тулды инде. Мөршидә бик молодец кеше. Беренче улым Алмазны да ташламый, минем туганнар белән дә элемтәне җайлап тора. Чын хатын-кыз шундый булырга тиеш, минемчә.

– Балаларыгыз сезнең юлдан китмәдеме?

– Минем юлдан китүләрен теләгән идем, әмма булмады. Туран биш яшеннән Казан дәүләт консерваториясе каршындагы махсус музыка мәктәбендә укыды. Сәләте дә бар иде, көйне тоемлау бирелгән аңа. Ләкин унберенче сыйныфны тәмамлаганда: «Әтием, үпкәләмә, тик мин музыка юлыннан китмәскә булдым...» – диде. Югыйсә рәхәтләнеп Казан дәүләт консерваториясенә керә ала иде. Һәм КФУның халыкара мөнәсәбәтләр факультетына укырга кереп, әйбәт кенә укып чыкты. Ике ел Кытайда эшләде, пандемия башлангач кайтты. Хәзер төрле заманча проектлар эшли, блоглар алып бара. Үзен камера алдында да бик иркен тота.

Олы улым Алмаз да бик акыллы булды, шулай ук КФУның халыкара мөнәсәбәтләр факультетын тәмамлады.

– Бүген ниләр белән шөгыльләнәсез? Иҗатка вакыт, теләк каламы?

– Быел һәвәскәр композиторлар антологиясен төзер өчен грант оттым. Мин бу эшкә күптәннән җыенам. Күрше төбәкләрдә – Себер якларында, Казахстан Республикасында да татар җырларын тупладым. Аларда милли көйләребез яхшы сакланган. Ә менә Татарстаныбызда ул тизрәк юкка чыккан. Нишләптер җирле татарларның бик тә заманча буласы килә. Ә читтә яшәгән милләттәшләребездә андый хәл күзәтелми. Күрәсең, читтә яшәгән татарлар өчен ул җырлар күңел юанычы да, тарих та...

Татарстан радиосында атна саен һәвәскәр композиторлар турында тапшырулар әзерлим, чөнки аларны халык белергә тиеш. Ә бит күбесен белмибез.

Элек халык иҗаты йорты бар иде, ул бетте. Фольклор үзәге дә юк. Культура министрлыгы каршында Традицион мәдәниятләрне үстерү үзәге бар иде, ул да юкка чыгарылды. Соңгысында шактый еллар эшләдем.

Туган районым Югары Осланга чакырдылар. Районның иҗат үзәгендә «Осланкай» («Услоник») дигән иҗат коллективы тупладым. Балалар белән театраль әсәрләр куябыз.

Эш күп, яңа планнар, максатлар белән яшим. Көч барында аларның барысын да тормышка ашырырга язсын, дип телим...

«Мин гел профессионализмга омтылдым. Ике симфония яздым...»

Риф Гатуллин уллары янәшәсендә.

ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫ КАЛАСЫНДА

Вероника Домрачева

1 август – РФ Кораллы көчләренең тыл көне. Казан иң катлаулы сугыш елларында тылның нинди әһәмиятле роль башкаруын исбатлады – Бөек Ватан сугышы чорында ул күпмилләтле халкыбыз бердәмлегенең, аның оешканлыгы һәм батырлыгының үрнәгенә әверелде. Казан чын мәгънәсендә хезмәт батырлыгы шәһәре булды.

СУГЫШКА БЕР ЕЛ КАЛА

1940 елның язы. Шомыртлар ап-ак чәчәктә. Вокзал яны мәйданында шәһәр халкы чәчәк бәйләмнәре тотып йөри. Оркестр уйный. Атлы милиция сафлары аша противогазлы кешеләр атлый – оборона активистларының Казан–Мәскәү маршруты буенча беренче җәяүле походына старт бирелә. Походны Казан тимер юлының оборонага, авиация һәм химия төзелешенә ярдәм итү җәмгыяте рәисе, тренер, Ворошилов укчысы, осоавиахимовчы, Мәскәү физкультура һәм спорт институтын тәмамлаган Алексей Васильевич Алексеев озата бара.

Поход 21 көн дәвам итә. Пехотачылар рельслар тоташкан урыннарның, противогазларның, «Спартак» комбинаты аяк киемнәренең сыйфатын тикшерергә тиеш була. Юл уңаендагы станцияләрдә халыктан ГТО нормаларын кабул итәләр, беренче медицина ярдәме күрсәтергә өйрәтәләр.

Журналистлар төркемне «Кыюлар җиделеге» дип атый, чөнки алар, һава торышының нинди булуына карамастан, алга баруларын дәвам итәләр.

Походны Казанда гына күзәтмиләр, аларны Мәскәүдә дә түземсезлек белән көтәләр. Платформадан күпкә югарырак күтәреп, транспарантка зур хәрефләр белән: «Казан пехотачыларына сәлам!» – дип язып та куелган була.

Төркем Осоавиахим бүлекләре белән Казанга кайта. «Локомотив» газетасы редакциясендә узган тантаналы очрашуда осоавиахимовчылар хисап тота.

Шуннан соң шәһәрдә ГТО, ПВХО, БГСО нормаларын тапшыру эше бик тиз җанланып китә.

Һәм менә инде чаңгычылар командасы «Обсерватория» шифаханәсеннән Казанга кадәр 18 км юлны бер сәгать эчендә үтә! Киләсе кышта яңа поход уздыруга әзерлек башлана – Ленинградка кадәр чаңгыда барырга ниятлиләр!

Ләкин сугыш планнарны чәлпәрәмә китерә.

Текстта архив документлары, Молотов райкомының, соңрак шәһәр партия комитетының хәрби бүлеге мөдире булган Алексей Алексеевның өлкә комитет партархивы үтенече белән язылган истәлекләре, шулай ук хезмәт фронтында катнашучыларның, ул көннәрне үз күзләре белән күрүчеләрнең истәлекләре кулланылды.

Фотолар Вероника Домрачева архивыннан, tatmitropolia.ru

41 НЕҢ ИЮНЬ АЕ

1941 елның 22 июне. Шомлы хәбәр бөтен шәһәрне тетрәндерә һәм тормышның астын-өскә китерә. Газета киоскларына чиратлар җыела. Репродукторлар гел кушылган хәлдә тора. Йорт идарәләре подвалларны тәртипкә китерә, бомбадан саклану урыннары булдырыла.

Ирек мәйданында яндыргыч бомбаларны сүндерергә өйрәтәләр, тәрәзәләрне ничек ябарга-капларга кирәклеге турында күрсәтмәләр бирәләр. Өйрәнү-тикшерү өчен тревога сынаулары уздырыла.

Партиянең район комитетлары каршында хәрби эшкә өйрәнү түгәрәкләре оештырыла, агымдагы чаралар планлаштырыла. Осоавиахимовчылар хәрби хәрәкәтләргә әзерлекләрен күрсәтә.

СССР Фәннәр академиясе «Ашарга яраклы кыргый үсемлекләр» дигән брошюра чыгара, аны илнең барлык төбәкләренә тараталар. Казанда аны шунда ук файдалана башлыйлар – алабута, әрекмән, какы, җикәнбаш һәм сәрдә бик күпләрне ачлыктан коткарып кала...

«Мине башта партиянең Молотов райкомы хәрби бүлеге инструкторы, аннары мөдире итеп билгеләделәр, – дип искә ала Алексей Васильевич Алексеев. – Булачак сугышчыларны – укчыларны, снайперларны фронтка әзерләү, төрле кирәк-яракларны куллана белергә өйрәтү, физик әзерлекләрен ныгыту йөкләнде. Бер үк вакытта атлылар, санитарлар, химиклар, хәрби этләр өйрәтү төркемнәре оештырылды. Нәселсез акыллы этләрне җыеп, төрле манёврларга өйрәттеләр. Алар арасында минем Трезор кушаматлы маэмаем да бар иде. (Мин аны сугыштан соң эзләп карадым, ләкин, ни кызганыч, ул һәлак булган. Хәрби комиссариатта миңа аның «Биремнәрне төгәл үтәгән һәм батырлык өчен!» дигән грамотасын гына тапшырдылар.)»

Яңа күрсәтмәләр алгач, шәһәрнең барлык предприятиеләре эш тәртибен үзгәртеп кора.

Икмәк комбинаты тәүлек әйләнәсе эшли, сохари киптерәләр, аны кәгазь капчыкларга тутыра башлыйлар. «Динамо» фабрикасы, «Швеймехкрой» артеле, «Спартак» комбинаты фронтка кирәкле яңа әйберләр чыгаруны җайга сала.

Сугышның беренче көннәреннән үк башка шәһәрләрдән төрле предприятиеләр эвакуацияләнә башлый.

Бу брошюрага кергән үсемлекләр күпләрне ачлыктан коткара.

Фронт өчен этләр өйрәтү төркемнәре оештырыла.

Мәскәүдән 22 нче авиация заводы (Горбунов исемендәге КАҖБ) күчерелә. Казан илнең хәрби самолетлар, бомбардировщиклар җыела торган яңа авиатөзелеш үзәгенә әверелә.

Воронеж һәм Мәскәүдән моторлар төзү заводлары эвакуацияләнә, берләшкәннән соң, аларга уртак – 16 нчы номер (КМҖБ) бирелә.

Бу көннәрне завод эшчеләре менә болай искә ала: «Мин ГТО нормаларын тапшырдым да, гальваник ванналарны анализлау буенча инженер-химик белемем нәкъ менә 16 нчы хәрби заводта файдалы булачак, дигән карарга килдем, – дип сөйли Валентина Николаевна Февралёва. – Постау бистәсеннән Караваевога җәяү йөрдем. Ә ул елларда салкыны да зәһәр була иде, термометр еш кына 50 градуска кадәр төшә. Тәүлек әйләнәсе диярлек эшләдем, башкаларны өйрәтә идем. Фидакарь хезмәт өчен медаль белән бүләкләндем».

«Сугышка кадәр дә, сугыш елларында да Ленин исемендәге Дары заводының иң катлаулы участогы – дары җитештерү цехында эшләдем, – дип искә ала Антонина Степановна Александрова. – Сугыш елларында өч Ленин ордены белән бүләкләндем. Дары заводы – хезмәт кенәгәмдәге бердәнбер язма. 40 нчы завод фронтка төп дары җитештерүче булды, шул исәптән атаклы «Катюша»лар өчен дә».

ОКОП КАЗЫРГА

Яңгырлы салкын көз. Фронтта хәлләр катлаулы, һәм моны һәркем аңлый.

Казанны саклау өчен Оборона комитеты төзелә. Гражданнарны оборона корылмаларына мобилизацияләү бара.

Алексей Алексеевка 3 нче йөзлекне җитәкләргә туры килә, анда колонна башлыгы Федор Федорович Матюшкин була. Колонна нигездә хатын-кызлардан тора, һәм алар үзләренең көрәк, балта, ломнарын күтәреп килә. Түрлемә станциясе тарафына кузгалалар. Юлда активистлар – Хөсәенова, Ракеева, Хуҗиәхмәтова, Трубникова «Ватан өчен!» дип аталган беренче стенгазетаны да чыгара.

Мамадыш-Әкил авылыннан соң җәяү барырга туры килә – юллар сазга әйләнеп беткән... Колонна ике километрга сузыла.

Җирле идарә белән сөйләшеп килешәләр – аларга ярдәмгә колхозның берничә җигүле атын җибәрәләр. Кирәк-яракларны, коралларны шуларга төйиләр, хәлсезләнгән хатыннарны утырталар.

Җирле колхозчылар хатын-кызларны бик яхшы каршы алалар, яшәп торыр өчен иң җылы бүлмәләрен аларга бирәләр.

Халык эшкә керешә. Ул вакытта бер генә хезмәтне дә ярышсыз күз алдына китереп булмый. «Бер көрәк тә эшсез тормасын!», «Эш – караңгыга кадәр!», «Артыбызда – Ватан!» кебек шигарьләр белән хәтта монда – окопларда да ярышлар оештырып җибәрәләр.

Окоп казырга... Колонна нигездә хатын-кызлардан тора, һәм алар үзләренең көрәк, балта, ломнарын күтәреп килә.

7 ноябрьдә салкын төньяк җиле исә башлый, кар төшә. Җирне туң тота. Балта һәм ломнарны эшкә җигәргә туры килә. Учаклар кабызмыйча булмый. Җирле халык эчәр өчен чиста су китерә, эшләргә ярдәм итә. Әнә шундый шартларда окоп казу эшен алып баралар.

Менә ул чорның стена газеталарындагы баш-исемнәр:

«15 кешедән гыйбарәт Волкова бригадасы 13 кубометрлык планны үтәде!»

«25 кешелек өлкән яшьтәге хатын-кызлар бригадасы 12 кубометрлык планны үтәде!»

Әлбәттә, мондый салкын вакытта авырып китүчеләр дә була. Күз яшьләре күренгәләсә дә, зарланмыйлар: бердәмлек һәм җаваплылык тойгысы тотып тора.

Йөзлек башлыкларын һәм бригадирларны Матюшкин штабка чакырткан көн килеп җитә. «Хезмәтегез өчен рәхмәт, иптәшләр. Моны үзегезнекеләргә тапшырыгыз. Казанга кайтабыз. Авырга туры килде. Ләкин берни дә эшләп булмый – сугыш...», – дип аңлата ул.

ФРОНТ ТА, ТЫЛ ДА

Ә шәһәрдә инде мобилизацияләнгәннәр һәм иреклеләр фронтка китә. Хәзер казанлыларның бөтен уе шулар турында була, монда, тылда, фронтка ничек ярдәм итәргә дип, баш вата шәһәрдә калганнар.

Хәрби частьләрдән солдат әйберләре кайтарыла башлый. Кулланышта булган кием-салым белән складлар бик тиз тула, кер юу, киптерү урыннары җитми.

Шәһәр һәм район партия комитетлары җәмәгатьчелеккә, шәһәр предприятиеләренә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Юасы керне бүлү буенча разнарядкалар төзелә.

...Кабан күлендә, Казансуда хатын-кызлар эшли – кер юалар, киптерәләр, үтүклиләр. Киемнәрне кочакларына кысып торган мәлләр дә була, чөнки аларда якыннарының каны булырга да мөмкин бит.

Надежда Михайловна Фелончева искә ала: «3 нче тегү фабрикасында тегүчеләр солдат шинельләрендәге каткан канны һәм пычракны юалар, пар белән эшкәртәләр иде. Аннары без, башка өлгеләр кисеп, яңа кием тектек. Боларны күреп тору да җанны өтә иде...»

ФРОНТ ӨЧЕН ӘЙБЕРЛӘР ҖЫЮ

Кыш якынлашуга, көн тәртибенә яңа мөһим мәсьәлә куела – хәрәкәттәге армия өчен ирекле рәвештә җылы әйберләр җыю. Шәһәр халкыннан мизгел эчендә җавап килә. Фронтка киез итекләр, сырма, бияләй, колакчынлы бүрекләр җибәрелә...

Әбиләрнең барысы да диярлек оекбаш, бияләй, свитер бәйли, аларга изге теләкләр теләп язу да кыстыралар. Заводлардан, артельләрдән әйберләрне зур-зур партияләр белән алып киләләр.

Фронттан рәхмәт хатлары алгач, әйтеп бетергесез шатлык хисләре кичерәләр!

Югары уку йортларыннан студент кызлар солдатларга җылы хатлар яза. Дусларча язышу башланып китә, тылда геройларның сугыштан кайтканын көтәргә вәгъдә бирәләр...



Форма № 1

районн(городская) комиссия по сбору теплых вещей и белья для Красной Армии.
Город (село) ______

«___» ____________ 194__ г.

Татарской АССР

КВИТАНЦИЯ № 39.068

на принятые теплые вещи и белья для Красной Армии

Принято от гр. Алексеева А. К. 50 руб.

проживающего

Принял: Завскладом
Член местной комиссии
Сдал

М. П.

Фронтка киез итек, сырма, бияләйләр, колакчынлы бүрекләр җибәрелә...

ЭВАКУАЦИЯНЕ КАРШЫ АЛУ

Якшәмбе көнне Ленин (Ульяновлар) урамындагы 27 нче йорт ишегалдындагы торак идарәсе янына бөтен якын-тирәдә яшәүчеләр җыела. Бу беренче зур җыелыш була. Башка

Ворошилов укчыларын әзерләү.

шәһәрләрдән эвакуацияләнүчеләр килергә тиеш, дип игълан ителә.

«Мондый вакытта чит шәһәргә килеп сыену җиңелләрдән түгел, – дип мөрәҗәгать итә җыелган халыкка шәһәр советы депутаты, 43 нче йортта яшәүче Баранов. – Шуңа күрә без бу кешеләрне иң якын туганнарыбыздай каршы алырга һәм үзебездә сыендырырга тиешбез. Тылда без барыбыз бергә Җиңүне якынайтачакбыз!»

Барановның тәкъдимен башкалар да хуплый. Алар арасында – мехкомбинат эшчесе Широков, слесарь Качалкин, Финанслар министрлыгы хезмәткәре Петров, партия өлкә комитеты хезмәткәрләре Солмин, Ведерников... Алар эвакуацияләнгәннәрне үзләрендә нормада каралганнан да күбрәк урнаштырырга карар кыла. Шунда ук Баранов булган акчаларны Татарстаннан китәчәк эскадрилья төзелешенә тапшырырга тәкъдим итә һәм, беренче булып, үзенең бөтен җыелган акчасын бирә.

Эвакуацияләнгән предприятиеләрнең йөкләре тимер юл белән һәм елга вокзалына килә тора, аларны озата килүчеләр үзләреннән бигрәк әлеге йөк өчен борчыла. Аларны да каршы алырга һәм урнаштырырга кирәк була.

Казанга Ленинград, Киев, Гомель, Ногинск шәһәрләреннән 70 тән артык завод, фабрика, фәнни-тикшеренү институты күченә.

...Эвакуацияләнгән предприятиеләрне кабул итүдә өч көн йокы күрми эшләгәннән соң, Алексеев өенә кайта һәм үз фатирын танымый: эвакуацияләнгән 23 кешелек 8 гаилә яңа ясалган сәкеләргә урнашкан!

Хатыны Алексеев белән таныштыра: «Бу минем ирем. Хәзер гаиләбез зур. Югалмабыз, Җиңүне бергә каршы алырбыз!» – ди.

СУГЫШНЫҢ КУРКЫНЫЧ ЙӨЗЕ

Сугышның чын йөзе шәһәргә яралылар кайтарыла башлагач ачыла. Ашыгыч рәвештә эвакогоспитальләр өчен биналар эзләү, аларны тиешле хуҗалык кирәк-яраклары, медицина җиһазлары, медицина кадрлары белән тәэмин итү ихтыяҗы туа. Бу бурычларның барысы да хәрбиләрчә оператив рәвештә хәл ителә.

Шәһәр халкы тәүлекнең теләсә кайсы вакытында, һава торышының нинди булуына карап тормыйча, фронттан эшелоннарны каршы алырга йөгерә. Алар носилкаларны күтәрешергә булыша, яралыларны тынычландыра:

«Агайнеләр, нык булыгыз, табибларыбыз яхшы, һичшиксез ярдәм итәчәк!»

«Рәхмәт сезгә, якыннарыбыз, без сезгә килеп йөрербез, һәрнәрсәдә ярдәм итәрбез!»

Комсомол кызлар, вахталы эшкә керешеп, яралыны кая алып барырга, караватка ничек саграк итеп күчерергә икәнен күрсәтеп тора.

Госпитальләргә иң яхшы медицина җиһазлары, медикаментлар китерелә. Хастаханәләр эшен җайга салуда сәламәтлек саклау тармагы оештыручысы, 1331 нче госпиталь башлыгы, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган табибы Шәфигулла

4494 нче эвакогоспиталь. Провизор Зоя Баранова һәм рецептлар ясаучы Екатерина Котихина.

Вәлиулла улы Бикчурин бәяләп бетергесез фидакарьлек күрсәтә.

Иң шәп табиблар – Шелутко, Комаров, Мурзин, Алексеев, Домрачев, Катеров һәм башкалар госпитальләрдә тәүлек буе эшли.

Суворов училищесы бинасында 1668 нче госпиталь урнаша. Бу – баш сөяге, баш мие авыр яраланган сугышчылар өчен иң зур госпиталь була.

«Миңа еш кына госпитальләрдә булырга, һәр палатада ранбольнойлар (ул вакытта фронтта яраланганнарны шулай дип атыйлар – автор иск.) белән сөйләшергә, аларның үтенеч һәм кисәтүләрен игътибар белән тыңларга туры килә иде, – дип сөйли Алексей Васильевич Алексеев. – Барысы да шома гына бармады, әлбәттә, чөнки эшне шунда ук җайга салу җиңел түгел. Ләкин җитешсезлекләр кичекмәстән хәл ителә барды. Бик күп сынаулар кичкән каһарман фронтовикларыбыз өчен иң яхшы шартлар тудырылырга тиеш. Табиблар һәм бөтен персонал кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырышты».

Туганнан туганнар – Зоя Баранова һәм Капитолина Алексеева 4494 нче госпитальдә хезмәт куя. Фармацевт-провизор Зоя кирәкле даруларны әзерли. Педагог Капитолина хезмәт терапиясе бүлеген җитәкли, өметләре өзелгән яралыларда кабат яшәү теләге уятырга тырыша.

ТЫЛ БАЛАЛАРЫ

Балалар өлкәннәрдән калышмый. Алты яшьлек Юра Алексеев әнисе белән госпитальгә йөри, яралыларның кәефен күтәрергә тырыша, шигырьләр сөйли, үзешчән сәнгать түгәрәгендә өйрәнгән лезгинканы бии.

Госпитальдә Юра яралы Коля Гусев белән дуслаша, аңа протез киеп йөрергә өйрәнергә булыша. Фашистлар Коляның йортын бомбага тоткан, аның бөтен гаиләсе һәлак булган, малай берүзе калган һәм шуңа бик нык борчыла. Юра аны үз гаиләсенә чакырырга була. Әти-әнисе дә бу тәкъдимне хуплый.

6 яшьлек Юра Алексеев госпитальдә яралылар каршында чыгыш ясый.

20 нче мәктәпнең беренче сыйныф укучылары (Тамара Щербакова сулда басып тора) тәмәке янчыклары тегә, кульяулыклар чигә... 1944 елның август ае.

11 яшьлек мәктәп укучысы Мила Бергер, укудан соң, дуслары белән бергә госпитальгә йөгерә – бинтларны юарга, үтүкләргә ярдәм итә, ә аннары чисталарын һәм кипкәннәрен төрә.

Беренче сыйныф укучысы Тамара Щербакова Мәктәп тыкрыгында урнашкан 20 нче мәктәптә укытучылар җитәкчелегендә сыйныфташлары белән тәмәке янчыклары тегә, кульяулыклар чигә... Тамара этисенең үлгәнен белә, ләкин өлкәннәр кызга этисенең герой булуы, аның белән горурланырга кирәклеге турында аңлата. Хәзер исә алар, җиңү өчен, аның фронттагы дусларына ярдәм итәргә тиеш.

Тамаралар сыйныфына мәктәп подвалына күченергә туры килә. Алар шул шартларда бишлегә генә укырга тырышалар, фронтка хатлар язарга өйрәнәләр.

МЕҢЧЕЛӘР ҺӘМ КҮП СТАНОКТА ЭШЛӘҮЧЕЛӘР

Стратегик әһәмияттәге предприятиеләр кадрларга аеруча кискен кытлык кичерә. Өлкәннәр белән беррәттән, станокка яшүсмерләр баса, алар барлык эшчеләрнең өчтән берен тәшкил итә. Ветераннар эшнең нечкәлекләренә төшендерә, моны алар намус белән башкара.

22 нче авиация заводында эшчеләр – слесарь Бирюков, фрезерлаучы Журавлев һәм башкалар планны 1000 процентка (!) үти башлый. Бу инде меңчеләр хәрәкәтенә кушылу дигән сүз. Мамакин, Сафронов кебекләр берьюлы берничә станокта эшли, алар иптәшләрен нормаларны фронтка киткәннәр өчен дә үтәүгә рухландыра.

Җиденче сыйныфны тәмамлаганнан соң, Капа Чукачёва елга техникумына укырга керә һәм беренче уку елында ук навигациягә чыга. Аларны, матрос итеп, Идел, Чулман, Агыйдел елгалары буйлап баржаларда сугыш кирәк-яракларын, азык-төлек, медикаментларны тиешле пунктларга ташырга җибәрәләр. Кызлар-егетләр Җиңүне якынайтуга булыша алулары белән ихлас горурлана!

Татарстанның бөтен авылларында да халык, шәһәрдән калышмыйча, бар көчен биреп эшли.

«Өлкәннәр, картлар, яшүсмерләр һәм балалар кырда эшләде, ат белән җир сөрделәр, – дип искә ала Вера Кузьминична Красильникова. – Кул белән чәчтеләр, бәрәңге утырттылар, аны чистартып, турап, фронтовиклар өчен мичләрдә киптерделәр. Мөслим районыннан станциягә малайлар белән капчык-капчык ашлык, киптерелгән яшелчә ташыдык... Боларның барысы да, фронт өчен дип, Казанга озатыла иде».

«Безнең «Рассвет» авылында хәтта иң кечкенә балалар да, икәүләп, өчәүләп булса да, киндер йолкыдылар, – монысы Галина Николаевна Митина истәлекләреннән. – Аннары хатын-кызлар аны суга салып изеп киптергәч, Казандагы җитен комбинатына җибәрәләр иде, анда фронт өчен арканнар ясадылар. Кызлар, сугышчыга атарга җайлырак булсын өчен, имән бармакны аерып, бияләйләр бәйләде. Малайлар кичләрен дә, төннәрен дә чыра яктысында киез итек басты – бүтән ут юк иде...»

ФРОНТОВИКЛАР ГАИЛӘЛӘРЕНӘ ЯРДӘМ

Барлык хәрбиләрнең гаиләләре исемлеккә теркәлә. Аларга азык-төлек, көндәлек ихтыяҗ әйберләре, утын бирәләр, ремонт ясыйлар...

Фронтовиклар гаиләләренә ничек тә булса ярдәм итәр өчен, шәһәр халкы шимбә һәм якшәмбе көннәрендә эшкә чыга.

Күп балалы хәрбиләрнең гаиләләре аерым исемлектә була. Яу кырында һәлак булган геройларның гаиләләрен аеруча кайгырталар һәм игътибар күрсәтәләр.

Партиянең шәһәр һәм район комитетларында ярдәм күрсәтү өчен махсус акча фондлары булдырыла. Предприятие коллективлары бер эш көне өчен акчаны фондка күчерергә карар кыла. Татар академия театры массакүләм кичәләр һәм концертлар оештыра, алардан җыелган акча да фондка килә.

Лядской бакчасында фронтовиклар гаиләләренә хезмәт күрсәтү мәсьәләләренә бәйле бушлай консультацияләр үткәрелә, булган җитешсезлекләр бетерелә.

ФРОНТТАН ХАТЛАР

«Өйдән хат алуга бик сөендем, хәрби бүлекнең адресын да шуннан белдем. Гаиләмә ярдәм иткәнегез өчен, йөз тапкыр рәхмәт әйтүне үз бурычым дип саныйм. Моның белән сез фронттагы тормышымны җиңеләйтәсез һәм минекен генә дә түгел. Без тылыбызның ышанычлы икәнен

ПАПА
БЕЙ ФАШИСТАВ

Юраның яу кырындагы әтисенә язган хаты.

Алексей Алексеевның улы Юрага фронттан язган хаты.


Юра! 27/IV
Скоро тебе в школу. Учись на хорошо писать, читать, считать. Будь послушным мальчиком. Люби свою учительницу


Выполняй все что она будет дебе задавать. К моему приезду ты должен читать, писать на отлично. Целую тебя и маму твой папа - Алеша

беләбез. Зур хөрмәт белән, Гарәф Юныс улы Юнысов, 24544 «А» кыр почтасы».

***

«Фронттан ихлас сәлам! Гаиләмә он һәм башка ризыклар бирелгәнен белдем. Мин сезгә бик рәхмәтле. Ватан өчен барган сугышларда мин яраландым һәм Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләндем. Сау булыгыз! Сержант Ф.М.Беляев, 05350 «К» кыр почтасы».

***

«Мин сезнең сабырлыгыгызга, хәрби хезмәткәрләр гаиләләренә карата игътибарлы һәм сизгер мөнәсәбәтегезгә таң калдым. Сезгә фронттагы иремнән сәлам һәм мең, Киевтан эвакуацияләнгән кешегә, ярдәмегез өчен рәхмәт. Веклярская (Маяковский ур., 27 нче йорт).

***

«Минем ирем фронтта һәлак булды. Ярдәмегез, кайгыртучанлыгыгыз өчен бик рәхмәтлемен. Латышева, Театр ур., 1/29 йорт, 14 нче фатир».

Һәм мондый хатлар күп була – алар монда, тылда, эшне туктатмаска көч бирә.

Хәрби бүлеккә сугышчыларның башка шәһәрләрдәге туганнарыннан да төрле үтенечләр язылган хатлар килә.

Алма-Атадан фронтовик Петр Иванович Архиповның хатынынннан борчулы хат килеп төшә. Сугышчы авыр яралана һәм башта кыр госпиталенә, аннары башка госпитальләргә җибәрелә. Хатыны үлем турында хәбәр ала, ләкин соңыннан иренең Казанга җибәрелү мөмкинлеге турында ишетә, аның кайда җирләнгәнен белеп булмасмы, дип сорый.

Барлык госпиталь һәм зиратлардан эзлиләр, кайсына язалар, кайсына барып белешәләр, мәгълүматларга төгәллек кертәләр, туры килми торган фактлар ачыклана... Фронтовикның хатынын төрлечә юатырга, тынычландырырга тырышалар, чөнки ул биш бала анасы була.

Кинәт Архипованың үзеннән хат килеп ирешә. Ул иренең исән-сау кайтып керүе турында хәбәр итә! Рәхмәт әйтеп, мәшәкатьләгәне өчен гафу үтенә, иң кадерле туганнар итеп, кунакка чакыра.

СУГЫШ ТӘМАМ. ҖИҢҮ!

«1945 елның 9 маенда мин партия өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советы кушуы буенча Балык Бистәсе районында чәчү эшләрендә йөри идем. Иртән иртүк район үзәгендә беренче секретарь Ландиков җыелган халыкка игълан ясады: «Иптәшләр! Сугыш бетте! Без җиңдек!» Шатлыкның иге-чиге юк иде!» – Алексей Васильевич Алексеев Җиңү көне турында әнә шулай искә ала.

...Казанда сугыш геройларын каршы алырга әзерләнәләр. Фронт һәм Җиңү өчен бөтен көчен түккән һәркем зур горурлык хисе кичерә. Хәзер инде җимерелгән халык хуҗалыгын торгызу таләп ителә.

ТЫЛ КЕШЕЛӘРЕ

Алексей Васильевич Алексеев, меңләгән Ворошилов укчысын, йөзләгән снайпер әзерләп, фронт сызыгына кадәр берничә эшелон солдатны озата бара. Алар белән бергә Ладога күлен кичә, бомбага тотыла. Ржев янында авыр яраланганнан соң, госпитальдә дәвалангач, инвалидлыгын яшереп, кушылган заданиеләрне үтәп баруны дәвам итә. Зур көч белән, дәртләнеп, эшче яшьләр мәктәпләрен ачу эшенә керешә, шуларның берсендә беренче директор була, тарих дәресләрен укыта. Тылда һәм фронтта Җиңүгә керткән өлеше өчен исемле корал, медальләр һәм хөкүмәт грамоталары белән бүләкләнә. Яуда алган яралар аркасында 59 яшендә вафат була.

Мила Бергер КДУны тәмамлый, химия фәннәре кандидаты була, КХТИның махсус факультетына эшкә урнаша.

Надежда Михайловна Фелончева гомере буе тегү фабрикасында тегүче-пар белән эшкәртүче булып эшли, үз һөнәренә хыянәт итми.

Валентина Николаевна Февралёва да үзенең КМҖБ заводына тугры кала, анда лаборатория башлыгы булып эшли, гомере буе Постау бистәсеннән Караваевога йөреп эшли.

Зоя Баранова тимер юл хастаханәсе төзелешендә катнаша һәм хезмәт юлын балалар бүлеге бинасында провизор-фармацевт буларак дәвам итә, даруханә мөдире булып эшли.

Капитолина Алексеевна, педагог буларак, 110 нчы мәктәптә укыта. Ул вакытта әлеге мәктәп Константиновкада була, анда хәрби очучыларның балалары укый.

Алексеевларның улы Юра – госпитальдә яраланган Коля Гусевка протез белән йөрергә өйрәнергә ярдәм иткән малай – очучы һөнәрен сайлый һәм соңыннан, тыныч чорда, һәлак була.

...Вакыт тәгәрмәче тиз тәгәри. Халкыбызга Бөек Ватан сугышында Җиңүнең нинди кыйммәткә төшүен, тыл хезмәтчәннәренең бу Җиңүгә керткән өлеше никадәр зур булуын беркайчан да онытырга ярамый.

Балык Бистәсе районында Җиңү көне. Трибунада – Алексей Алексеев .


www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Татарстан авыллары
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Финансовая грамотность
Реклама 16+

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Гомәр Терегулов тарихта **нинди** эз калдырган

Сембердә татар сәүдәгәрләреннән **кемнәр** яшәгән

Кайсы авылда мәчет белән чиркәү янәшә

Татар биюенә **кайда** өйрәнергә була

«ХАКЛЫККА ҖАНЫН ФИДА ИТҮЧЕ ИДЕАЛИСТ» ГОМӘР ТЕРЕГУЛОВ

Илдус Заһидуллин

XX гасыр башында татар мәдәни һәм иҗтимагый фикер күтәрелеше, күпчелеге крестьян сословиесенә кергәннәрдән тыш, рухани һәм мещан, сәүдәгәр һәм дворян катламнарыннан чыккан шәхесләр тырышлыгы белән тормышка ашырыла. Демократик ирекләр бирелгәч, русча яхшы белгән, дәүләт кануннарын аңлаган шәхесләргә мохтаҗлык арта.

Аерымланып яшәсәләр дә, дворян катламы вәкилләренең милләткә хезмәте хокук өлкәсендә ярдәм-киңәшләр бирүдә, Дәүләт Думасында депутат булуда, рус-татар мәктәпләрендә рус телен таратуда һәм земство оешмаларында халык мәнфәгатьләрен кайгыртуда ачык чагыла. Шундыйлардан Гаяз Исхакый «1905 елгы уяну дәверебезнең безгә биргән ташкын бер милләтчесе, хаклыкка җанын фида итүче идеалисты» дип атаган Гомәр Терегулов татар иҗтимагый хәрәкәтендә якты эз калдыра.

МОРЗА НӘСЕЛЕ

Гомәр Терегулов Уфа губернасы Бәләбәй өязе Яңа Каргалы авылында Хәбибрахман Сираҗетдин улы һәм Еникеевләр нәселеннән булган Зөлхәбирә гаиләсендә 1883 елның 9 апрелендә дөньяга килә.

Аның нәсел башы XVI гасыр ахырында Нугай Урдасыннан Рус дәүләтенә хезмәткә күчкән Еникәй Күлдәшевнең олы улы Терегул Еникеевкә барып тоташа. Еникеев һәм Терегулов морзалар Петр I нең 1713 елның 3 ноябрь указы таләбенә буйсынып чукынырга теләми һәм, дворян катламы оештырылганда, мөселман динен тоту сәбәпле, империянең югары катламына кертелми.

Ерак туганлыкларын истә тотып, бу ике нәсел вәкилләре XVIII гасырның икенче яртысында, Пенза төбәгендәге биләмәләрен калдырып, Оренбург губернасында бергәләп җир сатып ала һәм Каргалы авылына килеп урнаша. Екатерина II 1784 елда 22 февраль указы белән татар морзалары һәм кенәзләре нәсел дәвамчыларына дворян булып язылу хокукы бирә. Затлы нәселдән килгәннәрен исбатлагач, Оренбург губернасында яшәгән Терегуловларга һәм Еникеевләргә император Павел I нең 1796 елгы 29 ноябрь указы нигезендә дворян булып теркәлергә рөхсәт бирелә.

Дворян дәрәҗәләре расланса да, аларның матди яктан тормышлары мактанырлык булмый. Җир мәйданнары элеккечә кала, дәүләт эшенә урнашу өчен русча яхшы белү һәм уку йортын тәмамлау таләп ителә, шунлыктан күпләре иген игеп дөнья көтә. Гомәрнең этисе Хәбибрахман Терегулов, дворяннар өчен хас булмаса да, тирә-як авылларда сәүдә итү белән шөгыльләнә, шуның хисабына гаиләсен чагыштырмача мул тормышта яшәтә.

Уфа губернасында татар дворяннарының иң зур төркеме туплана. Алар үзара аралашып, ул өйләндереп, кызларын кияүгә биреп, бердәм булып яшиләр. Морзалар балаларына русча белем бирергә тырыша. Гомәр дә, бер сыйныфлы башлангыч рус-татар училищесын тәмамлагач, этисенә сәүдә эшендә ярдәм итә башлый.

ТАТАР УКЫТУЧЫЛАР МӘКТӘБЕНДӘ: ФИКРИ ЭЗЛӘНҮЛӘР

Бу елларда күп кенә дворян баласы 1876 елда Казанда ачылган Татар укытучылар мәктәбендә (КТУМ) белем ала. Гомәр дә, 15 яше тулгач, этисен күндереп, 1898 елда үз хисабына түләү шарты белән Татар укытучылар мәктәбенә укырга керә.

Ул КТУМда үзеннән 5 яшькә өлкәнрәк Гаяз Исхакый белән бер сыйныфта укый. Бергә укыган елларны искә төшереп, Исхакый моңарчы төрек әдәбияты белән мавыккан Гомәрнең

Фотолар түбәндәге сайтлардан алынды: photo.miras.info, иске сурәтләр: vk.com/wall-130649882_5970

рус әдәбиятын йотлыгып укуы, Лев Толстой романнарын идеал итүе турында яза. Шулар тәэсирендә яшүсмердә фикри эзләнүләр башлана, ул «Адәм баласын бәхетле итәр өчен ни кирәк?» дигән сорауга җавап эзли һәм таба. «Барлык золым, фәкыйрьлекнең сәбәбе – адәм баласының үз-үзен, тирә-юнен аңламавында» дигән нәтиҗә ясый.

Гомәр, аңлату кирәк дип, башта сыйныфташларына, аннары укытучыларына һәм 1900 елда КТУМ мөдире булып эшли башлаган Пинегинга, ялкынланып-ялкынланып, үз фикерләрен җиткерә. Ул шулай ук КТУМдагы яшерен түгәрәкләр эшенә катнашып китә. Гаяз Исхакый, Хөсәен Ямашев, Гафур Коләхмәтов белән бергә, «Шәкертлек» оешмасының актив әгъзасына әйләнә. 1902 елда укуын тәмамлаганда аның иң якын дусты Хөсәен Ямашев була. Дусты төрле теорияләр белән мавыгып, «янып яшәүче» Гомәрне бүлдермичә тыңлый белүе белән яшьтәшләре арасында аерылып тора. 1903 елны Ибнеәмин Әхтәмов Ямашев һәм Терегуловны РСДРП (б) ның Казан комитетына әгъза итеп терки.

Гомәр Казанда 1905 елда булган иҗтимагый-сәяси вакыйгаларда катнаша. Шул елның октябреннән 1906 елның сентябренә кадәр Уфа губернасының бер авылындагы рус-татар мәктәбендә укыта, бер үк вакытта үзлегеннән белем туплауны, рус әдәбиятын укуын, Лев Толстойның фәлсәфи хезмәтләрен өйрәнүен дәвам итә.

1907 елның 4 гыйнварында Оренбургта «Урал» газетасы нәшер ителә башлагач, шунда китеп, редакциядә хезмәт куя, матбаганың 24 нче саныннан соңгы 31 нче санына кадәр эшли. 27 апрельдә полиция большевистик газетаны яба.

«ШӘКЕРТ ҺӘМ ЯШЬЛӘР» ПЬЕСАСЫ

1908 елда Гомәр Терегуловның Казанда «Шәкерт һәм яшьләр» исемле 4 пәрдәлек пьесасы дөнья күрә. Фатих Әмирхан «әл-Ислах» газетасында бу әсәргә бәяләмә бастыра. Терегулов әсәрендә милли матбугатта моңарчы бик сирәк күренгән – татарга хезмәт итәр өчен русча системалы белем алу мәслихәт, шуннан башка берни дә эшләп булмый, дигән фикер үткәрә. Пьесада әсәрнең каһарманы шәкерт Нәгыймнең мәдрәсәдән соң русча укырга тотынуы, рус мәктәбен тәмамлавы, соңыннан атасына каршы тора алмыйча, зур икеләнүләр белән авыл мулласы булып китүе бәян ителә. Автор үз фикерләрен тормыш күренешләрен тәнкыйтьләргә яратучы Рөстәм исемле героеннан әйттерә. Бер яктан, Рөстәм зыялы яшьләргә татарча белү кирәклеккә ышана, икенче яктан, татар халкына дини мәдрәсәдә шәкерт булып торган кеше хезмәт итә алачак түгел, дигән фикер үткәрә. Фатих Әмирхан яшь авторны Нәгыймнең әти-әнисе типларын чынбарлыктан алып сурәтләгәне өчен мактый: Биктимер – тәкъва гына авыл карты, дөньядагы барлык нәрсәне намаз уку-укымаудан гына кил торган дип уйлый торган кеше, Галимә – балаларның үзләре теләгәнчә торырга хаклары булуын инкарь итмәүче юашрак хатын. Әмирхан Нәгыймне артык йомшак холыклы, ихтыярсыз итеп тасвирлау авторга үз фикерен үткәрү өчен кирәк булган, дип саный.

Фатих Әмирхан фикеренчә, автор үзенә идеал итеп куйган Рөстәм персонажында җитешсезлекләр күп: эшкә әзерлексез кешеләрне тәнкыйть итсә дә, үзенең эшләгән эше бер дә күренми. Тәнкыйтьче, әсәргә 5 нче пәрдә өстәп, анда Нәгыймнең мулла булып тулысынча эшләп китә алмавын, Рөстәмнең халыкка хезмәт итүче кешегә әйләнүен күрсәтү мәслихәт булыр иде, дигән нәтиҗә ясый. Ул пьесаның төп идеясе шәкертләр һәм яшьләр игътибарын җәлеп итәргә тиеш дип саный һәм барысына да әсәрне укып чыгарга киңәш итә.

«Шәкерт һәм яшьләр» пьесасы XX гасыр башында милләтнең киләчәге турында уйланучылар арасында фикер төрлелеген раслаган әсәр булуы белән кызыклы. Матур әдәбият өлкәсендә Терегуловның иҗаты шушы әсәр белән тәмамланса да, Уфа земствосында җитәкче урында эшли башлагач, автор, үз вәкаләтләреннән файдаланып, милли дөньяви мәктәпләр һәм русча укытуны тарату буенча киң эш җәелдерәчәк – пьесасындагы Рөстәм персонаж әйткән фикерләрне тормышка ашыра башлаячак әле.

Гомәр Терегулов (унда) һәм Әхнәф Мәмлиев. Уфа, 1905 ел.

Гомәр Терегулов, Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров (уңнан сулга). 1919 ел.

УФА ГУБЕРНА ЗЕМСТВО ИДАРӘСЕНЕҢ «ГАЙРЕ РУСЛАРНЫ АГАРТУ ШӨГЪҺӘСЕ» ҖИТӘКЧЕСЕ

Терегулов 1907 елның көзендә Казан университетының юридик факультетына ирекле тыңлаучы булып урнаша. Белеме җитеп бетмәвен аңлап, университетка керү өчен кирәк булган урта белем турында аттестатны экстерн рәвештә алу өчен имтиханнар тапшырып карый. Ләкин алар уңышлы булмый. Әтисе вафатыннан соң матди терәк беткәч, Гомәрнең югары уку йортына керү теләге хыял булып кала. Ул 1910-1911 елларда Казан губернасы Спас шәһәрендәге рус-татар башлангыч мәктәбендә укытучы булып эшли.

Уфага кайткач, Гомәр Терегуловның тормышында яңа этап башлана.

1910 елны Уфа губерна земство идарәсе каршында «Гайре русларны агарту шөгъһәсе» – рус булмаган халыкларның мәгариф бүлеге оештырыла. Гомәр башта беренче мөдир – мари милләтеннән Леонид Мендияровның ярдәмчесе булып эшли, 1913 елдан үзе мөдир була. Рус әдәбиятына мөкиббән Гомәр Терегулов үзенең ихласлыгы, мөгамәлә кору осталыгы һәм булдыклылык кебек сыйфатлары белән рус зыялылары һәм төбәк җәмәгать эшлекләренең ихтирамын казана, татарга бәйле төбәк мәсьәләләрен хәл итү буенча хезмәттәшлекне җайга сала.

Бу елларда аның сәяси карашлары үзгәреш кичерә. Ул большевикларның сыйнфый көрәш теориясеннән ваз кичеп, милләтпәрвәр либералга әверелә. Гади халыкка якынаеп, аның тормышын яхшырту өлкәсендә тырышып эшләгән дустын Гаяз Исхакый, якын итеп, «бердәнбер милләтче мирза баласы» дип атый; ул халкыбызның милли үзенчәлеген саклау өчен күпсанлы чараларга нигез сала, дип яза.

Чыннан да, 1912 елдан башлап, Уфа губернасында халыкны агарту эшләре яңа баскычка күтәрелә. Кооперация, мәгариф, гигиена, йогышлы авыруларга каршы көрәшү, игенче хуҗалыгы өчен файдалы үсемлекләр игү технологияләре, яңа авыл хуҗалыгы техникасы булдыру һ.б.лар хакында китаплар татарчага тәрҗемә ителә. Үтемлерәк булсын өчен, текстларда әйтемнәр, мәкальләр, шулай ук халык тормышыннан мисаллар китерелә. Тәрҗемә эшләре белән 1915 елга кадәр Мәхкәмәи шәргыя казые булган Хәсәнгата Габәши актив шөгыльләнә.

«Гайре русларны агарту шөгъһәсе» шулай ук, берничә дистә белгечне авылдан-авылга йөртеп, халыкны икъдисади яктан уята торган фәннәр, гигиена белеме буенча лекцияләр укуны оештыра.

Гомәр Терегулов 1914 елның җәендә булган земство киңәшмәсендә мәктәптән тыш укуукыту мәсьәләләреннән китапханәчеләр әзерләү кирәклеге турында сөйли. Нәтиҗәдә губернада, еш гына муллалар белән хезмәттәшлек итеп, земство хисабына 100 дән артык татар китапханәсе төзелә, берничә авылда уку өйләре ачыла, «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаган яшьләр, аларга китапханәче булып урнашып, халыкны мәдәни агарту эшен киң җәелдерә.

Мөдир кул астындагы агартучылар халык җырларының музыка үрнәкләрен җыя, аларны юкка чыгудан саклар өчен, земство хисабына Саратов шәһәре консерваториясе укытучысы морза Мансур Ислам улы Солтанов идарәсендә комиссия төзелә.

«Гайре русларны агарту шөгъһәсе» көче белән 1914 елдан Уфа губерна земствосының матбугат органы - «Уфимский сельскохозяйственный листок», татарчага тәрҗемә ителеп, «Авыл көнкүреше журналы» исеме белән нәшер ителә башлый. Журнал редакциясендә 1914–1917 елларда тәрҗемәче булып шагыйрь һәм журналист Сәгыйть Рәмиев хезмәт куя.

1916 елда Терегулов рус булмаган халыкларның мәгарифенә багышланган земство киңәшмәсендә доклад сөйли. Чыгышында һәр халыкның милли һәм тормыш ихтыяҗларына туры килә торган уку йортлары ачарга кирәклекне ассызыклый. Дини мәктәпләрне дөньяви уку йортларына әвелдерү планын тәкъдим итә һәм, земствоның матди ярдәмен җәлеп итеп, бу өлкәдә зур нәтиҗәләргә ирешә. Шул ук елда земство Уфада мөселманнардан укытучылар әзерләү өчен 3 еллык педагогик курслар ача.

Гомәр Терегулов Уфа шәһәре татарлары мәдәни тормышында мөһим урын тота. Ул Мөселман хәйрия җәмгыяте эшчәнлегендә, җәмәгать оешмасы үткәргән мәдәни һәм хәйрия чараларында катнаша, татар спектакльләрендә уйный, «Госмания» мәдрәсәсе шәкертләренә рус теле укыта һ.б. Терегулов эшләгән еллар тарихка земство һәм татар зыялыларының нәтиҗәле хезмәттәшлек итүе чоры булып кереп кала.

СӘЯСИ ЭШЧӘНЛЕК

Уфа губернасында зур абруйга ия Гомәр Терегулов исеме 1917–1918 елларда булган милләткүләм чараларда еш ишетелә.

Февраль инкыйлабыннан соң Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык фикерләрен тарату комитеты» оеша. Март башында комитет әгъзалары, шул исәптән Терегулов, мөфти Баязитовны һәм казый Г. Капаевны вазифаларыннан азат итә. Терегулов март азагында Петроградта Бөтенроссия мөселман съездын җыю өчен оештырылган Бюро эшчәнлегендә катнаша һәм татар җәмәгать эшлеклеләренең инкыйлаб шартларында мөселманнарны бердәмлеккә өндәгән күмәк мөрәҗәгатенә кул куя.

Үзе оештыруда катнашкан Бөтенроссия мөселман съездында (Мәскәү, 1-11 май көннәре), дини әләм тирәсендә түгел, милли байрак тирәсендә берләшергә чакырып, рус телендә сөйләгән докладды бер төркем делегатларда ризасызлык тудыра.

1917 елның 14–17 июлендә үткән губерна мөселманнары съездында губерна Милләт мәҗлесе сайлана. Терегулов туган телләрне земство, шәһәр думасында, губерна идарәсендә куллануны яклап сөйли, дәүләт җирләрен халыкка бирергә тәкъдим итә. Тиздән губерна Милли идарәсе рәисе итеп сайлана. Казанда узган һәм 22 июльдә милли-мәдәни автономия игълан иткән II Бөтенроссия мөселманнар съездында автономияне яклап ялкынлы чыгыш ясый, шулай ук беренче съездның җирләрне социализацияләү турында резолюциясен юкка чыгарып, хосусый милек сакланган хәлдә, дәүләт, удел, кабинет һәм монастырь җирләрен сатып алмыйча конфискацияләү кирәклеге турында чыгыш ясый. Аның тәкъдиме съезд тарафыннан кабул ителә.

1917 елның көзендә Уфада ачылган Милләт мәҗлесендә Терегулов милли-мәдәни автономия яклы төркемгә һәм мәгариф комиссиясенә керә, Милли идарәнең Мәгариф нәзарәтенә сайлана. Аның 1917 елның 1 ноябрендә булган утырышында мөселман укыту системасын саклаган хәлдә земстволар белән хезмәттәшлек итәргә чакыра.

Терегулов, губерна Милли идарәсе рәисе буларак, җирле автономия яклы ике төркем җитәкчеләренә каршы идеологик көрәш алып бара: 1) сул эсерлар төркеме җитәкчесе Галимҗан Ибраһимовка каршы – губернада лидерлык өчен; 2) Мәскәү съездында үзен мәркәзгә сайламаганнарына үпкәләп, башкорт автономиясен корырга тотынган Зәки Вәлидигә каршы – бердәмлекне саклап калу өчен.

Ул, Уфа губернасы либераллары вәкиле буларак, 1918 елның 5 гыйнварында дәүләтне Россия демократик федерациясе дип игълан иткән һәм большевиклар тарафыннан куып таратылган Учредительное собрание эшендә катнаша. Большевиклар белән хезмәттәшлек итүдән баш тарта.

МӨҺАҖИРЛЕК ЧОРЫ

Терегулов 1918 елның язында Уфада милли-мәдәни автономияне оештыру мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Уфага икенче тапкыр кызыллар керер алдыннан, 1918 ел ахырында Милли идарәнең җитәкчеләре белән бергә Кызылъярга күченә. Биредә Милли идарәнең атналык «Маяк» газетасын нәшер итүгә үзеннән өлеш кертә. Версаль тынычлык конференциясенә Гаяз Исхакый һәм Милләт мәҗлесенең төрекчеләр вәкиле буларак сайланган Гомәр Терегулов, Европага бару өчен, 1919 елның 10 апрелендә Ерак Көнчыгыштан, Иркутскидан Япониягә китәләр. Биредә дусларның юллары аерыла: Исхакый Европага китә. Авырып киткән Гомәр Харбинда татарлар арасында мәдәни-агарту эшләре алып бара, лекцияләр укый; Милләт мәҗлесенең соңгы эш нәтиҗәләре турында брошюра язып нәшер итә.

Терегулов 1924 елда Европага күченеп, Берлинда «Туран» җәмгыяте эшендә катнаша, докладлар укый. Төрек берлеген тормышка ашыру юллары – аның соңгы мавыгып һәм ялкынланып шөгыльләнгән темасы була. Бу хакта фикерләрен китап итеп туплый башлый, ләкин әсәр тәмамланмый кала. Сәбәбе – ялгызлык һәм туган илдән аерылу хисе, атасыннан күчкән эчкечелеккә бирелү гадәте. Бер-ике ел Берлинда, бер-ике ел Прагада, бер-ике ел Варшавада яшәгәч, Фуад Туктаров белән Төркиягә күченә. Биредә Омәр Тәңреколый (Аллаһ колы) исемен ала. Тәрҗемәләр белән шөгыльләнә, иҗтимагый эшчәнлектән читләшә.

Гомеренең соңгы айларын Әнкарада яши. Каты авырудан соң, 1938 елның 29 августында Бакыркөй хастаханәсендә вафат була, Бакыркөй зиратында күмелә.

Гаяз Исхакый дустының вафаты турында ишетү тәэсирендә язган мәкаләсен түбәндәге сүзләр белән тәмамлый: «Без Гомәр Тәңреколый белән бергә 1905 елгы уяну дәверебезнең безгә биргән ташкын бер милләтчесен; хаклыкка җанын фида итүче идеалистын; төрек берлегеннән башка таркау төрек кабиләләре өчен милли барлык юктыр, дигән бер төрекчене; Идел-Уралның киң төреклек юлында тартышучы бер милли гаскәрине; руслыкның безгә биргән зәһәрле хасталыкларының зур бер корбанын арабыздан югалтабыз!.. Урыны җәннәттә булсын!»

СЕМБЕР ТАТАР СӘҮДӘГӘРЛӘРЕ

Ульяновск ш., Бәхтиевләр йортлары.

Римма Вилданова, тарих фәннәре кандидаты

Сембер (Ульяновск) элек-электән татарлар күпләп яши торган төбәк санала. Шәһәрдә Акчурин, Алиев, Бәхтиев, Тенишев һ.б. кебек мәчет-мәдрәсәләр тоткан, фәкыйрьләргә ярдәм йөзеннән хәйрия җәмгыятьләре оештырган күренекле татар нәселләре көн иткән. Шулардан берсе – Бәхтиевләр династиясе.

ГАИЛӘ БАШЛЫГЫ СИРАҖЕТДИН БӘХТИЕВ

Сембернең тарихи Татар районына бүгенге Федерация урамының уртасы, Түбән Татар урамы һәм аларга якын урамнарның бер өлеше керә. Әнә шул җирләрдә шәһәрнең элеккеге таш мәчете белән янәшә урнашкан ике матур бина сакланып калган. Акчуриннар мәчет төзеткәнче, Сембер татарлары намаз уку өчен нәкъ менә бирегә – мещан Сәитов-Ильясовлар йортына җыелган.

XX гасыр башында Сембер өязе Шәйморза авылы крестьяны Сираҗетдин Шәйхаттар улы Бәхтиев мөселман җәмгыятендә әлеге дәрәҗәле участокны сатып ала һәм йортны үзгәртеп кору белән шөгыльләнә. 1905 елда утарда таш йорт калкып чыга, ә ике катлы агач йорт 1912 елда төзелә. Халыкта аларны Бәхтиевләр йортлары дип йөртәләр. 1916 елда хуҗа утарны мөселман мәчете карамагына тапшыра. Хәзер бирердә Ульяновск өлкәсе мөселманнарының төбәк Диния нәзарәте урнашкан, ә биналар үзләре архитектура һәйкәле булып тора.

Зур гаилә башлыгы Сираҗетдин Бәхтиев фабрикант, күпсанлы күчемсез милек иясе, җир хуҗасы була. Ул «Россия постау фабрикантлары җәмгыятенә» кергән сигез Сембер вәкиленең берсе санала, Үзара кредит җәмгыяте советына керә, шәһәр «Авыл хуҗалары, крестьян-милекчеләр, обрубчылар берлеге»ннән Учредительное собраниегә сайлана. 1917 елгы революция вакыйгалары башланганда Бәхтиевләрнең Мәләкәстә кибетләре һәм ашлык амбарлары, Самара губернасының Ставрополь өязе Мулловка авылында, Карсун өязенең – Ляховка, Сембер өязенең Линёвка авылларында постау (сукно) фабрикалары була, алар «С.Ш. Бәхтиев уллары белән һәм К» Сәүдә йортын оештыра. 1917 елда Сираҗетдин Бәхтиев Сембернең Лосевая урамында (хәзерге Федерация урамы) яши, гаиләнең шулай ук фабрикалар урнашкан авылларда, Шәйморзада йортлары була.

...Сираҗетдиннең әтисе Шәйхаттар Бәхтиев Иске Шәйморза авылында хәлле крестьян санала. 1885 елда ул Мәләкәстә ашлык амбары һәм мануфактура кибете ача. Иген белән сәүдә итү яхшы табыш китерә, һәм крестьянны барысы да «сәүдәгәр» дип атый башлый, гәрчә аның сәүдәгәрлек яки гильдия таныклыклары булмаса да. Сираҗетдин исә йон җыю һәм сату белән уңышлы гына шөгыльләнеп китә һәм инде XX гасыр башында постау фабрикаларын тотрыклы рәвештә чимал белән тәэмин итә башлый. Шунысы да билгеле: эшләре уңышлы гына барган «Сирай бай» (якташлары аны шулай дип атый), яшь чагында ярлы булса да, акыллы кеше була, кемнең кем икәнен яхшы чамалый. Әйткәнебезчә, гаиләнең туган авылында йортлары була. Бүген ул ике катлы йорт, кызганыч ки,

Фотолар автордан алынды

сакланмаган, ләкин авылда байларның өч ашлык амбары булуын әле дә хәтерлиләр. Икмәк уңмаган елларда авыл халкының күпчелеге ачтан интегә. Авылның бай кешеләре, аерым алганда Бәхтиевләр, бу вакытларда ашлыкның бер өлешен зәкят итеп мохтаҗ авылдашларына тарата. Бу турыда ишетеп алган күрше авыл кешеләре дә зәкят алырга Иске Шәйморзага агыла. Бай татарларның шәхси иганәләре авылдагы мәчет-мәдрәсәләрне карап тотуда бердәнбер диярлек керем чыганагы була. Бәхтиевләр, Аллаһка чын күңелдән ышанган мөселманнар буларак, туган авылларына ярдәм итәргә беркайчан да онытмый. Мәчетләр төзү һәм аларны карап тоту өчен шактый күп акчалар бирәләр.

XX гасыр башында Сиражетдинның гаиләсе ишле санала – анда тугыз бала үсә. Атаның алты улы сәүдә эшләрендә чын таянычка әйләнә.

Сиражетдин Бәхтиев һәм аның гаиләсе турында мәгълүмат аз сакланган. Әмма 2020 елда Сиражетдин оныгының Санкт-Петербургта яшәүче оныгы Алексей Рөстәм улы Бәхтиевтә бу нәсел турында шактый материал саклануы ачыкланды. 2021 елның язында ул Бәхтиевләр гаиләсе өчен истәлекле урыннар – Шәйморза, Мулловка авыллары, Димитровград, Ульяновск шәһәрләре буенча сәяхәт кылды.

ЛЯХОВКАДАГЫ ФАБРИКА

Сембер губернасында Бәхтиевләр үз капиталлары белән XX гасыр башында таныла. Монда Сиражетдин Бәхтиевнең Сембернең Ярминкә урамында яшәүче I гильдия сәүдәгәр Хәсән Алиев гаиләсе белән эшлекле һәм туганлык бәйләнешләре зур роль уйный. Сиражетдин Бәхтиев күрше Лосевая урамына килеп урнаша. Хәсән Алиевның вафатыннан соң, аның варислары нәкъ менә Бәхтиевкә матди ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. 1905 елда алар үз утарларын залогка салалар, тагын Бәхтиевләр аларның Ляховка авылындагы постау фабрикасын да сатып ала. Сатып алганда «фабриканың тузган, машиналары искергән булуы, анда 16 кеше эшләгәнлеге» ачыклана. Кәгазьләрне рәсмиләштерүгә берничә ел китә. Фабрика эшләре белән Зариф Бәхтиев шөгыльләнә, һәм предприятие 1908 елдан гөрләп эшли башлый. Бина тәртипкә китерелә, пар казаннары урнаштырыла. Сәүдәгәр фабрика белән идарә итүне Ибраһим Бибаевка тапшыра. Тиздән Сиражетдин Бәхтиев фабриканың казна подрядларын башкара алуы турында рәсми таныклыкка ия була. «Фабрика ел дәвамында 300 000 аршын соры шинель сукносы һәм дөя йонынннан башлык өчен 5 000 аршын сукно җитештерә ала. Сиражетдин Бәхтиев шәхесе казна подрядын үтәү өчен бик ышанычлы», – дип языла анда. Фабрикада 400 эшче хезмәт куя.

Һәрбер җитештерүдәге кебек үк, уңышлы эшләү чорыннан соң төшенкелек этабы килә. Гадәттә алар бөлдергеч яки фаҗигале очраклар белән бәйле була. Бәхтиевләр дә шундый хәлгә тарый. Ул заманнарда янгыннар гадәти хәл санала. 1909 елның ноябрендә Сембер фабрикалар инспекторы эш буенча Карсун өязендә була һәм Бәхтиевләрнең Ляховкадагы өйләрендә куна. Кызганыч ки, аңа зур янгынның шаһиты булырга туры килә. Фаҗига вакытында Сиражетдин Бәхтиевнең постау фабрикасы кара күмергә кала, йорты да янып бетә. «Куркудан алып чыгарга онытылган төнге йокы күлмәгем дә янды», – дип яза инспектор зур үкенеч белән. Фабрика хуҗаларына янгын китергән зыян, әлбәттә, инспекторныкы белән чагыштырганда, бик күпкә аянычлырак була. Шулай да Зариф Бәхтиев эшчеләргә «1 декабрьгә кадәр хезмәт хакы түләргә ризалыгын һәм эшчеләрне, башка эш тапканчы, фатирларыннан чыгармаячагын» белдерә.

Гомумән Зариф Бәхтиев Сембер татарлары тарихында күркәм эз калдыра. 1910 нчы еллар башында яңа буын кешесе – Зариф Бәхтиевнең иҗтимагый эшчәнлеге аның бик күп эшлекле сыйфатларын ача. Ул үз эшчеләрен укытырга кирәклеген, татар халкына аң-белем җитеп бетмәвен аңлый, мөселманнар, шул исәптән кызлар өчен дини һәм дөньяви мәктәпләр ачу тарафдары була. 1907 елда Зариф Бәхтиев Сембердә Хәсән һәм Ибраһим Акчуриннар, Кәрим Абушаев һ.б. тарафыннан оештырылган шәхси мәктәпләр советы рәисе була. Ул мәдәният, мәгариф һәм рухи тормыш өлкәләрендә татарларга кагылышлы яңа башлангычларга ярдәм итү йөзеннән Сембер мөселман хәйрия җәмгыятен (1913) оештыруда катнаша. 1914 елда Сембер шәһәр Думасының гласные буларак, татар башлангыч мәктәпләренә дәүләт субсидиясен бирү мәсьәләләрен даими күтәрә.

ЛИНЁВКАДАГЫ ФАБРИКА

Бәхтиевләрнең икенче предприятиеләре тарихы, мөгаен, Сембер өязендәге Мокрая Богурна авылында җир сатып алудан һәм Линёвка (Семёновка) авылында кечерәк кенә постау фабрикасын арендалаудан башланадыр. Шул заманнарда яшәгән туган якны өйрәнү белгече Павел Мар-


Ляховская фабричная
контора
Сыразетдина Шайхатдаровича
Бахтѣева.
Адресъ: Ст. Стар. Зиновьевка,
Симбирской губ.

Сиражетдин Бәхтиевнең Ляховкадагы постау фабрикасында кулланыла торган бланк, 1909 ел.

Зариф Бәхтиев гаиләсе, 1925 ел.


Начальникъ
Симбирскаго
склада
Въ Казанскую Контрольную Палату.

Бәхтиевләр сәүдә йортына караган эш кәгазе, 1918 ел.

тынов Линёвкадагы предприятие турында болай дип язып калдыра: «Фабрика 1889 елда эшләми инде – 1878 елдан бирле ябык». Сиражетдин Бәхтиев башта эшсез торган фабриканы торгыза, шуннан соң җитештерүне табыш китерерлек итеп оештыра һәм элеккеге хуҗаларыннан сатып ала. Әлеге зур булмаган предприятиенең әле 1917 елда да эшләвен раслый торган документлар сакланган. Мәсәлән, Февраль революциясенә ярты ай кала, ай башында, «С.Ш. Бәхтиев уллары белән һәм К» сәүдә йорты пар казаннары сатып алу өчен Идел-Чулман җәмгыятенә керә.

Сиражетдин Бәхтиевнең фабрикаларында җитештерү эшләре белән ышаныч кәгазе нигезендә уллары Зариф, Исмәгыйль һәм Әлим идарә итә.

МУЛЛОВКАДАГЫ ФАБРИКА

Кайчандыр Мулловка фабрикасы Ставрополь өязендә генә түгел, ә бөтен Самара губернасында иң зур предприятиеләрдән берсе санала. Имин елларда анда 900 гә кадәр кеше эшли. Әмма 1900 елда аның хуҗасы Хәсән Алиев вафат була. Фабрика белән идарә итә алмаганга, варислары, алдарак әйтелгәнчә, ярдәм сорап Сиражетдин Бәхтиевкә мөрәҗәгать итә. Шул рәвешле 1905 елда Сембердәге таш йорт һәм Мулловкада җирләре белән бергә постау фабрикасы өчен 10 мең һәм 95 мең сумлык ике заклад кәгазе рәсмиләштерелә. 1910 елда Мулловкадагы фабрика утары белән бергә Сиражетдин Бәхтиев милкенә күчә. Яңа хуҗа ремонт ясый, җиһазлар сатып ала, электр үткәрә. 1914 елгы сугыш постау җитештерүне үстерергә этәргеч бирә, чөнки дәүләт заказлары һәм подрядлары арта. Постау кыйммәтләнә, ә ихтыяҗ туып тора, җитештерү киңәя. Фабрика соры шинель тукымасы, солдат һәм тупас крестьян постаулары җитештерә. Бередә 90 станок, өч пар машинасы, 250 ат көчле локомобиль һәм башка җиһазлар эшли.

Революция Бәхтиевләрне дә читләп үтми. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң, губернаның постау фабрикалары делегатларының I съездында эшчеләр 8 сәгатьлек эш көне булдыруга ирешә. Сугыш бара, хәрби заказларны үтәгәндә эшче кулларга кискен кытлык сизелә. Сиражетдин Бәхтиев, башка милек ияләре кебек үк, мондый яңалыкларга каршы була. Ул эшчеләрне большевиклар коткысына бирелмәскә, аларга каршылык күрсәтергә өнди, шулай да фабриканы өч сменалы 8 сәгатьлек эшкә күчерергә мәҗбүр була.

1917 елның кышы ахырында Мулловкада революция җилләре көчәя. 600 эшче, патша режимына каршы, азатлык даулаган лозунглар күтәреп, урамга чыга. Илдә һәм губернада хәлнең начарлануын тойган Сиражетдин Бәхтиев өлкән улларыннан аерыла: аларга 50 000 сумлык товар (постау һәм йон) бирә. Әлбәттә, революциядән соң бөтен товарлары тартып алына.

1918 елның җәендә исә Сембергә аклар керә. Тормыш кыска вакытка гына булса да элеккеге рәвешенә кайткан кебек була. «Шәһәр хакимияте Кузнецов сәүдә йорты, С.Бәхтиев сәүдә йорты һәм Арацков фабрикасы конторaларына мануфактура (100 000 аршын бобрик, байка, трико, шевиот) алу мөмкинлеге турында сорау юллый», – дип язылган тарихи документларда.

1918 елның сентябрендә хакимияткә большевиклар килә. Эшчеләр җыелышы фабриканы дәүләтнеке итәргә һәм Халык хуҗалыгы советы карамагына тапшырырга карар кыла. Бәхтиевләрнең Сембер шәһәрендәге чимал складларындагы 23 500 поттан артык төрле йон товары тартып алына.

Сиражетдин Бәхтиевнең холкын ачкан бер эпизод турында аның Үзбәкстанда яшәүче оныгы Д.Таҗиева болай дип яза: «Революциядән соң, бөтен байлыгын яңа хакимияткә биреп, ул үзе Шәйморза авылына кайта. Аның кулында бу хакта документ була. Бу документ күп очракта аны саклап кала». Шулай да мондый сак кәгазе гаиләне репрессияләрдән коткарып кала алмый. «Бервакыт намаз вакытында өенә яңа хакимият вәкиле килеп керә һәм аңардан алтын таләп итә башлый. Сирай намазыннан бүленми, шуңа күрә килгән кеше аңа берничә тапкыр камчы белән сыптыра. Намазын тәмамлаганнан соң гына, Сиражетдин үзенең бөтен байлыгын хакимияткә тапшыруын әйтеп, документын күрсәтә. Алтын даулап килгән вәкил сүгенеп чыгып китә».

Соңрак Сиражетдин улы Кәрим белән хаҗ кыла. Фабрикант 1920 елның 29 июнендә үз йортында вафат була, Иске Шәйморза авылы зиратында җирләнә.

Бәхтиевләрнең Мулловкадагы постау фабрикасы бинасы. 2020 елгы фото.

ВАРИСЛАР...

1919 елда җирле газетада «Исмәгыйль Бәхтиевнең абыйсы Зариф Мулловкага килгән, Мәләкәс өяз совнархозындагы меньшевиклар ярдәмендә эшче идарә составына үтеп керергә тырыша, ләкин аннан куыла» дигән язма басылып чыга. Зариф Бәхтиевнең чыннан да яңа хакимияткә тәләктәшлек белдергәнме-юкмы икәнлеге билгесез, әмма 1920 елның мартында аның зур хуҗалык тәҗрибәсе Мәскәүдә РСФСР Тышкы сәүдә комиссариатында таләп ителә. Башта ул анда товаровед вазифасын башкара, чимал эзләп, Оренбургка һәм казах далаларына бара, аннары, Монголия йоны һәм Кытай мамыгына дип, Азия илләренә йөри. Аның киләчәк язмышы Баку шәһәре белән бәйләнә.

Сиражетдин Бәхтиевнең уллары – Исмәгыйль, Кәрим, Мөхәммәтҗан, Ибраһим, туган җирләреннән китеп, Казанда һәм Урта Азия республикаларында урнашалар. Араларында репрессиядән иң зур зыянны Сембердә калган Әлим Бәхтиев күрә. Сәүдәгәрнең эше Федераль куркынычсызлык советының Ульяновск өлкәсе буенча Идарәсе архивында саклана, бу турыда мәгълүматны аның оныгының улы Алексей Бәхтиев таба.

Әлим Бәхтиевне ике мәртәбә – 1918 һәм 1930 елларда кулга алалар. 1918 елда ул Бәхтиевләрнең Линёвкадагы фабрикаларында эшли һәм шунда яши. Шул чакта акларны акча белән тәэмин иткәне, алар белән элемтәдә булганы өчен тоткарлана. Линёвка авыл советы, киресенчә, бу көннәрдә Әлим Бәхтиевнең авылда булмавын, туган ягына кайтып китүен раслый. Ләкин Әлимне төрмәгә утырталар, 15 мең сум компенсация түләргә мәҗбүр итәләр. Фабрика тартып алынганнан соң, Әлим Бәхтиев, 8 кешелек гаиләсен алып, Шәйморзада яши башлый. 1922 елда гражданлык

Алиев һәм Бәхтиевләрнең варислары Эдуард Хәйруллин белән Алексей Бәхтиев Мулловкадагы постау фабрикасы хәрабәләре янында, 2021 ел.

хокукларыннан мәхрүм ителә. 1923 елда, илдә яңа икътисадый сәясәт барганда, Әлим Сембергә килә. Чүпрәк-чапрак, калдыклар белән сәүдә итә, аның еллык товар әйләнеше 1000 сумлык була. Аннары үзе сабын җитештереп, шуны базарда сата башлый.

Икенче тапкыр 1930 елның октябрендә кулга алына: РСФСР Җинаять кодексының 58 нче һәм 107 нче статьялары буенча хөкемгә тартылып, 10 елга төрмәгә утыртыла. Туганнары аны бүтән күрми.

Сембердә Бәхтиевләр нәселенең ике тармагы яшәгән, икесенең дә чыгышы Иске Шәйморза авылыннан, икесе дә Мәләкәстә үз эшләрен оештырган. Икенче тармак башында Шәмсетдин Бәхти улы Бәхтиев торган. Аның Сембер Ярминкә мәйданында ишегалды корылмалары, утар җирләре кергән, таш нигезгә салынган янкормалы агач йорты булган. Әмма бу инде бөтенләй башка тарих...

Казанның Татар бистәсендә Габдулла Тукай яшәгән тарихи «Болгар» кунакханәсе. «Бинаның беренче катындагы бүлмәләрне Әбрар Бәхтиев биләгән. «Тарихчылардан Сембер Бәхтиевләре белән Казандагылары арасында туганлык бәйләнешләренең булу-булмавы турында сорыйсы килә, – ди Римма Вилданова. – Интернет-чыганакларда Әбрарның улы – крестьян катлавыннан мещаннарга күчкән Сафа Бәхтиев мануфактура товарлары белән сәүдә итеп баеган дигән мәгълүмат та бар».

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

vk.com/protatarstann

t.me/protatarstan

youtube.com/channel/
UCuOhLcARMGm1PZnmAdaYdEQ

**БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!**

Реклама 16+

УРТАК КЫЙММӘТЛӘР – УРТАК МАКСАТЛАР

«Татэнерго» АҖ үз предприятиеләре урнашкан шәһәрләрдәге җирле хакимиятләр белән тыгыз хезмәттәшлек итә, бу республикадагы иң зур энергетика предприятиесенең уңышлы үсеш стратегиясенең мөһим өлеше булып тора. Зәй муниципаль районы белән хезмәттәшлекне озак елларга сузылган, ике як өчен дә файдалы үзара бәйләнешләрнең матур үрнәге дип әйтергә мөмкин. Бүгенге үзара конструктив мөнәсәбәтләр, аңлашып һәм бер-береңә ышаныч күрсәтеп эшләү күп очракта Зәй муниципаль районы башлыгы Рәзиф Гали улы Кәримов тырышлыгы нәтиҗәсендә саклана.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго»АҖ
генераль директоры

Мин күп еллардан бирле белгән Рәзиф Гали улы – җаваплы кеше, тәҗрибәле хуҗа. Әйләнә-тирәдәге тормышны тәртипкә салырга, бөтен процессларны шәп итеп оештырырга омтылу – аңа хас әлеге сәләт куелган бурычларны үтәү өчен бөтен ресурсларны эшкә җигеп алга атлаганда этәргеч булып тора.

Озак еллар буе Рәзиф Гали улы Тукай районында да, Яр Чаллыда да үзенә ышанып тапшырылган эш урыннарындагы бер дә идеаль булмаган мохитне әкренләп үзгәртү, төзекләндерү белән шөгыльләнде. Актив һәм максатчан Рәзиф Гали улы үзенең хезмәт юлын узган гасырның 90 нчы елларында авыл хуҗалыгында урта звено идарәчесе буларак башлаган иде: «Татарстан» совхозының машиналар паркы мөдире, баш инженеры, «Искра» колхозы рәисе, ә соңрак – Тукай районы хакимияте башлыгының беренче урынбасары, «Тукай муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе» дәүләт учреждениесе башлыгы, сөт эшкәртү предприятиеләре директоры...

2014-2015 елларда башта Зәй муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, аннары Зәй муниципаль районы башлыгы вазыйфасына керешкәч, Рәзиф Гали улы карьерасының тагын да югарырак баскычына күтәрелде. Биредә ул үзенең алдан күрә, район һәм шәһәр файдасына колачлы бурычларны хәл итүдә халыкны берләштерә, социаль мохитне үстерүгә комплексលы якын килә белү осталыгын күрсәтә алды. Шәһәр оештыра торган предприятиеләргә таяну – территорияне үстерүнең беренчел шарты, һәм Зәйдә моны яхшы аңлап эш итәләр.

«Татэнерго» АҖ филиалы Зәй ГРЭСы быел 60 еллыгын билгеләп үтә, алар Рәзиф Гали улы белән яшьтәшләр. 1963 елның 26 февралендә Зәй ГРЭСының беренче энергоблогын комплекслы сынау тәмамлана. Зәй ГРЭСы турында юкка гына «Татарстан энергетикасында тулы бер эпоха» дип әйтмиләр.

Станция төзелгәннән соң, Татарстанның нефть табыла торган перспективалы төбәгенең үсеше яңа импульс ала. Шәһәр оештыра торган предприятие буларак, Зәй ГРЭСы бүген дә районның икътисадый һәм социаль юнәлешен билгели, җирле бюджетның сизелерлек өлешен формалаштыра, эш урыннары булдыра. Иң мөһиме, станция шәһәр һәм район халкын, социаль әһәмияткә ия объектларны, предприятие һәм оешмаларны электр һәм җылылык энергиясе белән тәэмин итә. Предприятиенең бөтен тырышлыгы энергия белән ышанычлы һәм өзлексез тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Ел саен шәһәрдә җылылык челтәрләренең якынча 2–3 чакрымы ремонтлана һәм камилләштерелә, торбаүткәргечләр даими тикшерелеп тора.

«Татэнерго» җәмгыятенең җирле хакимият белән хезмәттәшлеге иң кыйммәтле ресурс – кешеләрне кайгыртуга юнәлдерелгән булуы сөендерә. Энергетикага укучылар һәм студентларны җәлеп итү уңай нәтиҗә бирә: Зәй политехника көллиятен тәмамлаучылар эшкә урнаштырыла, студентлар җитештерү һәм диплом алды практикасына кабул ителә – әлеге тәҗрибә Зәйнең башка предприятиеләрендә дә киң таралган. Спорт ярышлары, бәйрәм концертлары, хәйрия проектлары, волонтерлык хәрәкәте – шәһәрнең социаль тормышында энергетиклар бик актив катнаша.

Әлеге уңай тәҗрибә дәвам итсен, ә Зәй муниципаль районының комплекслы үсеше тотрыклы тенденциягә әйләнсен иде. Боларның барысында да Рәзиф Гали улының мөһим роль уйнаячагы һәркемгә мәгълүмдер.

– Хөрмәтле Рәзиф Галиевич!

Сезне ихластан юбилеегыз белән котлыйм! Катлаулы хезмәтегездә уңышлар телим. Иманым камил: сездәге идарә итү таланты һәм оештыру сәләт, сезгә хас хезмәт сөючәнлек һәм энтузиазм яңа үрләр яуларга булышыр. Үзегезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, муллык һәм иминлек телим!

Фото: «Татэнерго» АҖ рөхсәте, zainsk-inform.ru. РЕКЛАМА

Айгөл Әхмәтгалиева — язучы, драматург, журналист, мөхәррир. Сәҗидә Сөләйманова һәм Илдар Юзеев исемендәге әдәби премияләр лауреаты.

Әсәрләре «Казан утлары», «Идел», «Сөембикә» һ.б. журналларда, «Мәдәни җомга» газетасында басыла. «Болытта җиләк үсә», «Синең өчен яшим», «Мин гашыйк булдым», «Баланнарда бал тәме» дип аталган китаплары басылган. Пьесалары татар һәм башкорт театрлары сәхнәләрендә куела.

Хикәяләре мәктәп дәреслекләренә, «Яңа базар», «Балачак энциклопедиясе» җыентыкларына кертелгән, рус һәм төрек телләренә тәрҗемә ителгән.

Айгөл Әхмәтгалиева

ТӨСЛЕ МОҢ

Авылдашларыма багышлыйм

Тузганак керфекләре берәм-берәм җилгә сибелде. Нурислам, кулында нәүмизләнеп, бушап калган, таҗчыкларын койган нәни касәгә байтак кына текәлеп торды: «Хикмәт бу дөнья. Сулыш өрүдән дә юкка чыксын инде әле генә бар булган нәрсә»... Фәлсәфи уйларга бирелергә җыенган картның карашы капыл гына алдыннан йөгереп үткән алсу үкчәгә берегеп калды.

Бакча очында хәтфәдәй җәйрәп яткан бәбкә үләненә тәпиләрен тигерер-тигермәс кыз бала йөгерә. Юк, йөгерми, иркә генә канат тибрәткән нәни күбәләктәй оча, бөтерелә. Болытларның итәк очы җиргә тигән якка табан тымызык җил булып ашкына. Чирәм өстендә — алсу үкчә...

Нурислам, көтмәгәндә пәйда булган ялантәпиле кызны күздән югалтмагаем дигәндәй, карашын күбәләк-сыннан аермыйча гына, ашыга-кабалана галушларын киде. Бер мизгелдән ул да, ук кебек томырылып, кызчык артыннан чаба иде. Чаба, чаба, чаба... Күз алдында — алсу үкчә... Кул сузымы ара калгач, әйтерсең, аягына тышау салалар: салулап кала, ничек кенә омтылмасын, якынаеп беттем дигәндә генә кызчык янә болытларның итәк очы җиргә тигән сызыкка җиткән була.

— Гөлмәрья-әм!

Болытларга бәрелеп кайтаваз булып яңгырыймы соң бу исем?

Кайткан бит, кайткан! Әнә бит ул, кул сузымы арада гына — Гөлмәрьям. Шул ук шөпшә билле, ялан тәпиле кызыкай. Ул нәкъ элеккечә инеш ярында күбәләктәй бөтерелә, кояшка кочак җәеп йөгерә...

Нурислам, җилгә сибелгән алтын толымнарга кагылырга теләп, кулларын сузды һәм шул халәттә катып калды. Ике арада ярты гасырдан артык вакыт җәйрәп ята иде.

«Вәт карт җүләр, биленнең бил, аягыңның аяк түгеллеген дә онытып, яшь-җилкенчәк кебек кадурланып кузгалмасаң соң!» Нурислам, авырткан билен бераз угалап торгач, кыз артыннан үзе түгел, уе гына йөгергәнен аңлап, көрсенеп куйды.

Җәйге кояш, ничек кенә юмарт булмасын, җелеге кипкән карт сөякләрне җылыта алмый шул. Нурислам чабылган печән өстенә салып ташлаган саргылт камзулын алып киде һәм, аягындагы йон оекбашларга күз төшереп, янә бер уфтанды. Чалгысын кайтарга иткән иде, кулының эштән кайтканын

Фото: автордан алынды, В.Мухин иллюстрациясе, Инесса Морозова картинасы

аңлап, кайрагын үләнгә ташлады. Кул аркасы белән билен ышкый-ышкый, иплән кенә иелде, җиргә таянып, авырлык белән генә аякларын сузып җибәрде.

...Шул татлы җылыда черем итеп алырга өлгергән карт ялан тәпиле кызчыкның үз янына килеп басуын да искәрмәгән иде.

— Бабай, әй бабай, син нишлисең? — Ак җирлеккә зәп-зәңгәр кыңгыраулар төшкән күлмәкле кыз үзе дә карап туймаслык чәчкәне хәтерләтте.

— Менә, бәрәннәргә дип, бакча печәнен чабарга азапланам да, бик теш үтми шул әле, кызым, картлык үзенекен итә.

Кыз рәт-рәт яткан печән пакусларына күкләр төсен урлаган күзләрен тутырып карады да чиксез гаҗәпләнгән кыяфәттә:

— Син аларны шулай тешләрең белән кисеп чыктыңмы? Кру-то! — дип, баш чайкап куйды.

Аның ихласлыгына ифрат күңеле булган Нурислам рәхәтләнеп кеткелдәде:

— Мин үзем дә бик крутой бит, кызым, — диде, күзләрен хәйләкәр кысып. — Күрәсеңме, минем яннан кырмыска малайлары да җепкә тезелеп, тәртип белән генә үтәләр. Әнә, берсе честь бирергә дә маташа түгелме?

Кыз, күлмәк итәген чеметеп кенә тотып, карт янәшәсенә чүгәләде. Тәпиләре янында тыз-быз килүче бөҗәкләрнең хәрәкәтен бик дикъкать белән күзәтеп торганнан соң челтерәп көлеп җибәрде. Муенса энҗеләре бәллүр касәгә сибелде... Кызның озын керфекләре күбәләк канатыдай лепелдәде.

— Син шундый кызык, бабай! Бабай, әй бабай, дәү әнием инеш буенда бөрлегән бар дигән иде, мин берне дә тапмадым!

Картның йөрәге дертләп китте. Ул, кәпәчен арткарак төшереп, берән-сәрән тырпаеп торган чал чәчләрен сыйпап алды.

— Һм... Нишләп дәү әниең үзе эзләшмәде икән соң?

— Ул ерак-ерак әбинең хәлен белергә дип китте. — Кыз авыл читендәге зират ягына ымлап күрсәтте дә, җил кебек бөтерелеп, янә инеш буена йөгерде.

Нурислам ярның теге ягында хан сараедай балкып утырган, челтәр бизәкле, зур капкалы йортка текәлеп-текәлеп карады.

Ул гомер буе көтте. Әлеге йортның капка төбендә Хыялы белән күзгә-күз очрашыр мизгелне көтте. Шул мәлдә нидер булыр, бар дөнья аллы-гөлле төсләргә күмелер, яшәү дигән татлы сүзнең мәгънәсе ачыкланыр һәм, ниһаять, чын-чынлап тормыш башланыр, дип көтте. Шундый хыял белән гомернең һәр көне кителеп барды. Нурислам өчен «бүгенге көн» дигән вакыт төшенчәсе дә булмады, ахры. Аның яшәеше,

бүгенгесе һәрчак үзеннән читтә, каядыр янәшәдә атлады. Гомер озын, бик озын тоелган иде, киләчәк дигән матур сүзгә дә әллә нинди сихри хикмәтләр сыйган кебек иде. Шул киләчәкнең килерен көткән Нурислам хатирәләр белән генә яшәп торды...

***

Алар икесе ике ярда — оялчан кызлардай толымнарын салындырып, иплэп кенә лепелдәшеп утырган таллар белән каймаланган инеш ярында яшәделәр. Нурисламнарның бакча очы шул таллар буена килеп терәлә. Инешнең аръягыннан исә, әллә шул бакчаны, әллә инде юк сәбәпне бар итеп гелән-гелән шунда кайнашырга яраткан чандыр гәүдәле кара чутыр малайны яхшылабрак күрергә теләп, Гөлмәрьямнәрнең үргә табан салынган җил капкалы, салам түбәле өйләре карап тора.

— Нурисла-ам! Хөрәсәнегез ычкынган! — Гөлмәрьямнең нәзек тавышы малайны әллә кайлардан эзләп таба. Ул, бәрәңге сабаклары аша атлый-йөгерә, инеш буена атыла. Үшәнлеге, ялкулыгы өчен «Хөрәсән» кушаматы алса да, бауны өзеп качарга дигәндә, бозаулары ике уйлап тормый шул.

— Әнә, таллар арасына, күләгәгә кереп ятты! — Гөлмәрьям, алсу үкчәләрен ялтыратып, сары толымнарын җилгә таратып, малай алдыннан йөгерә. Ни хикмәттер, учка салсаң, сыеп бетәрдәй шушы кызчык янында бик рәхәт Нурисламга.

— Син гел безнең Хөрәсәнне генә күзәтеп торасың бугай...

— Менәтерәк, соң син бит аны нәкъ безнең тәрәзә турысына төшереп бәйлисең...

— Гөлмәрьям, ә синең күзләрең нигә бөрлегән төсендә?

— Бөрлегән дигәннән, яр астында быел бигрәк күп, җыярбыз әле, яме?

Монысы — балачак хәтере. Ач, ялангач чакларны оныттырып, ирен читләрендә якты елмаю уяткан якты сагыш, якты хатирә.

***

Гөлмәрьямнең дә, Нурисламның да әтиләрен сугыш алып китте. Нурисламныкын — бөтенләйгә. Югалту ачысын үсмер малай гармун телләренә салды:

Уйсу җирнең агым суы
Ага икән таң белән.
Узар, ахры, яшь гомерем,
Гел сагыш, гел моң белән...

Сугыш урлаган балачакны, бөтенлекне, тигезлекне сагынып, җырга авылның бүтән ятимнәре кушыла.

Кич утыруларга, сирәк кенә булса да, Гөлмәрьям дә чыккалый. Озак юанмый үзе, түгәрәк эчендә бер-ике бөтерелүгә, инеш буйлап кына өйләренә кыяклый. Эзенә бастырып атлаган Нурисламны баштарак күрмәмешкә салыша, береаздан гына, юлыннан бүленмичә, телгә килә.

— Кит әле, иярмәле миңа, Нурислам, кеше күрсә, әллә ни уйлар...

— Бәй, сиңа иярүем түгел лә, мин дә өйгә кайтам бит, Гөлмәрьям.

— Нигә соң аны мин кузгалгач кыймылдыйсың, иртәрәк йә соңрак кайтсаң ярамыймыни?

— Син киткәч, анда ни ямь кала дип уйлыйсың?

Авыл урамы йолдызлардан сирпелгән серле яктылыкта коена. Тымызык җилдә кызның биленә төшеп торган сап-сары ике толымы тибрәнә. Ай яктысында аның «менә пешәм, менә пешәм» дигән бөрлегәндәй куе зәңгәр күзләре, шул күзләрне ят карашлардан яшерергә теләп каймалаган, ләм хәрефенә охшаш керфекләре, ирен читендә каләм очы белән төртеп куйгандай күренер-күренмәс торучы нәни миңе чагылып китә. Ак күлмәкле зифа сын, барган җиреннән кырт туктый да артыннан өч-дүрт адым калдырып атлаучы үсмерне көтеп ала.

— Әнкәй урын өстендә ята бит, Нурислам. Күңелең ачылыр, дип чыгарып җибәргән була да, ни йөрәккәем белән уенда йөрим. Көз көне колхоз басуында көлтә ташыганда көч китергән иде, әле дә булса мантый алганы юк. Көннән-көн начарая гына бара. Бригадир, норманы үтәмәсәң, Себер китәсең дип, өстендә торып эшләткән бит...

Юату сүзләре табалмаган Нурислам дәшми генә Гөлмәрьямнең кулын җитәкләп ала.

Монысы да хәтер. Үсмер чак хәтере. Сапсары төсләргә күмелгән хатирә.

Шул язда сугыш бетте. Шул җәйдә, күлмәгенең буш җиңен җилфердәтеп, Гөлмәрьямнең әтисе госпитальдән кайтып төште. Күрешү мизгелләре өчен генә җан саклаган авыру ана, җиңел сулап, мәңгелеккә күзләрен йомды.

***

Авыл тиз генә тернәкләнә алмады. Сугыштан соң килгән беренче тыныч язда да хезерчелек хөкем сөрүен дәвам итте. Чын исеме тәмам онытылып, яше-карты «быргадир» дип кенә йөрткән сыңар аяклы Сәүбән абзый, шул язда уникe кешене җыйнап, Минзәләгә җибәрде.

— Апайлар, ничек тә симәнәне исәнимин апкайтып җиткерегез инде. Ат белән чана, Нурислам, синең карамакта. Апаңнарга да күз-колак бул, матри, урлап кала күрмәсеннәр.

Бригадирның «апаңнар» дигәненең күбесе унбиш-уналты яшьлек кызлар булып, алар арасында Гөлмәрьям дә бар иде.

— И Ходаем, сез урап кайтканчы су гына төшмәсә ярар иде. Аны иртәрәк җибәрсәләр нәмә була икән соң, ел саен яз кергәнен көтәләр, — дип, Нурисламның әнисе хафаланып кына озаткан иде, юкка булмаган икән.

Кырык чакрым юлның озынлыгы да, ачлы-туклы булуы да, фатир төшеп, как идәндә төн уздырулары да, җырлашып, уен-көлкеле сүз алышып әллә ни сизелмәгән иде. Тик Минзәлә аларны колач җәеп каршыламады.

— «Кызыл көч»тән дисезме? Знать не знаю, безнең глубинкада сезнең колхозга дигән ашлык юк.

Йөнтәс кашлы, мыек чолгыйлары иягенә асылынып төшкән, бертуктамый йөгерешеп торган, муенса төймәләредәй түгәрәк күзле агай кырт кына шулай дигәч, барысы да аптырап калды. Шулай да арада тәҗрибәлерәкләр дә бар иде:

— Бәтәч, юк диеп, ел саен шушыннан апкайта торган идек бит. Быргадир бу юлы да Минзәләгә дип җибәрде ләса.

— Каян кая килеп, буш кул белән кайтып булмый бит инде, адәм тәганәсе...

Хатын-кызларның ыгы-зыгысына әллә ни исе китмәгән йөнтәс каш кәгазьләрен тагын актаргандай итте дә:

— Бигайбә, апайлар, миннән тормый. Исемлектә сезнең колхозның «к» хәрефе дә юк. Кайтышлый бүтән глубинкаларга туктап сорашыгыз әле, мужыт, буталып, шуларның берәр исемлегенә кергәндер, — диде дә, салпы якка салам кыстыра-кыстыра, оста гына озатып та җибәрде.

Юл өстендәге авыл глубинкаларыннан да коры кул белән борылып чыктылар.

...Аю авылында төн уздырып, атны ял иттереп юлга кузгалганда, көн шактый җылыткан, апрель кояшы, кызларның кәефен күтәрергә теләгәндәй, юмарт елмаеп, җиргә баккан иде. Үзенә тиң көләч йөзләрне генә күрмәде ул. Кызлар бер мәгънәсезгә юл сабып йөрүләренә, буш кул белән кайтуларына ут йотып атлыйлар иде.

— Җылыта, малайлар, Ыкка су гына төшмәгән булса ярар инде.

— Әйтмә дә генә, чабаталар болай да мәлҗери башлады.

— Нурислам, атыңны җәһәтрәк атлат әле, аңа карап, без дә шәбәябез бит...

Матвеевка авылына җиткәч, очлы күзле берәве җан ачысы белән ахылдап куйды:

— Сукыр тычкан юлга чыкса, аршын ярым кар ява, ди. Төшмәйме соң...

Язгы суга ястык калынлыгы булса да ышанма, диюләре хак икән. Күпме генә бил алышмасын, кыш бирешкән: симәнәчеләрне кар юрганы астында йокымсырап озатып калган елгага яз аяк баскан иде.

Әлеге дә баягы тәҗрибәлерәкләр сүз алды:

— Ат артыннан атласак кына инде. Малкай каты эзне тоя бит ул, сукмакны тапмый калмас.

Нурислам дилбегәне ычкындырмый гына беренче булып чана артына басты. Кызлар да, Аллага тапшырып, тезгә җиткән суны ерып, Нурислам артыннан атладылар. Үзе хакында уйламады егет, Гөлмәрьямнең нәзек гәүдәсенә карагач, үзәкләре өзелде. Бозлы су йөрәген яндырды.

— Сират күперен кичүләр дә шулайрак микән, кызлар? — Елганың бу ягына барысы да исән-имин чыгып җиткәч, дер-дер килгән килеш, берәвесе шаяртып та алды.

— Оҗмахка аяк бастык, димәкче буласыңмы әллә? — диде икенчесе, лычма су булган аякларына, сырмасының юеш итәк очларына ишарәләп.

— Сөйләнеп тормагыз, йөгердек, кызлар. Әле ун чакрымлап кайтасы бар бит, чир эләктермәек дисәгез, кыймылдагыз...

Атлый-йөгерә дә кайттылар, хәлдән тая башлагач, чанага да төялделәр. Бозланып катарга өлгергән киемнәр, чанага утыргач, бөтен гәүдәгә калтырау төшерә иде — янә җәяүләргә керештеләр. Кичке караңгылык канат җәя башлаганда, ничек кирәк алай кайтып егылдылар. Нурисламның әнисе, күз яшьләренә төелә-төелә, улына тиз генә коры киемнәр әзерләп китерде, даруга гына саклап тоткан каз маен эретеп, күкрәген, аркасын уарга керешә. Рәхмәт төшкере, мичен ягып, өен дә җылыткан иде: егет, мәтрүшкәле чәйне чүмечтән генә чөмергәннән соң, коры сырмага төренеп, мич башына менеп ятты һәм, татлы җылы тәненең һәр күзәнәгенә үтеп кереп, рәхәт изрәү баскан бер мәлдә корт чаккандай дертләп китте: «Гөлмәрьям! Аның бит мичкә ягып торырга әнкәсе юк. Әтисе көне-төне фермадан кайтып керми, куна-төнә диярлек шунда ята». Егет, дөньясын онытып, идәнгә сикерде. Шабыр тиргә баткан тәнен аннан-моннан сөрткәндәй итте дә, кулына ни эләксә, шуны алып, киенергә керește. Сәке почмагында киндер чүпрәккә төрелгән каз мае тора иде — күзе төшүгә, шуны алып кесәсенә тыкты. Ә дияргә дә, җә дияргә дә белми торган әнкәсен аптырашта калдырып, «Гөлмәрьям» диде дә, чыгып йөгерде.

Нурислам Гөлмәрьямнәрнең коточкыч фәкыйрьлек һәм котып салкыны бөркелеп торган ярымкараңгы өйләренә аяк басуга, бермәл тын калды. Гөлмәрьямнең әнисе исән чакта өй эчендә нур бар иде, җылылык бар иде. Тәбәнәк тәрәзәләрдә чигүле пәрдәләр эленеп тора иде. Мич аралыгында кызыл чәчәкле чаршау бар иде. Бүген исә өй эче шәрәләнеп, ятимләнеп калгандай тоелды...

Түр почмактагы сәкедә, сулык-сулык килеп берәү елый. Гөлмәрьям... Ишек тавышына да игътибар итмәде ул, сулкылдады да сулкылдады. Бу сулкылдауга юл газабы да, ятимлек ачысы да, гаҗизлек-чарасызлык та — барысы, барысы да сыйган иде.

— Гөлмәрьям! — Нурисламның тавышы йөрәгеннән өзелеп төште.

— Килмә! Якын килмә!

Кыз сүзен әйтеп бетергәнче Нурислам сәке янында иде. Ала-кола юрганга төренеп, почмакка сыенып утырган кыз иңсәләрен дерелдәтеп елый бирде. Авазлары өзек-өзек чыкты.

— Килмә, дим! Минем... киемем юк.

Егетнең аптыраулы сүзсез соравына янә сулкылдап җавап кайтарды.

— Юешләрен мич буена куйган идем. Анда да салкын. Алмашка бүтән күлмәгем юк минем.

Нурислам каккан казыктай басып торуның мәгънәсезлеген, нидер эшләргә кирәклеген аңласа да, тиз генә исен җыя алмады. Бераздан мич янына атлады. Бәхеткә, аралыкта утынга дигән бер-ике такта кисәге, әз-мәз салам да бар иде — егет, шуларны тутырып, ут элдереп җибәрде. Мич алдында торган табага каз мае салып, аны эретергә куйды. Бераздан, агач шүрлек янында эленеп торган чүпләмле сөлгене алып, кызган табага үрелде.

— Гөлмәрьям! Юрганыңны ач, аркаңны май белән уам.

Кыз, оятыннан комачтай кызарып, юрганына тагын да ныграк сыенды.

— Чирләп егыласың килмәсә, җәтрәк кылан! — Бу юлы Нурисламның тавышы боерулы яңгырады. Кыз, керфекләрен күтәрмичә генә, егеткә аркасы белән борылды. Нурислам юрганны ачты, кайнар майга манылган бармакларын кызның күшеккән аркасы буйлап йөртә башлады. Шул мәлдә кинәт кенә бу нәни кошчыкны үзенә сыендырасы, үзендә булган бар җылыны аңа бирәсе, сулышы белән эретәсе килгәнне тойды егет. Аның уйларын сизгәндәй, кызның ябык гәүдәсе әллә куркып, әллә туңып дерелдәп китте.

Нурислам, үзенең юа-юа төсе танымаслык хәлгә килгән күлмәген салды да, ай-ваена карамыйча, Гөлмәрьямгә кигерде, кызны сабый баладай юрганга төреп куйды...

Гөлмәрьям гаепле кешедәй башын түбән иеп кенә сүз катты:

— Әнкәй чирләгәч, өйдәге бөтен чүпрәк-чапракка кадәр әле сөткә, әле онга алыштырып бетердем бит. Исән генә булсын иде, җаннарымны да бирер идем дә соң...

Кызның тавышы калтырады, ул башын юрганына яшерде. Хәсрәт-сагышының ташып түгелер мәле идеме, бераздан сүзен янә дәвам итте.

— Займыгыз түләнмәгән дип, сыерны алып китмәгән булсалар, исән каласы идем әнкәем. Көн саен сөт эчәр иде, бер йотым ризыкка тилмереп ятмас иде... Нурислам, хәтерлисеңме, узган кышта колхоз атын бүреләр ботарлаган иде? Урман авызыннан шуның тиресен сөйрәп кайттым, аны тураклап, аш пешердем. Әнкәйнең авызына итнең тәме булса да кермәсме, дидем. Барыбер терелтә алмадым шул үзекәен, терелтә алмадым...

Нурисламның да тамагына төер тыгылды. Кызның күз яшьләрендә нигәдер ул үзен дә гаепле итеп тойды.

— Гөлмәрьям, — диде ул, кызның күзләренә туп-туры карап. Карашында: «Синең кайгың — минем кайгы. Мин «син» дип яшим. Гомерем буе син дип яшәячәкмен», дигән сүзләр чагылса да, аларны тел тибрәтеп кабатларга егетнең кыюлыгы җитмәде. — Елама инде, Гөлмәрьям, — диде Нурислам, кызның чәчләренә сак кына кагылып.

Бу күрешүнең соңгы күрешү, калган гомерне буеннан буена озатып барачак, төнге йокыларны бүлеп төшләргә керәчәк, төзәлмәс җәрәхәт булып йөрәкнең иң түрендә уелып калачак соңгы күрешү икәнен егет әле белми иде.

Ул төнне егет ут булып кызышкан көе урынга егылды. Яшәү белән үлем арасында шактый көрәшеп, аякка басканда, әнисенең күзгә туры карарга кыймагандай тәрәзәгә төбәлгән килеш әйткән сүзләре аяз көнне суккан яшенгә тиң булды.

— Гөлмәрьямнең әтисен апкиткәннәр. Немецләрдә әсирлектә булган икән, ничек эләккән, ничек качкан — шуны тикшерәселәр, ди, бугай. Үзебезнең авылныкылар «тырышкан» ди, хак булса. Гөлмәрьям юкка чыккан. Эзләп-эзләп табалмадылар. Исәнме-үлеме икәнен дә белгән кеше юк. Гарьлектән үзенә кул салмаган булса ярар инде, әй, бәхетсез бала.

Юк. Юк, авыл Гөлмәрьямсез яши алмый. Әнә бит, боз юрганыннан арынырга өлгергән инеш тә, әле бер, әле икенче ярына бәргәләнә-бәргәләнә, Гөлмәрьямне эзли. Яз кояшына баш калкыткан таллар да аны көтә, аны юксына. Ялангач таллар арасында исә, йөрәкне мең телемгә телгәләп, ялгыз бер кош өзгәләнә. Тик Нурислам гына аны ишетмәде...

***

Дөрес яшәлдеме-ялгышмы — Нурислам монысына бәя бирә алмый. Тик шунысын акылы белән аңлый: Гөлмәрьям югалган көннән алып бүгенгегә кадәр ул хыял белән яшәде.

Бар сере, бар хәсрәте инеш суларына сыйды. Нурисламның йөрәк сагышыннан инеш тә сулды, инеш тә саекты. Нурислам белән бергә картаеп, таллар да чаларды, олпат өянкеләргә әверелде. Егет булып килүче Нурисламның тәүге күз яшьләренә шушы таллар шаһит булды ич. Гөлмәрьямнең исән икәнен, күз күрмәгән якларда оя корганын, балалар үстереп ятканын ишеткәч, ир уртасы Нурислам шушы таллар кочагына килеп үкседе. Гөлмәрьямнәр нигезендә җиде ятлар йорт җиткергәнен Нурислам шушы талларга сыенып күзәтте. Шушы таллар аңа Гөлмәрьям тавышы белән эндәште: «Исәнме, Нурислам! Балачак дустым, яшь йөрәгемдә бөреләнгән, чәчәк атарга өлгермәгән мәхәббәтем минем! Әткәй артыннан чыгып киткән көннән алып, язмышның сикәлтәле юлында күп йөрдем. Туган авылымның шәфкатьсезлеген, әткәемне таш капчыкка этәрүен кичерә алырмынмы, белмим. Тик мин барыбер кайтырмын. Анда минем әнкәм кабере, анда минем ярты җаным калды»...

***

Тузганак керфекләре янә җилгә сибелде. Нурислам, уйларыннан арынырга теләп, пакус өстеннән кузгалды. Мунча почмагында калдырган олы җәймәне алып төште, борынны кытыклаган хуш исле печәнне кочаклап-кочаклап шунда салды. Баш-башларын тоташтырып бәйләгәч, ярыйсы гына олы төенчекне аркасына асты да ашыга-ашыга абзар буена юнәлде. Йөрәге нигәдер дулый, урыныннан куба кебек иде. Бу мизгелдә күңел түренә ниндидер курку хисе кереп ояләды. Гомер буе көткән Хыялын менә-менә эзләп табар да, ымсынып, ашкынып яшәвенең бөтен мәгънәсе җуелыр, чәлпәрәмә килер сыман тоелды Нурисламга. Ә бит моңарчы бөтенләй киресенчә иде, Хыялы — тормыш мәгънәсе иде... Шулай да ул түзмәде, төенчеген бер як җилкәсенә авыштыра төшеп, бакча башына әйләнеп карыйсы итте. Аръяктагы йорт буенда баягы ялантәпиле кызны җитәкләгән ят карчыкны күргәч, кинәт кенә аякларының җегәре киткәндәй булды.

Нурислам гомер буе ул капка төбендә тик басып торуны күз алдына китерә иде: алтын толымнары тезләренә җиткән ялантәпиле Гөлмәрьямне күрергә хыялланып яшәде. Ә бу карчык — ак яулыгын шәһәрчәләп чалма итеп бәйләгән, ялтыравык кара күлмәге өстеннән шәмәхә төстәге ыспай гына кәчтүм кигән, тулы гәүдәле карчык аның өчен чит-ят иде. Нурислам, күпме генә текәлеп тормасын, аны танымады.

Карт, егетләрчә җил-җил атлап, адымнарын дәвам итте, шулай да барган шәйгә янә бер борылып карады. Таллар, нәкъ элеккечә, толымнарын җилгә тараткан, ә инешнең ике яры офыкның зәңгәр сызыгында бергә кушылган иде.



ҖАВАПЛАР ТАБЫЛМАГАН ДӨНЬЯДА

Луиза Янсуар

2023 ел стримингларында кызыклы һәм үзенчәлекле сериаллар күренгәләп торды. Арада дәвамлы булган, безгә әле алга таба да яңа сезоннар вәгъдә итүчеләре дә шактый. Өр-яңа икесенә тукталып узасы килә. Һәр икесен дә, карап бетермичә, экраннан аерылып китеп булмый.

Фотолар: kinopoisk.ru, 4aug.lostfilma.net, goodfon.ru, film.ru

ИСӘН КАЛСАК, БЕЗНЕ КЕМ ТУКТАТЫР?

Прокаттагы исеме: «Укрытие» («Бункер»)
Дөньякүләм премьерасы: 5 май 2023
Стримингы: Apple TV+
Сезоннары: 2
Жанры: фантастика, драма, триллер
Шоураннеры һәм сценарий авторы: Грэм Йост
Режиссёрлары: Адам Бернштейн, Мортен Тильдум, Берт, Дэвид Семел
Актёрлары: Ребекка Фергюсон, Тим Роббинс, Харриет Уолтер, Эви Нэш, Билли Постлтуэйт, Чиназа Уче, Иэн Глен, Дэвид Ойелоуо һ.б.
«Кинопоиск» сайтындагы рейтингы: 7,8



Күпчелек кино тәнкыйтьчеләренең фикерләре, рейтинглар суммасы буенча исәпләп караганда, шикләнмичә, 2023 елның иң шәп сериалы дип әйтергә мөмкин. Зәвыклы, интеллектуаль тамашачы да, массачыл продукт ятучылар да бер фикердә кисешә: «Укрытие» – чын-чынлап вакыйга. Һәрхәлдә, кайчандыр телеэкраннарны шартлаткан һәм барыбызны да яңа сезонын көтәргә мәҗбүр иткән «Остаться в живых» проектыннан бер дә ким түгел. Аерма шунда гына: соңгы елларда, бигрәк тә карантин вакытында өйләребездә бикләнеп утырып, күпсанлы видеоформатны чиксез күләмдә кулланырга өйрәнгән безне инде хәзер берни дә балаларча шаккатыра һәм сокландыра гына алмый. Ә бит, асылда, сериал нәкъ менә мәңгегә үзгәргән дөнья һәм, исән калып, бункерда көн итәргә мәҗбүр кешелек турында.

Сериал нигезендә – Америка язучысы Хью Хауи иҗат иткән «Бункер» әсәрләр циклы. Сюжет, беренче карашка, әллә ни яңа да түгел һәм шактый гади. Мондый жанрдагы әсәрләрне без күп беләбез. Әмма Хауи әсәрендә бары тик аңа гына хас булган фәнни детальлек, постапокалипсистан соңгы дөнья төзелешен җентекләп тасвирлау осталыгы бар. Һәм – серләр, серләр, серләр...

Якынча 140 ел элек җирне һәлакәткә китергән хәлләрдән соң, кешелек 144 этаждан торган бункерда яши. Ә бункерның тышында – куырып алып һәлак итә торган агулы һава... диләр. Гәрчә моны беркемнең дә үзенең сынап караганы булмаса да, Зур залдагы тәрәзә аша барысын үз күзләре белән

Хью Хауи 1975 елның 23 июнендә АКШның Төньяк Каролина штатында Шарлотт шәһәрендә туа. 1995 елда Чарлстон шәһәренә күчеңә, андагы колледжда физика үзләштерә. Китап кибетенә эшкә урнаша. Көймә сатып ала һәм шунда яши башлый. Озакламый инглиз филологиясе курсларына, профессор Деннис Голсбери дәресләренә языла. 1998 елда укуын ташлап, үз көймәсендә Багам утрауларына йөзә, анда яхта капитаны булып эшли. Яңадан колледжга укырга кайта, яңадан ташлый, Нью-Йорк верфьләрендә эшли.

Икенче мәртәбә өйләнгәч, Виргиниягә күчеңә, биредә аның хатыны психология буенча докторлык дәрәҗәсе ала һәм укыта башлый. Хауи янә китап кибетенә эшкә урнаша һәм ирекле вакытын язуга багышлый. 2011 елда ул хыялындагы фәнни-фантастик серияне язарга тотына – әлеге романнар циклында язучы һәлакәттән соң җир асты бункерында яшәргә мәҗбүр ителгән тоталитар җәмгыятьне сурәтли.

2015 елда Хауи, өеннән һәм цивилизацияле тормыштан баш тартып, Көньяк Африкага күчеңә. Җилкәнле катамаран төзеп, җир тирәли сәяхәткә кузгала. 2022 елда өченче мәртәбә өйләнә һәм хәзерге вакытта Нью-Йоркта яши.

Әсәрләре дистәләгән телләргә тәрҗемә ителгән.

күреп торган кешеләр ышана. Аларның, җәзага дучар булып, Тышка чыккан берничә кешенең язмышын күргәне бар. Әнә, алар пыяла артында гына йөзтүбән ята...

Исән калган 10 мең кешенең яшәеше катлар белән билгеләнгән: югары катлам вәкилләре югары катларда – болар хакимлек белән хөкем итүчеләр, урта сыйныф вәкилләре – аңлашыла ки, уртада мыжгылдый, ә түбәндәгеләр бункерны электр уты бирү, һаваны чистартып тору һ.б. яшәү шартлары белән тәэмин итүче «күселәр» генә. Түбән вә урта катлам вәкилләре бункерның иминлеге өчен язмышларын да кызганмаска тиеш. Бөтен нәрсәгә биредә Устав һәм канун бар, аларны үтәмәүчеләр өчен кулланыла торган катгый алымнар да. Дөрес, кем дә кем Уставны үтәмичә яшәргә җөрьәт итә икән, аларны биредә беркем тотмый – рәхим ит, Чистарыну дип аталган законлы процедураны уз да Тышка чыгып кит.

Бу яңа дөньяда кешелек хәтереннән ваз кичкән токым булып күз алдына килеп баса. Күпчелекне мондый таләпләр әллә ни борчымый да, әмма арада һәрчак йөрәге бимазалана торганнары табыла бит. Бигрәк тә ул җан ярасы – балачак хатирәләре белән дә бәйле булса... Төп героиня Джульетта очрагында шулай. Ул этисенең бункерга ничек хезмәт иткәнен белсә дә, энисе һәлак ителгәннән соң, урта сыйныф вәкилләреннән булырга теләмичә, «түбәнгә» төшеп китә. Ә «түбәндәгеләр» бары тик очын-очка ялгый, ничек тә яшәргә тырыша-тырмаша һәм, һәрвакыттагыча, аяк астында җир киткәнен «өстәгеләрдән» иртәрәк сизенә. Артефактларга юлыгып, мәхәббәткә мавыгып, бункерның тагын да астагырак катларына төшеп йөри башлагач, Джульетта моны аермачык абайлый. Әмма һәр нәрсәнең үз бәясе бар. Җәмгыять сине бүген

> ДӨРЕСЛЕК БЕЛӘН ЯЛГАННЫ БЕРГӘ КУШЫП, БОЛГАТЫП КАРА – КАЙСЫ НИ ИКӘНЕН ҮЗЕҢ ДӘ АҢЛАМАЯЧАКСЫҢ.
>
> Хью Хауи, «Бункер»

өскә, иртәгә аска чөеп уйнавын туктатмаячак.

Сериалның визуалы, музыкаль драматизмы - югары дәрәҗәдә. Футуристик детальләр белән берләштерелгән ретро элементлар үзәк өзгеч атмосфера тудыра.

Минем өчен бу сериал, иң беренче чиратта, җәмгыять һәм система өчен уңайсыз булган кешеләр турында. Алар һәрчак күбрәк белергә тели, сораулар бирә, алган җавапларда бушлык тоя, дөреслекне үзе эзләргә керешә.

...Ә зур залдагы пычранып беткән пыяла артында һәр кич берәү утыра һәм йолдызларны күрә. Ул аларның нәрсә икәнен дә белми, әмма – борынгы бер инстинкт буенча – соклана һәм чын икәнлекләренә ышана. Югыйсә, бер генә нәрсәнең дә мәгънәсе булмас иде бит...

ӘНӘ КҮЗЕ АША КАРАСАК...

Прокаттагы исеме: «Переполненная комната»
Дөньякүләм премьерасы: 9 июнь 2023
Стримингы: Apple TV+
Сезоннары: 1
Жанры: биография, детектив, триллер
Шоураннерлары һәм сценарий авторы: Акива Голдсман, Тодд Графф, Сюзанн Хиткот, Джессика Эшфорт
Режиссёрлары: Брэйди Корбет, Мона Фастволд Лерче, Корнел Мундруцо
Актёрлары: Том Холланд, Аманда Сайфред, Эмми Россам һ.б.
«Кинопоиск» сайтындагы рейтингы: 7,7

Тодд Графф, Дэнни Де Вито белән берлектә, «Переполненная комната» фильмына сценарийны әле 1997 елда ук яза. Режиссер буларак ул чакта Джеймс Камерон күздә тотыла. Джонни Депп, Брэд Питт, Шон Пенн, Колин Фарелл кебек актёрлар Миллиганны уйнарга атлыгып тора, продюсер буларак чыгыш ясарга да. Аларның кайберләре Миллиган белән шәхси очраша һәм аның консультациясен дә ала.

2015 елның мартында бу рольнең Леонардо ди Каприога тәгаенләнгәне билгеле була, ул аны инде 20 елга якын уйнарга хыяллана. Әмма 2016 елда проект туктатыла, аңа кабат шул формада әйләнеп кайтмыйлар.

Шулай да 2021 елда аны сериал итеп чыгарырга хәл итәләр. Беренче сезон 10 эпизодтан гыйбарәт, аның сценарий авторлары тоташтан йолдызлы составны тәшкил итә. Ә актёрлар составына килсәк, проект авторлары монда бөтенләй көтелмәгән рокировка ясый – без күрергә хыялланган, үзе уйнарга омтылган берәү дә юк. Сериал 2022 елның 31 мартыннан 28 сентябренә кадәр Нью-Йоркта төшерелә.

Билли Миллиган турындагы шау-шу инде тынган иде кебек. Гәрчә без аның турындагы фильмда төшәргә әле һаман да Леонардо ди Каприо белән Джонни Деппның хыялланууын онытмасак та. Һәм менә еллар буена сөйләнгән, көтелгән сериал, ниһаять, стримингларда. Ә төп каһарманнары – бөтенләй көтелмәгәнчә! – Том Холланд белән Аманда Сайфред.

Әлбәттә, без биредә документаль тәңгәллек эзләргә тиеш түгел, бу хакта сценаристлар белән режиссерлар башта ук кат-кат әйттеләр. Ә шоураннеры дөньякүләм бестселлерларны сериалга яки тулы метрга адаптацияләү буенча осталардан булган Акива Голдсман һәм аның саллы командасы Миллиган тарихының инде, чынбарлык белән турыдан-туры бәйлелектән арынып, социаль феноменга әверелүен ассызыклады.

Әйе, бу команда, Дэниел Киз романыннан китеп, яңа сәнгати чынбарлык тудыруга йөз тота, шуңа да без төп каһарман Дэнни белән очрашканда, аның өлкән тормыштагы җәрәхәтләнгән Миллиган героена бары тик сукмак кына икәнен аңлыйбыз. Киздан ераклашу кирәкми, диючеләр белән катгый килешмим, чөнки без Миллиган тарихын шулай ук асылда әдәби гәүдәләнеш аша кабул иттек, бу тарих инде беркайчан да документаль чынлыкта була алмый. Әмма аңа булган кызыксыну бер нәрсәне исбатлый: без кабат-кабат сере чишелмәгән бу шәхескә һәм аның яралы, куркыныч язмышына әйләнеп кайтабыз. Бу язмыш безгә төрле проблемаларны яңадан күтәрергә һәм алар турында сөйләшергә этәргеч, сәбәп, нокта.

Ни өчен, дигән сорау бимазалады күңелне гел. М.Найт Шьямаланның күпләргә мәгълүм булган киеренке «Сплит» һәм «Стекло» фильмнарыннан соң да, «Монстры внутри» документаль картинасыннан соң да... Ә җавап бик гади: без ни өчен икәнен белмибез. Билли Миллиган безгә үзе турында да, аны тудырган, формалаштырган җәмгыять, чор турында да җаваплар калдырмыйча китте. Кеше баш мие белән психологиясенең феномены турында да... Җаваплар булмаган җирдә сораулар кала. Һәм алар арта да арта.

Әлбәттә, мин, тамашачы һәм аларның талантына сокланучы буларак, югарыда исемнәре аталган «җегетләрнең» ничек уйнавын күрергә теләр идем. Әмма Том Холландны бу рольдә беренче эпизод кадрларында күрүгә үк... «ә бит Ди Каприо булса иде!» дигән уйның эзе дә калмады. Бу актерның эшеннән чын мәгънәсендә ләззәт аласың. Оригиналда карасаң, Холландның ни дәрәҗәдә дикция, акцентлар белән эшләвен дә күрергә, ишетергә, тоярга мөмкин. 70 нче еллар вайбы, музыкаль һәм визуаль эстетика – боларына да аерым рәхмәт, чөнки алар нәкъ менә безнең балачактан үз чорыбызның продукты булырга мәҗбүр ителгәнлегебез турында бик яхшы сөйли. Безгә тагылган мөһерләрдән беркая да китә алмавыбызны ассызыклый. Һәм ностальгия дулкынына көйли.

Ә каян һәм кайда соң без чын үзебез? Әнә шул сорауны каһарманнар белән бергә сериал дәвамында эзлисең. Моны без сериал азагында, Дэнни бүлмәсендәге картиналар эченә кереп күмелгәч кенә, бар тирәнлегендә аңлыйбыз: без әнә шуннан, ул киндерләрендә сурәтләгән йолдызлардан, май коңгызлары җемелдәгән җәйдән, сере чишелмәгән һәм чишелә дә алмаячак табигатьтән, гөрелдәп торган Галәмнән...

Бу картинада мин беренче мәртәбә альтер-эголарыннан арынырга мәҗбүр ителгән, ягъни психолог белән эшләгәннән соң рациональ чынбарлык белән күзгә-күз калган кешенең ни дәрәҗәдә упкын алдында торганлыгын аңладым. Шуңа да соңыннан Дэнни образындагы Джек: «Сез үз эшегезне эшләдегез, берни дә барып чыкмады, без һәрчак үзебезне үзебез генә коткара алдык», – ди. Бу, бернинди җинаять, көч куллану, харап ителгән балачак, тапталган язмышлар, феминистик, гендер системаларының катаклизмы фонына карамастан, искиткеч тормышчан һәм оптимистик рухлы картина. Үзеңне һәм үзеңдә яшәгән беренчел сабыйны саклый алу һәм олы ярадан матурлык тудырырга омтылу...

Бу – безнең бүгенге әчке дөньяларыбыз җимерелгән, ә яңа система, корылмага ишарә дә булмаган чынбарлыгыбыз түгелме соң? Сериалның буеннан-буена без ташландык амбар эчендәге күпкатлы читлекләр эчендә урап йөрибез, бу да үзенә күрә – бункер, аннан чыгу юлы бер генә: куркуың каршына күзгә-күз килеп басып һәм барысына да сәбәпче булган бер үзеңә ышанып.

ШУЛАЙ УК УКЫРГА ҺӘМ КАРАРГА:

- **Дэниел Киз. «Множественные умы Билли Миллигана»** («Таинственная история Билли Миллигана») романы
- **«Монстры внутри: 24 личности Билли Миллигана»** документаль мини-сериалы, режиссеры – Оливье Мегатон
- **«Сплит», «Стекло»** фильмнары, режиссеры – М.Найт Шьямалан

> КОТОЧКЫЧ АВЫР БУЛДЫ, ШУҢА ДА АЛДАГЫ ЕЛГА КИНО БЕЛӘН АРАНЫ ӨЗДЕМ. МЕКСИКАГА КИТТЕМ, ҮЗ-ҮЗЕМӘ БИКЛӘНДЕМ, ПЛЯЖДА АУНАДЫМ. МОҢАРЧЫ БЕРКАЙЧАН ДА ТОЕП КАРАМАГАН ЭМОЦИЯЛӘРНЕ КИЧЕРЕРГӘ ҺӘМ АНАЛИЗЛАРГА МӘҖБҮР ИТТЕ СЕРИАЛ. ЭШЕМНЕ НИКАДӘР КАТЛАУЛЫРАК БУЛСА, ШУЛКАДӘР КҮБРӘК ЯРАТАМ, ХӨРМӘТ ИТӘМ. ӘММА БУ ПРОЕКТ МИНЕ ИЗЕП ТАШЛАДЫ, ЮККА ЧЫГАРДЫ, ТУЗАНГА ӘЙЛӘНДЕРДЕ. ЯҢАДАН ҖЫЯР ӨЧЕН.
>
> Том Холланд

Нәни генә бер бала, үсмер малай язмышы аша без бик күп нәрсәләр турында уйлана алабыз. Әлбәттә, бу байопик түгел. Бу – мотивлар буенча эшләнгән проект. Әмма шәхсән минем өчен бу проект – Дэниел Киз аша киң җәмәгатьчелеккә таныш вакыйгага тагын бер мәртәбә, яңа күзлектән караш ташларга чакыру булып тоела.

Әйе, чынбарлык белән уйдырманы аерып та, төгәл аңлап, табып та булмый. Детективлы башваткыч белән эш иткәнебезне дә без бик яхшы тоябыз. Хәтта бәян ителгән хәлләр дә – беркайчан чын дөреслек түгел, аларда гел кемнеңдер интерпретациясе, эмоциональ эзе, манипуляция чалымы бар. Бу безнең хакта түгелме? Әнә күзе аша карасак, нәрсә күрәчәкбез?

Татарстан авыллары

Әдәмсә: күпмилләтле авылга читтән караш

Фото: Александр Ефремов

Әдәмсә

Мәчете дә, чиркәве дә булган авыллар республикада күп түгел. Яңа Чишмә районының Әдәмсә авылы әнә шундыйлардан берсе. Монда Шәйхи Маннур әйткәнчә: «Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел», – дигән девиз белән яшиләр. Дини бәйрәмнәрне уртак билгеләп узалар. Бу дуслыкның сере нәрсәдә? Әдәмсәгә баргач, шул сорауга җавап эзләдек.

Руфия Фазылова

«УРТА МӘКТӘП БУЛЫП АЧЫЛАБЫЗ!»

Гадәттә, авыллардан киткәндә: «Сез безгә иң матур чакта – җәй килегез», - дип калалар. Әдәмсәне әнә шундый вакытта – кешеләрнең бакча, ишегаллары шау чәчәккә күмелгән чакта күрергә насыйп булды. Чәчәк кенә түгел, төрле сыннар, фонтаннарга кадәр ясаган халык. Киң урамнар, бөтен җирдә яшеллек, җимерек йортлар да юк дияргә була. Авыл үзәгендәге зур мәктәп ерактан ук игътибарны җәлеп итте. Беренчедән, бинасы һәм мәйданы бик зур, икенчедән, ул капиталь төзекләндерүдән соң, балкып, гөлбакча булып утыра.

Яңа мәктәп 1994 елда ачылган. Шул чорда республикада яңа проект белән салынган өч белем учагының берсе ул: ике йөз егерме балага исәпләнгән. Аерым актлар залы, спорт залы, зур ашханә, киң коридорлар, зур сыйныфлар: шәһәр мәктәпләренең кайберләрендә дә мондый уңайлыклар юк. Бүген биредә алтмыш бала белем ала, бу бер Әдәмсә авылы балалары гына икән. Мәктәп коллективы яңа уку елын зур сөенеч белән каршы ала – биш ел тугызъеллык булып торганнан соң, яңадан урта мәктәпкә әйләнәләр.

– Мин Әдәмсә урта мәктәбендә утыз биш ел эшләдем, математика фәнен укыттым, – диде Тәскирә Сибгатуллина. – Директор ярдәмчесе

1

Мәктәп капиталь төзекләндерүдән соң авыл күркенә әйләнгән.

2

Әдәмсә урта мәктәбендә утыз биш ел математика укыткан Тәскирә Сибгатуллина бүген музей җитәкле.

3

Белем йорты гөлбакча булып утыра.

булып та тордым. Безнең мәктәптә һәрвакыт татар, рус сыйныфлары булды. Балалар саны азайгач, ун еллар элек, бер генә сыйныф калды. Хәзер татар балалары да төп фәннәрне рус телендә укый.

– Ә укытучылар коллективы үзара нинди телдә сөйләшә?

– Татарча да, русча да. Бездә рус милләтеннән булган кешеләр дә татарчаны яхшы белә.

Чынлап та, мәктәпнең хәзерге директоры Наталья Михайловна Главнова татарча белә. Милләте буенча әтисе керәшен татары, әнисе рус икән. Әдәмсә урта мәктәбен алтын медаль белән тәмамлаган. Алабуга дәүләт педагогика университетының биология факультетында укыганнан соң, туган ягына кайтып, балаларга белем бирә башлаган.

– Директор булып ике генә ел эшләдем әле, – диде Наталья Михайловна. – Башта уку эшләре буенча директор урынбасары идем. Менә быел мәктәпнең элеккеге статусын кайтардык. Бөтен коллектив белән шуңа сөенәбез.

– Унынчы, унберенчегә килүче балалар бармы?

– Бар, берничә булачак.

– БДИ куркытмыймы? – дим.

– Юк, куркытмый. Беренчедән, безнең укытучыларның андый тәҗрибәсе зур, коллектив көчле. Икенчедән, балаларның белем дәрәҗәсе югары. Мактану булмасын, әмма бездән соң унынчы сыйныфка барган балалар күрше авыл мәктәбенең рейтингын күтәреп килделәр – БДИны яхшы бирәләр. Директор буларак кына түгел, ата-ана буларак та укучы үз авылында белем алса, яхшырак, дип саныйм. Күрше авылга бару өчен бала иртәнге алтыда торырга мәҗбүр, дүртсез өенә кайтып җитә алмый. Ә үз авылында укыгач, өенә кайтып та килә ала. Аннары, без зур трасса өстендәге авыл, балалар өчен ут йотып торганчы, җәяү йөрсәләр, күңел тыныч.

Мәктәп директоры белән телләр турында сөйләшәбез. Баксаң, рус милләтеннән булган һәр бала татар телен укый икән!

– Үзләре теләпме? – дим.

– Әлбәттә, ана теле урынына гариза язып татарча укыйлар. Алай гына түгел, тугызынчыдан соң татар теленнән имтихан тапшыралар. Үзләре теләп. Татар балаларына караганда татарчаны яхшырак белүче укучылар бар...

– Ничек алай?!

– Татар телен балалар кечкенәдән ишетеп үсә бит. Алар өчен ул ят тел түгел. Шуның өчен дә тиз оталар. Рус милләтеннән булган ата-аналар үзләре дә татарча укыган, шуңа да бу гадәти хәл санала. Әйтергә дә куркам, безнең мәктәптә тел, милләт проблемасы юк. Укытучылар коллективы да катнаш бит, балалар да. Бәйрәмнәрне уртак билгеләп узабыз, дини бәйрәмнәрдә дә котлашабыз. Ураза гаетенә камыр ашлары белән сыйласак, Пасхага төсле күкәй таратабыз.

Директор зур сөенеч белән мәктәпне күрсәтеп чыкты – узган ел федераль программа нигезендә капиталь ремонт булган. Хәзер ул өр-яңа мәктәпне хәтерләтә. Барысыннан бигрәк мәктәпнең бакчасы шаккатырды: шундый зур мәйданда ник бер чүп булсын. Ә аллы-гөлле чәчәкләре ни тора!

– Чәчәк үсентеләрен яздан ук утыртабыз, – диде Наталья Михайловна. – Чәчәкләр бик яратам, буш вакыт булган саен үзем дә бакчага чыгам. Ә гомумән алганда, бу матурлыкны күмәк көч белән тудырдык. Укытучылар, техник персонал, балалар – барыбыз да җәй буе бакчада эшлибез.

МӘЧЕТ БЕЛӘН ЧИРКӘҮ ЯНӘШӘ...

Әдәмсә зур авыл. 235 хуҗалык бар, 651 кеше яши. Шуларның 456 сы татар, 182 се рус һәм унөче калган милләтләр. Түбән Камадан 50 чакрым ераклыкта урнашкан. Күпләр шунда йөреп эшли. Аннары, бу якларда нефть чыга, авылның алтмышлап кешесе шунда хезмәт куя. Шуның өчен дә, берничә иске өйне санамаганда, буш йортлар юк дияргә була. Балалар бакчасына егермедән артык бала йөри, ике төркем. Ике кибет, кафе... Барысы да халыкны эш белән тәэмин итә. Менә агрофирмада малларны бетергәннәр, халык бу яңалыкны борчылып кабул иткән. Начармы-яхшымы, авылда ферма булу берничә кешегә хезмәт урыны бит.

Балалар бакчасында ремонт эшләре бара иде, анда кереп тормадык. Алай да әкияти бакчаларына күз салып киттек.

Мәктәптән соң Аллаһ йортларына – башта мәчеткә, аннан чиркәүгә кердек.

– Авылның иске мәчете башка урында иде, – диде, мәчеткә кергәч, Габдрахман хәзрәт Зөбәеров. – 1998 елда нигез салынып, 2002 елда ачылды ул. Дин ирегә килгәч тә, халык башта иске мәчеткә йөрде. Яңа мәчетне төзүдә Гәбдерәуф Юнисов бик булышкан. Мин әле ул вакытта авылда яшәми идем.

4
– Быел мәктәпнең элеккеге статусын кайтардык, – диде мәктәп директоры Наталья Михайловна Главнова.

5
Мәчет 2002 елда ачылган.

6
– Быел зур эш башкардык – мәчеткә янкорма салдык, – дип зур сөенече белән уртаклашты Габдрахман хәзрәт Зөбәеров.

7

Дуслык Аллаһ йортыннан башлана – авыл имамы Габдрахман хәзрәт Зөбәеров белән чиркәүне карап торучы Михаил Борисов.

8

2017 елда, аерым кешеләрең зур тырышлыгы белән, чиркәү үзенең беренчел миссиясен үти башлаган.

9

Чиркәүнең үзенең аш-су бүлмәсе булачак.

Габдрахман хәзрәт Әдәмсәдә туып-үскән. Аннан исә Түбән Камада яшәгән, шунда гаилә корган. Лаеклы ялга чыккач, җәмәгате белән туган ягына күченеп кайткан. Диндә күптәннән икән.

– Быел зур эш башкардык – мәчеткә янкорма салдык, – дип зур сөенече белән уртаклашты хәзрәт. – Яңа якта дин сабаклары укытачакбыз, Коръән ашлары уздырабыз. Моның өчен барысын да көйләдек. Халыктан җыелган сәдака акчасына әнә шундый зур эш башкардык. Аллаһка шөкер, мәчетебез зур, заманча. Көн саен ахшам намазына уннан артык кеше була, җомгада күбрәк, әлбәттә...

Мәчеттән соң чиркәүгә киттек. Борынгы, 1874 елда төзелгән бина икән. Совет власте урнашкач, 1937 елда чиркәүдән мәктәп ясаганнар. Авылның берничә буыны биредә укыган. Яңа белем үзәге салынганнан соң, әлеге бина буш торган. Һәм 2017 елда, аерым кешеләрең зур тырышлыгы белән, чиркәү үзенең беренчел миссиясен үти башлаган.

– Мәктәп итеп ясаганда чиркәүнең икенче катын алганнар, – диде Әдәмсә авылының ветераннар советы рәисе Михаил Борисов. – Чиркәүне яңадан торгызу өчен бик күп эшләр башкарылды. Тумышы белән бу авылдан булган бик хөрмәтле кеше – архимандрит Дорофей атакай бар, Мәскәүдә яши. Чиркәүне ул төзеклэндерде. Әле менә икенче якка аш-су бүлмәсе ясап ятабыз. Аны да Дорофей атакай эшләтә. Төзелештә татар егетләре эшли, хәзер кереп чыгарбыз...

Чиркәү эченә узабыз... «Сезгә аяк киемен салыгыз дип әйтәсе түгел, сез өйрәнгән: мәчеткә кергәндә дә аяк киеме белән кермиләр», – дип куйды Михаил Александрович.

Күзгә ташланган беренче әйбер – чисталык, затлылык. Ремонттан соң булгангадыр да, ялт иткән.

– Атакай күрше авылдан килеп йөри, – диде Михаил Борисов. – Мин биредә чиркәүне карап торучы рольдә. Шимбә-якшәмбе чиркәүгә унлап кеше килә. Ә дини бәйрәмнәрдә зал тулы була, күрше авыллардан да киләләр.

Дини бәйрәм дигәннән, Әдәмсәдә 21 июль көнне христианнарның олы бәйрәме – Казан Изге Мәрьям Ана иконасының тәре йөрешен билгеләп узганнар. Чиркәү янында зур бәйрәм булган: балалар өчен бушка батутлар эшләгән, тәм-том белән сыйлаганнар. Концерт куйганнар, анда татарча да җырлаганнар.

– Авылда дини йолалар уртак, – диде Михаил Александрович. – Мәсәлән, мин керәшен татары. Әдәмсәгә моннан егерме еллар элек килдем. Башта колхоз җитәкчесе, аннан мәктәп директоры булдым. Шул вакытта ук аңладым: күпмилләтле авылда һәркем бербереңә ихтирам итә. Бу гомергә шулай бул-



ган. Без, килгән кешеләр дә, әлеге традицияне дәвам иттек. 21 июль көнне чиркәвебезнең биш еллыгын билгеләп уздык. Мәскәүдән Дорофей атакай да кайткан иде. Чиркәү төзелешенә ярдәм иткән унике авылдашка грамоталар әзерләдек. Һәм, беләсезме, шуның алтысы татарларга эләкте! Рәхмәт әйтеп, куллар кысышып алдылар. Чиркәүнең тәресен дә татар егетләре куйды. Әйтәм бит, бездә бүленеш юк...

«СЫЕР АСРАП ГОМЕР ИТТЕК...»

Авылларга баргач, берәр уңган гаилә белән танышырга тырышабыз. Гомер буе хәләл көч түгеп туган авылында хезмәт иткән кешеләрне халык та күрсен, дибез. Әдәмсә авылында Зиннуровлар гаиләсендә булдык. Гаилә башлыгы Мингали абый гомер буе колхозда механизатор булып эшләгән, әле дә трактор йөртә. Вәсимә апа исә лаеклы ялда инде. Ул да гомер буе колхозда – исәпкә алучы (учетчица), ферма мөдире дә булган. Зиннуровлар гел күп итеп мал асраган. Бүген дә дүрт сыерлары бар.

– Элегрәк баш саны бермә-бер артык иде, сөт акчасы белән яшәдек, – диде хуҗабикә. – Хәзер дә шулай көн итәбез. Сөтнең бәясе төште, әлбәттә, бүген литрын 18 сумнан тапшырабыз.

Ир белән хатын ике ул үстергән. Олы уллары Әдәмсәдә калган, җәмәгате белән өч бала үстерәләр икән. Төпчек малайлары гаиләсе белән Түбән Кама шәһәрендә яши.

– Әлеге нигезгә 1988 елда килеп төпләндек, – диде Мингали абый. – Башта Вәсимә белән төп йортта, минем әти-әни белән яшәдек. Аннары монда күчендек. Иске йорт иде. 2004 елда яңа йорт салып чыктык. Авыр елларда да начар яшәмәдек – өч бакча бәрәңге үстереп саттык, итен, сөтен дигәндәй...

Вәсимә апа мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган. Югары белем алырга да нияте булган, тик авылын яратканга, шәһәргә чыгып китмәгән.

– Бер дә үкенмим, – дип көлде Вәсимә апа. (Ул шулай көлеп кенә сөйләшә. – Авт.) – Югыйсә укытучыларымның барысы да, укы, дип киңәш бирде. Авыл тормышын яратам. Ирем әйбәт, бөтен эштә бергә без. Шәһәрдә дә бушка китереп бирмиләр... Укыган кешеләрдән начар яшәмәдек, Аллаһка шөкер...

Мингали абыйның шәхси тракторы бар. Эштән бушаган арада, тракторы белән кырга чыгып, җәй буе печән чаба, аны киптерә. Аннан, тюклар ясап, өенә алып кайта. Тракторга бөтен җайланмаларны да сатып алган.

– Малларыгыз да күп, техникагыз да бар. Фермер булып теркәлеп эшлисегез килмиме? Грант алу мөмкинлеге дә булыр иде, – дим.

– Хәзер юк инде, яшьрәк чакта бәлки уйлап карарга кирәк булгандыр. Алтмышка җиткәч, яңа тормыш башлыйсы килми. Болай без үзебезгә үзебез хуҗа: теләсәк өчне, бишне асрыйбыз, теләмәсәк, бөтенләй асрамыйбыз.

Мингали абый эштә чакта, тракторны уллары Илнур алып тора икән. Кеше бакчасын чаба, җир эшкәртә. Ә эти кеше агрофирма эшеннән бушый алмый.

– Хәзер агрофирма тракторы белән йөри алмыйсың – GPS куйдылар, – ди Мингали абый. – Шуның өчен дә үзебезгә техника кирәк дип уйладым. Малай да авылда бит, алар да мал асрый. Техникаң булганда, иренмәсәң, печән проблемасы юк.

Хуҗабикә Вәсимә апа үзенә гашыйк итте безне – атлап түгел, йөгереп йөри. Кечкенәдән шундый уңган булган. Төнге бердә торып, камыр куйган: безгә дип гөбәдиясен, бәлешен, токмачлы ашын пешергән. (Мондый игътибарга ничек битараф каласың!) Ә гадәттә көне иртәнге өчтә башлана икән, җәйме, кышмы, гел шулай.

...Авыллар буенча күп йөрибез. Кайтканда үзебезчә бәя бирәбез: артык тыйнак халык яши яки җыр-моңга бигрәк оста икән, диешәбез. Ә Әдәмсәдән киткәндә, гаҗәпләнү, соклану хисе туды: болай да буламы икән? Ана телен өйрәник дип лаф органда, әнә, Әдәмсә авылында тыныч кына рус балалары татарча укып ята. Ә татар ир-атлары чиркәүне төзекләндерә. Алар өчен бу шуның кадәр гадәти хәл, безнең аптыраулы карашны күреп, хәтта сүзсез калдылар. Татулык нигезендә бер-береңә хөрмәт ята – Әдәмсәдә шуны яхшы беләләр. Т

10 Әдәмсәнең иң тырыш гаиләләренең берсе – Зиннуровлар.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Әдәмсә авылына XVIII гасырда нигез салынган, дип санала. Ә менә иске зиратта XVII гасырга караган кабер ташлары да табылды. Шуның өчен авылда унҗиденче йөздә үк кешеләр яшәгән, дип уйлыйбыз. Кызганыч, тарихны яхшылап өйрәнгән кеше юк.

Авылның исеменә килгәндә, әби-бабайлардан калган фараз бар: бу якларга Балык Бистәсенең Күгәрчен авылыннан урман кисүче килеп төпләнгән. Елга булгач, бу урында төпләнергә карар кылган. Аның исеме Әдәмсә булган. Менә шуннан бу исем авылга да бирелгән.

Яңа Чишмә районының күпчелек татар авылларында мишәрчә сөйләшәләр. Ә менә Әдәмсә халкының сөйләмендә андый диалект юк. Балык Бистәсеннән күчеп килгән бабаларыбызның теле гасырлар дәвамында әнә шулай саклангандыр, дип уйлыйм.

(Тәскирә Сибгатуллина, Әдәмсә урта мәктәбе музее җитәкчесе.)

афиша

АРКАДИЙ ПЛАСТОВ ДӨНЬЯСЫ (6+)

Третьяков галереясының даими экспозициясендә бер бизәк булып торган «Яз» картинасы – сәнгать сөючеләр өчен дә, беркатлы дилетантлар өчен дә бертөрле дәрәҗәдә аңлаешлы һәм якын. Әлеге картина һәм башка җәүһәрләр авторы Аркадий Пластов иҗаты белән хәзер Казанда да танышырга мөмкин. Күренекле рәссам гаиләсенең тупланмасыннан гыйбарәт күргәзмәдә Аркадий Пластов иҗатының барлык чорларын колачлаган 150 дән артык рәсем һәм графика әсәрләре тәкъдим ителә.

Шунысы да игътибарга лаек: Аркадий Пластовның беренче шәхси һәм бердәнбер күргәзмәсе 1929 елда нәкъ менә Казанда була. Хәзерге экспозиция авторның тууына 130 ел тулуга багышланган. Күргәзмәдәге картиналар арасында рәссамның иң танылган сугыш чоры эше – «Фашист очып үтте» әсәре дә бар. Сталин күрсәтмәсе буенча ул Тәһран конференциясендә күргәзмәгә куела һәм Рузвельт белән Черчилльне бик әсәрләндерә.

31 августка кадәр 10:00 дән 18:00 сәгатькә кадәр,
пәнҗешәмбе көнне – 11:00 дән 20:00 сәгатькә кадәр.
Дүшәмбе – ял көне. ТР ДССМның «Хәзинә» Милли сәнгать галереясы, Казан Кремле, 3 нче подъезд

БЕЛАРУСЬНЕҢ ТЕРЕ МИРАСЫ (6+)

Союздаш дәүләтнең Брест, Витебск, Гомель, Гродно, Минск, Могилев өлкәләре буйлап үзенчәлекле сәяхәт. Белорус халкының мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән танышу, рухи хәзинәсен баяләү. Беларусь Республикасы Милли тарихи музее проекты теләге булган һәркем өчен әнә шундый мөмкинлекләр тудыра. Казанда ачылган күргәзмә «Беларусьның тере мирасы» дип атала, аның экспозициясендә халык һөнәрчеләренең үзенчәлекле эшләнмәләре, милли костюмнар тәкъдим ителә. Туку һәм чигү, мичкә һәм чүлмәк ясау, агачтан уеп ясау, киез басу, салам, чыбык һәм кабыктан әйберләр ясау – күп кенә һөнәрләр безгә, көндәлек әһәмиятен югалтмыйча, бик борынгы заманнардан килеп җиткән. Беларусь мәдәни мирасының мөһим бер юнәлеше – саламнан үреп, төрле әйберләр ясау ЮНЕСКОның матди булмаган мәдәни мирасы исемлегенә кертелгән. Бу факт та экспозициядә тәкъдим ителгән әйберләрнең тиңсезлеген раслый.

17 сентябрьгә кадәр
Сишәмбе – шимбә көннәрендә – 10:00 дән 20:00 сәгатькә кадәр,
якшәмбе, дүшәмбе – 10:00 дән 18:00 сәгатькә кадәр
ТР Милли музее, Казан, Кремль ур., 2

Фотолар «Эрмитаж-Казан» Үзәгеннән, ТР ДССМнан, tatmuseum.ru, tatar-inform.ru, russdramteatr.ru сайтларыннан алынды



КРЕМЛЬДӘ JAZZ (6+)

«Кремльдә Ольга Скепнер белән JAZZ» Бөтенроссия импровизация музыкасы фестивален Казанның җәйге мәдәни тормышының «визит карточкасы» дип атарга була. Фестивальнең быелгы, 17 нче сезоны, һәрвакыттагыча музыка сөючеләрне күренекле исемнәр белән җәлеп итә. Олег Аккуратов, Леван Ломидзе, Дмитрий Илугдин, Андрей Руденко – импровизация буенча танылган артистлар йолдызлыгы чын меломаннарны бер ай дәвамында сөендерә. Фестивальнең алыштыргысыз президенты, авторы һәм алып баручысы – Ольга Скепнер. Сүз уңаеннан, алты искиткеч концертның өчесен август аенда да карарга була. Программада:

3 август – Леван Ломидзе & Blues Cousins

10 август – Саша Алмазова һәм Non Cadenza

17 август – RISE STAR: SEVEN STEPS TO HEAVEN &Мария Аксенова триосы & Олег Аккуратов триосы

Кабул итү урыннары ишегалды сәхнәсе
«Казан Кремле» Музей-тыюлыгы

БӨЕК АЛЕКСАНДР ЮЛЫ БЕЛӘН (6+)

Көнчыгышка сәфәр вакытында Александр Македонский үткән юлдан сез дә сәяхәт кылыгыз, ә озата баручыгыз барлык яшерен серләрне ачар һәм сорауларга җавап бирер. Бу дөньяда 32 ел гына яшәп калган бөек патша тормышының безгә бүген, 2 мең ярым чамасы ел узгач та, ничек йогынты ясавын белерсез. Моны төрле чорлардагы төрле халыкларның әсәрләрендә күрерсез. Әгәр күргәзмәгә балалар белән килгән булсагыз, уен картасы сезгә борынгы цивилизацияләрнең гаҗәеп дөньясын ачарга ярдәм итәчәк. Әлеге карта белән сәяхәт мавыктыргыч һәм истә калырлык булачак. Сүз уңаеннан, «Александр Македонский. Көнчыгышка юл» дип аталган күргәзмә әүвәлрәк Санкт-Петербург, Амстердам һәм Сидней тамашачыларының күңелен яулады инде. Нәтиҗәне үзегез ясагыз.

Дүшәмбе – пәнҗешәмбе, шимбә – якшәмбе 10:00 дән 18:00 сәгатькә кадәр
җомга – 11:00 дән 20:00 сәгатькә кадәр
«Эрмитаж-Казан» Үзәге, 3 нче кат
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

ЯВЫЗНЫ ЭЗЛӘГЕЗ (12+)

Петербург режиссеры Валентин Левицкий тарафыннан детективлар патшабикәсе — Агата Кристи пьесасы буенча куелган «Гаепләү тарафы шаһиты» спектакленең сюжеты гади дә һәм бер үк вакытта катлаулы да. Ул шул дәрәҗәдә чуалып китә ки, сәхнәдә барган вакыйгалар интеллектуаль уенга охшый башлый. Явыз бәндәнең кем икәнен ачыкларга тырышкан тамашачыга яңадан-яңа табышмакларны чишәргә туры килә. Ә детектив спектакльнең ахыры, һәрвакыттагыча, көтелмәгән булачак.

11,14 август 19:00
«Мастеровые» рус драма театры
Чаллы шәһәре, Чулман проспекты, 77

ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ

Казанда Кабан күле буенда һәр пәнҗешәмбе көнне татар телендә «Хәрәкәттә – бәрәкәт» дип аталган бию дәресләре оештырыла.

Мастер-класста татар биюе хәрәкәтләренә өйрәнергә, төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезнең бию үзенчәлекләрен күрергә, биючеләрнең биюләренә сокланырга, рәхәтләнеп ял итәргә була. Бу чараны Парклар һәм скверлар дирекциясе белән берлектә, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Казан шәһәре мэриясе оештыра. Дәресләрдә теләге булган һәркем катнаша ала.

Бүген без укучыларыбызга шундый дәресләрнең берсеннән фоторепортаж тәкъдим итәбез.

Фото: tatar-inform.ru

озеро
кабан

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9172-740-352

Реклама 16+